№ 1 2018

ТУГАРАК УЕН

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

Туган йорт...
Син миңа дөньядан зуррак:
Син – әти, син – әни,
син – Нигез.
Син – җирдә яшәүнең мәгънәсе,
Мәңгегә без – ул син,
син – ул без.

2007нче елгы фольклор экспедициясе вакытында Яшел Үзән районының Олы Шырдан авылында төшереп алынган сөлгеләр.

Илсөяр ИКСАНОВА

Сөлге – дастан

Кем чиккән? –
Инде билгесез.
Ни чиккән? –
Аңлау читен.
Тарих битен укыгандай
Карыйбыз сөлге читен.

Тулы бер риваять монда, –
Тик телен аңлау кирәк.
Бу рәвеш үрмә-бормалар
Очрый бездә сирәк.

Ни сөйли билге-тамгалар? –
Булырмы таный белгән?
Орхон-Енисей язмасы
Бизәкләп төшерелгән...

№ 1 2018

ТҮГӘРӘК УЕН

Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

«Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,
моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул»

16+

Гамәлгә куючылар:

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге

Редколлегия:

Әхмәтҗанов М.И.
Бакиров М.Х.
Вәлиева З.Р.
Вәлиев Р.И.
Гайсин И.З. (Мари Эл)
Деникаева В.А. (Ульян)
Заһидуллина Д.Ф.
Каюмова Э.Р.
Локманов А.Х. (Башкортостан)
Сибагатуллин А.М.
Тукаев М.Р.
Шәрәфиева Р.Г.
Юсупов Ф.Ю.

Директор: **Фәнзилә Җәүһәрева**

Баш мөхәррир: **Илсөяр Иксанова**

Альманахның иҗат төркеме:

Гөлсинә Хәмидуллина
Алсу Тимергалина
Мөнирә Кузиева

Альманах 2014 елның 5 августында элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77-58939. Өч айга бер чыга.

Бу санны бизәүдә Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге фондындагы, Р. Якупов (тышлык), Г. Габдрахманов, Р. Миндубаев һәм авторларның шәхси архивларындагы фотолар файдаланылды.

Кәгазь форматы 60х90$^{1}/_{8}$. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды 8.02.2018 ел. Заказ С-64.
Тираж 1050 экз.

Редакциянең адресы: 420021, Казан, Тукай урамы, 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин урамы 66/33 йорт.
Телефон: 293-27-99. E-mail: tugarakuen@gmail.com

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар ур., 2.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен»нан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

КАЗЫНГАН – КАЗНА ТАБАР

Эльмира Каюмова
Ныклы гаилә – ил терәге

6
Төп йорт
Гөлсинә Хәмидуллина
Сандугачлар оясы

18
Һөнәрле үлмәс...
Раилә Хәялиева
Тамбурлы чигү

20
Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр...

24
Йола-гадәт
Эльвира Камалова
Кама аръягы керәшеннәрендә туй йолалары

© «Түгәрәк уен», 2018

28 **Малның җаен баккан белер**
Алсу Батталова
Малы барның сые бар

32 **Фидакарьләребез**
Илсөяр Иксанова
Иҗтихат иткән –
морадына җиткән

37

Хәтер-хатирә
Нажия Гыймадиева
Гомер иткән җирләр кала...

46 *Мөхәммәт Мәһдиев*
Татар халык җырларының
поэтикасы

52 **Кайтаваз**
Илгиз Кадыйров
Мәңге саекмас чишмәләр

КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

54 *Наис Гамбәр*
Мату-у-у!
(хикәя)

57 **Вакыт көзгесе**

58 **Вәгазь-нәсыйхәт**
Мөхәммәт Галләм
Байлык һәм мал

УЕНДА ЖИҢГӘН – ЖЫЕНДА ЖИҢӘР

60 **Без, без,
без идек...**

64 **Өй күрке –
аш**

Ныклы гаилә – ил терәге

Узган көздә Татарстанда яшәүче халыкларның сәнгати иҗатын чагылдыручы «Төп йорт» гаилә ансамбльләре фестиваль-бәйгесе үз эшен башлап җибәрде. Аның оештыручысы – Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге.

Республикабызда Гаилә ансамбльләре фестивале беренче тапкыр 1991 елда үткәрелә. Һәм, үзгәртеп кору чорында килеп туган кыенлыклар аркасында, ул алга таба дәвам итә алмый кала.

«Төп йорт» исеме астында яңартылган фестиваль-бәйгенең төп бурычы – гаиләләрдә элек-электән дәвам итеп килгән асыл кыйммәтләрне, ягъни, гаилә учагын, ата-бабадан калган изге йолаларны, гореф-гадәтләрне, әдәп-әхлакка нигезләнгән кануннарны саклауга ярдәм итү.

Гаилә фестиваль-бәйгесе октябрь аенда республикабыз районнары арасындагы зональ турлардан башланып китте. Гаиләләргә 5 юнәлеш тәкъдим ителде: йола күренеше, вокал, музыка коралларында уйнау, бию һәм декоратив-гамәли сәнгать.

«Төп йорт»та Татарстанның 36 районыннан 85 гаилә катнашырга теләк белдерде, шулардан 73 гаилә чыгыш ясады. Өченче турга исә арадан иң сәләтле 34 гаилә төркеме сайланды. Йомгаклау чарасы 25 ноябрьдә Питрәч районы Мәдәният йорты бинасында булып узды. Бирегә 200 гә якын кеше җыелган иде. Әлеге фестивальнең жюри рәисе буларак, шуны әйтәсем килә: җиңүчеләрне билгеләү шактый ук кыен мәсьәлә булып чыкты, чөнки катнашучы гаиләләр берсеннән-берсе көчле, талантлы иде!

Йомгаклау тантанасы искиткеч рухлы, илһамлы, җылы атмосферада үтте. Сабый балалар, урта, өлкән буын кешеләре иртәдән кичкә кадәр мәш килеп фестивальдә кайнаштылар. Гаҗәеп тамаша булды ул! Хисләргә бирелеп, берничә кат моңсуланып елап та, шатланудан көлеп тә алдык. Күңелдә туган иң зур теләк: әлеге күркәм, изге чара алга таба да дәвам итсен иде! Катнашучыларга теләкләрем: чыгышларның эчтәлегендә гаилә традицияләрен, гореф-гадәтләрен, әби-бабалардан килүче һөнәрләрне буыннан-буынга тапшыруны чагылдыру тагын да ныграк күренсен иде! Кайберәүләрнең фестивальгә формаль рәвештә генә әзерләнүен дә әйтеп үтми булмый (мәсәлән, ике туганның бергә чыгып җырлавы чараның нигезләмәсенә туры килми). Репертуарга, киемгә карата таләпчәнлекне арттырырга киңәш итәр идем. Кайбер чыгышларның режиссура ягы йомшак булды (сәхнәгә чыгу, кереп китү, композициянең драматургиясе – боларны барысын да ныклап уйларга кирәк). Чыгыш вакытында гаилә әгъзалары турындагы мәгълүмат та кыскача һәм урынлы булырга тиеш, кызыклы детальләргә игътибар итү бик тә отышлы. Аннары, гаилә ансамблендәге һәрбер кешенең сәләте күренсен иде (кемнәрдер кеше санын арттыру өчен генә чыкмасын иде). Аерым катнашучыларга башкару энергиясе җитеп бетми (талантлы икәненә шик тә юк, репертуары да, өс киеме дә менә дигән, ә чыгыш сүлпән, рухсыз, илһамсыз. Нәтиҗә, әлбәттә, көткәннән начар була. Әлбәттә, тулысынча фонограммага (плюсовкага) башкару катгый тыела!

Йомгаклап, «Төп йорт»ның гомере озын булыр, фестиваль кабызган учак җылысына алга таба тагын да күбрәк гаиләләр тартылыр дигән өметтә калам!

Эльмира КАЮМОВА,
сәнгать фәннәре кандидаты, фестивальнең жюри рәисе.

ТӨП ЙОРТ
ОТЧИЙ ДОМ

ДИПЛОМ
лауреата I степени
ДИПЛОМ
лауреата I степени

ТӨП ЙОРТ

Гөлсинә
ХӘМИДУЛЛИНА

Сандугачлар оясы

«Балаларны гармун уйнап уяттым...»

«Төп йорт» республика фестиваль-конкурсында катнашкан гаиләләр турында язуны Сарман районының Иске Имән авылындагы төп нигездә канат ярган Гайнемовлар-Гайнемөхәмматовлардан башлыйбыз. Шунысы куанычлы, фестивальнең йомгаклау концертында сәхнәнең кабатланмас бизәге булган Ана – 94 яшьлек Фатыйма әби Гайнемова бүген дә төп йортта хуҗа булып, балаларының кадер-хөрмәтен күреп, түрдә утыра. Көннең-көнендә үзе янына кайтып йөрүче балаларын ул кайнар аш белән каршы ала, хәер-догасын укып озатып кала.

Безне дә ул болдырга ук чыгып каршы алды. Һәм, вакытыбызның шактый кысан булуын чамалап, сорау биргәнне дә көтмәстән, сөйләде дә сөйләде.

– Минем хәзер ике генә шөгылем калды – намаз укыйм да гармун уйныйм. Иске Имәнгә Азалак авылыннан килен булып төштем. Ике абыем – Заһидулла белән Сәмигулла, түтиләрем бар иде. Заманасы авыр булса да, яшәүләре барыбер күңелле иде без бала чакта. Азалакта түгәрәк тау бар иде. Кар эрү белән, абыйлар, яшьләр инде, шул тау башына уенга менеп китәләр. Шуннан җәйге Кичке уеннарга тоташа аннары. Тау итәге тулы кеше. Бөтенесе матур итеп киенгән. Бәхет эзләп киткән кешеләр Урта Азиядән чуклы шәлләр, күз явын алырлык матур ситсылар алып кайталар иде.

Ул аулак өйләр, мунчада, майлы кершән савытына чүпрәк куеп, чүпрәккә ут төртеп, күз йомыш, арка чабыш уйнаулар... Мин күбрәк малайлар белән уйнадым: Мосавир, Котдус, Габдулла... Бер-ике кыз була иде тагын. Кеше нык күп бит ул чакта. Сугышка кадәр бит әле бу.

Әткәй белән әнкәй икесе дә җәтим үскән балалар, икесе дә моңга, музыкага бик дәртләр иде. Әниебез Нурлыгаян, туган елы 1895 тирәсе булгандыр дип беләм, чын курай остасы, озын көпшә курайда уйный иде. Утырмага йөргән ул курае белән. Кура үләнен махсус үстерәләр иде бит элек. Әниебез кая барса да бер дә кураен үзеннән калдырмаган. Ятим үскәнгә шулкадәр моңлы булгандыр инде, озын көйләрне уйнавы хәтердә калган. «Әллүки»не. Менә хәзер минем искә төшә... Әнинең уйнавы, җырлаулары күз алдыма килә.

Бервакыт әни кызыл бәрәңге алып кайтты да олы тазга салды. Миңа әрчергә кушкан кеше юк инде, чыра алдым да үземчә кырам. Әнкәй көйли-көйли бәрәңге әрчи. Эләктереп алдым мин бу көйне.

«Кәккүкләр дәй сайрар җир түгел лә,
Былбыллар да моңланыр җир түгел...»

Фатыйма әбинең шушы озын көйне барлык борылмаларына кадәр килеп җырлавына без таң калып тордык. Әйтерсең, каршыбыздагы 94 яшьлек Фатыйма әби авазы түгел, өй эчен тутырып ерак еллардан япь-яшь Нурлыгаянның моңлы аһәңе тарала иде...

– Кеше җырлаганга уянганыгыз бармы сезнең? – дип дәвам итте Фатыйма әби. – Кыш. Бездә урман юк, кәс яга идек. Әнкәй мичкә төрткән дә җырлый. Эреп китә идем мин аның җырлавына. Безне йокыдан бервакытта да «Торыгыз!» дип уятмады ул. Җырлый иде. Мин дә балаларымны җырлап уяттым. Бер җырлыйм, уянмасалар, гармун тартам... Мәктәптә аш

пешергәндә, интернат балаларын да гармунда уйнап, җә җырлап уята торган идем. Тәрбияче килгәнче «мылт-мылт» торып бетәләр. Шул балалар, инде зур булгач, очраганда янымда туктап, «син бит безне җырлап уята торганыең» дип әйтеп китәләр иде. Әнкәй тәрбиясе инде бу.

Азалакка күмелде әнкәй, оныклары кабер ташына да «Безнең чибәр җырчы әбиебез» дип яздырганнар.

Музыкага хирыслык әниебездән безгә дә күчкән. «Заһидулла абыйлар сине гармун итеп уйный торганнар иде», – дип сөйли иде бер танышыбыз. Абыйларның кыланмышын күргәч, әткәй Сарман базарыннан гармун алып кайтып биргән үзләренә. Абыйлар шул гармунны күтәреп урамга чыгып китәләр дә сыздырып уйнап җибәрәләр. Безнең капка төбендә зур бүрәнә бар иде, бөтен кеше шунда җыела. Менә шушы көйне уйный иде абый.

Фатыйма әби бергә гомер кичкән тальянын алып, шыңгырдатып «Авыл көе»н уйнап җибәрде.

– Заһидулла абый, сугышка киткән чагында, мине үзе янына чакырып алды да: «Апаем, шушы көйне уйна, «Азалак көе» бу, онытма! – диде. Аннары: «Сакла!» – дип тальянын миңа тоттырды. Абый сугыштан кайтмады... Хәзер дә исемә алам да уйнап җибәрәм. Кая барсам да бу көйне уйнамый калмыйм. Гармуны да шул, көе дә шул. Бу көйне уйнаган бүтән кешене дә белмим.

Сугыш вакыты булса да, яшьлек үзенекен итте, барыбер гармун күтәреп йөрдек инде. «Шахта» көен яратып уйный идем тагын. Бу – төп гармун инде. Төзәттердем моны. Завод белән Янурыс арасында «Ферма» дигән бер поселок бар иде элек, бетте инде ул, шунда Габдулла исемле кеше төзәтә иде гармуннарны.

Фатыйма әбинең кызы Вәзирә сүзгә кушыла:

«Сандугачлар оясы»н үргән Фатыйма һәм Бикмөхәммәт Гайнемовлар.

– Әни, Бикмөхәммәт атлы егет күңелеңне ничек яулады – анысын да сөйләп кит әле...

– Арттан йөрүчеләр күп иде, алар белән йөрергә вакыт юк иде. Картым белән Нөркәйдә МТСта эшләгәндә таныштык. Мин анда учетчик идем, Бикмөхәммәт, сугышта булып кайткан егет, шофер. Машинасында кер сабынын күргәч, «Их, моңа кияүгә чыксам, рәхәтләнеп кер уар идем», дип уйлап куйганым хәтердә. Аннан, «кияүгә чыккан кешемнең өендә бер каргыгы да, бер мунчасы булсын», дигән теләгем дә бар иде. Нәкъ шулай килеп чыкты да. Мунча сирәк кешедә генә, безнекенә, чират торып, 20шәр кеше керә иде.

Колхозда кыр эшләре беткәч, Чаллыдагы түтигә барып, берәр ай торып кайта идем. Гармунымны үземнән калдырмыйм. Түти редакциядә эшли. Аның өенә редактор Зәйнәп белән кызлар килә. Мин гармун уйныйм, җырлатам, биетәм. Бер көнне Зәйнәп райком кешеләрен ияртеп килгән. Мине җырлатып-уйнатып карадылар да, баянист урынына агитбригадаларына керттеләр дә куйдылар. Мина 18 яшь. Атка төялешеп, и йөрибез авыллар буйлап. И нужа чаклар инде бу! Анда күргәннәрне сөйләп бетерә торган түгел.

Түбән Каманың «Җидегән чишмә» әдәби берләшмәсендә чыгыш ясаган мизгел. 1984 ел.

Июнь ае иде. Ие, тучны, июньнең 9ы бу, 10 ы отчет көнем иде. Гармун, башка әйберләр Чаллыда минем. Авылда гармунсыз була мени! Директорга әйтәм: «Менә бу машина мине алып бармас микән?» – дим. «Барыр», – ди. Киттем кузовтагы мичкәләр арасына кереп утырып. Шофер янында Нурулла дигән кеше. Барып төшкәч, шоферга: «Абый, шушыннан алып та китәрсез инде, яме?» – дидем. Килеп туктадылар минем арттан. Тути чәй эчәргә алып керде боларны. Ә мине озатырга кызлар килгән – Асия, Җәмилә... – калганнарын оныттым инде. Берсеннән-берсе матурлар! Кулларында чәчәк бәйләмнәре – каян тапканнардыр! Ничек биетмисең боларны! Зур өй. И матур итеп бииләр!

Ярар, мине озатып калды болар. Бик матур итеп кояш баеды. Кайттык. МТСка килеп туктадык. Ул арада караңгы төшкән иде инде. Нурулла төшүгә, мин кабинага күчеп утырдым. Исәбем – яктырганны көтү. Караңгыдан да курыкмас идем – зиратны үтәсе бар. Шофер абый каравыл өенә кереп чыкты да: «Кер әйдә, суык бит», – ди. «Җук-җук, монда гына утырам», – дим. Аннары тагын чыкты. «Кер!» – ди. Кулымнан тартып төшерде.

Керсәм, бәләкәй генә бүлмә. Дөм караңгы. Анда берәү, монда берәү яткан – урын юк. Шофер абый әйтә: «Кил, ят минем янга!» – ди. Нишлим инде, бардым. Тән буе кочагында яттым. Үзем күзне дә йоммыйм инде. Бер-ике сүз сөйләштекме шунда-юкмы. Таң беленүгә, әйберләремне алып чыгып чаптым.

Шуннан... Мин Тәкермәндә фатирда торам инде, ара якын, керә дә керә бу. Фатир хуҗам Лотфулла абый да бик ачык чырай күрсәтә моңа: «Бикми, әйдә чәй эч, аш эчеп ал», – дип кенә тора. Безнең ике арада сөйләшү дә, якын килү дә юк. Хәер, бер кочаклап ятты бит инде. Бер көнне әйтте: «Кәз көне килеп алам», – диде. Килеп алды.

Төшкән нигезем дә җырлы-моңлы булды, шөкер. Монда килгәч тә сәнгатьтән аерылмадым. Бием – Гайникамал әнкәй корырак кеше иде, мәрхүмә. Әз генә ачуланырга итсә, «Әнкәй, мин бит сине Ходайдан сорап алдым!» – дия торган идем. «И-и, каян туры килә, төртенгән!» – дия иде. Ул да курайда уйный иде. Морҗага карап кына уйнап утырулары күз алдымда. Бераз уйный да: «Җә, уйна инде гармуныңны, баланы карыйм бит!» – дип, мин уйнаганга онытылып, уйга калып утыра торган иде.

Бик матур, тәртипле, сыйфатлы, авторитетлы кеше булып чыкты картым. Мин аның тавыш күтәргән чагын хәтерләмим.

Вәзирә:

– Әти турында үзе бер китап язарга мөмкин булыр иде. Хәер, ул китапның күп өлешен үзе язып та куйган инде – армиягә киткәннән башлап көндәлек алып барган ул. Анда хроника гына түгел, беркемгә әйтә алмаган әрнү-кичерешләр дә... 1939 елда армиягә китә эти. Свердловскида автобатальонда хезмәт итә. 1941 елда авыр артиллериягә техник-механик итеп куела. Июнь аенда алар дивизия белән Көнбатышка таба кузгалалар. 22 июнь көнендә Витебскида эшелоннан хәрби техниканы бушатканда, дошман самолетлары бомбага тота башлый. Сугыш башланганын менә шунда аңлыйлар. Алга таба сугышның чын мәхшәре башлана – газаплы чигенүләр, атакага барулар, оборона тотулар, сугышчан дусларны югалту ачысы... Әти ЗИС-5 машинасы белән техникага бензин ташый. Ә 1942 елда арадан 6 шоферны сайлап алалар да, яшерен рәвештә, яңа гына уйлап табылган корал – «Катюша» серләрен өйрәнергә җибәрәләр. Аннары – Сталинград. «Сталинград язмышын «Катюша»лар хәл итте, – дип сөйли иде ул. – «Катюша»дан беренче тапкыр ут яудыра башлауга ук әлеге коралның көчен сиздек без. «Катюша»ны немецлар ничек кенә кулга төшерергә тырышса да, моңа мөмкинлек тудырмадык. Чигенгәндә, алып китә алмасак, йә яндырып, йә суга батырып, йә сүтеп китә идек. Мин, атышлар вакытында, дошманның снарядларыннан качу өчен, машинаның урынын гел күчереп тора идем».

Бер һава һөҗүме вакытында бөтен батареялары кырылып бетә. Әти аңына килә һәм яралы командирын аулак урынга яшереп, коткарып кала. Командир аны орденга тәкъдим итә. НКВД кешесе исә: «Ну что, татарин, орден захотел? Не орден, а пулю в затылок получишь!» – дип яный. «Кайчан атып үтерерләр икән дип куркып йөрдем. Орденны минем янда утырып йөри торган егеткә бирделәр. Сугышта татарларга рәт булмады», – дип сөйләгән ул әнигә. 1944 тә Латвиядә бомба шартлаганда кыйпылчык тиеп, әтинең аягындагы өч бармагы өзелә, кулы, бите яралана. Кар өстендә аңсыз яткан хәлдә табып алалар аны. Аннары – госпитальләр. 1945 елда 2нче группа инвалид булып авылга кайтып төшә. Шофер, аннары инженер-механик була, МТС башлыгы дәрәҗәсенә күтәрелә. Һәм, кайбер көнче кешеләрнең нахак сүзләреннән, әләкләреннән туеп, гади комбайнер булып урнаша. Лаеклы ялга чыккач та бераз эшләп йөрде әле. Эшен бер дигән итеп башкара иде, техниканы белә, тырыш, тәртипле.

Әти безнең өчен бик зур абруй-дәрәҗә булды. Берәр нәрсәгә рөхсәт аласы булсак, тын да алмыйча әтинең җавабын көтә идек без. Әни дә аннан узып берни хәл итми. Әти әйткән – закон. Әтинең ачулану, орышу сүзе дә бик кыска иде: «Чурту, кызый!», «Чурту, малай!» Бу сүзләр безнең өйдә бик сирәк яңгырады.

Фатыйма әби:

– Авыл халкы бик хөрмәт итте үзен. Ул китеп баргач, әллә ничә еллар вафатына ышана алмый йөрделәр әле. Безнең өчен генә түгел, бөтен авыл өчен зур югалту булды ул.

Флүр

Балалар турында сөйләшүне алты баланың өлкәненнән башлап җибәрдек. Флүрә белән Вәзирә бер-берсенә карап алдылар да: «И-и, абыйны беләсездер инде... Флүр Гайнемөхәммәтов бит инде. Гомере буе сәхнәдә инде безнең абый. Үзе генә түгел, гаиләсе – балалары, оныклары да», – дип, гаилә альбомы эчендәге төрлесе төрле елларга караган гәҗитләрдән кисеп алынган мәкаләләрне күрсәтә башладылар. Ул арада Фатыйма әби сөйләп китте:

– Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, дигән борынгылар. Балаларыбыз музыкадан гел аерылгысыз булды. Бием әнкәй курайчы иде, дидем бит. Бервакыт безнең малайлар, Флүрләр инде, әбигә курай җыябыз дип, басуга киткәннәр. Кәҗә сакалы бик зур булып үсә иде анда, шуны курай үләне дип белгәннәр. Ул чакта җирне бик тирән сөрәләр иде, кызыл балчыкка кереп батканнар бит болар! Чыга алмый азаплана торгач, кич җиткән. Ярый әле авылдашыбыз Ясир абый күреп алган үзләрен. Басуда ниләр кыймылдый микән дип, кызыксынып, барып караса, безнең малайлар. Төн җиткәндә китереп бирде боларны: балчыкка батканнар, ә кулларында кәҗә сакалы! Ягылган мунча бар иде, алып барып җебетеп, юындырып, кочкә кеше ясадык!

Флүрем арада аерым бер тиктормас бала булды. Бик кызыксынучан иде. Бар нәрсәгә, хәтта гап-гади кыргаяк, кырмыскаише бөҗәкләргә дә олы бер дөнья итеп, шаккатып карый иде ул. Әнә шул кызыксынучанлыгы аркасында үзенә этисеннән эләккәли дә иде. Берсендә, шуклыкларына түзә алмыйча, бием әнкәй моны базга ябып куйган. Берзаман «Бах! Бах!» килгән тавышка баз капкачын ачса, 60 кукәйне стенага бәреп ватып бетереп утыра, үзе сөенеп «Аттым!» – дип кычкыра икән. Икенчесендә әбисе моны мунчага бикләп куйган. Без эштә бит инде. «Гөлекәем, әйдә чык!» – дип, баланы алып чыкса, Флүрнең кесәләреннән шып та шып бака коела ди.

Ул шуклыклар чоры тиз узды ул. Артыннан бер-бер артлы кечкенәләр туа башлады. Флүр инде абый роленә керде.

Флүр белән Рәзинә Гайнемөхәммәтовлар дуэтына, әнә шул рәвешле, балалары Ирек белән Иркә дә килеп кушыла.

Вәзирә:

– Флүр абый безнең өчен чын мәгънәсендә авторитет булды. Гармунда да аңа карап өйрәндек. Абый, сигезне бетергәч, Алабуга культура-агарту училищесының «Халык уен кораллары» бүлегенә укырга керде. Бервакыт радиодан Флүр абыйның гармунда уйнавын тапшырып яталар. Шуны ишеттек тә, нишләргә белмибез, үрле-кырлы киләбез. Радио каршына килеп: «Абый, абый, син безне ишетәсеңме? Без сине ишетәбез! Кайда соң син? Күрен инде!» – диеп кычкырабыз.

Аннары абый Түбән Кама музыка училищесында укый башлады. Һәм Флүрә апа белән мин дә аның артыннан иярдек...

...Һәм менә шуннан Түбән Кама шәһәренең татар дөньясына Флүр Гайнемөхәммәтов дигән талантлы егет килеп керә. 1969 ел була ул. Флүр БСИ заводында музыка җитәкчесе булып эшли башлый. Ике елдан калада тагын бер яшь гаилә, ә сәхнәдә Флүр белән Рәзинә Гайнемөхәммәтовлар дуэты барлыкка килә.

Тынгы белмәс егет, авыллардан килгән егет-кызларны җыеп Кечке уеннар, татар «пятачок»лары оештыра башлый. Төрле түрәләрнең ишекләрен таптый торгач, аннан-моннан иске уен кораллары юнәтеп, «Ләззәт» татар эстрада ансамбле оештыра. Ансамбль составы тулы булса да, янына килгән бер генә егет-кызны да кире бормый ул: һәрберсенең нинди дә булса талантын табып, «өстерәп чы-

гара». «Ләззәт» яшьләр өчен чын мәгънәсендә тәрбия мәктәбе дә була. Монда хәмергә дә, әшәке сүзгә дә, килешсез гамәлләргә дә урын юк – Флүр абыйлары белән Рәзинә апалары кабызган җылы учак тирәсенә елышкан яшьләр җырлар-биюләр өйрәнә, уен коралларын үзләштерә, иң мөһиме, чын татар мохитендә аралаша-яши.

Вәзирә:

– Авылларга концертларга йөргәндә автобус тулып кайтып төшәрләр иде. 25 кеше! Ишегалды туп-тулы. Мунча, келәт – кайда мөмкин, бөтен җирдә урын җәелә. Бездә кунып, ял итеп, икенче көнне башка авылга чыгып китәләр. И күңелле чаклар иде инде!

«Ләззәт» республикада гына танылып калмый, Ижау, Мәскәү, Ташкент, Киев кебек шәһәрләргә дә чыгып китә. Төрле дәрәҗәдәге фестиваль, конкурсларда катнаша, халык эстрада ансамбле исемен яулый. Еллар уза тора. Ансамбльдә канат ярган яшьләрнең алдагы буыннары, төрлесе-төрле якка таралып, остазлары кебек үк мәдәният-сәнгать өлкәсендә хезмәт итә.

Флүр белән Рәзинә Гайнемөхәммәтовларның уллары Ирек белән кызлары Иркә дә музыка сәнгате юлына кереп китә. Ирек бүген «Ләззәт»тә әтисенең төп таянычы булып торса, Иркә – профессиональ скрипкачы буларак танылуга ирешкән музыкант. Ә инде Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Флүр Гайнемөхәммәтов җитәкчелегендәге «Сандугачлар оясы» дигән, 7 кешедән торган гаилә ансамблен бүген чит илләрдә дә аяк өсте басып алкышлыйлар. Республикакүләм, Бөтенроссия, Халыкара бәйгеләрдә җиңеп яулаган Дипломнарның исәбе юк. Талант белән тырышлыкны бергә кушып, армый-талмый туган халкыбызга хезмәт итүдән ямь табып яши алар.

Мәүлит

Беркемнең дә касәсе буш түгел, диләр. Икенче бала – Мәүлит – дәртләнеп эшләп, гаиләсендә кадерле ир, әти кеше булып сөенеп-куанып яшәгән чорында, 43 яшендә каты авырып китеп вафат була.

Фатыйма әби:

– Абыйсы Флүр белән аерылгысыз булып үстеләр. Дусларча көрәшеп, көч сынашып. Мәүлитем, ничек дип әйтим икән... әүлия кебек бала булды ул. Шулкадәр акыллы, тәртипле. Мәктәптә укыганда, укытучысы Хәдичә: «Фатыйма апа, бөтен бала арасында үзгә ул Мәүлит. Мин аны аңлата да алмыйм. Ул ничек киенә – калган малайлар да аныңча киенә башлый, үзен ничек тота – тегеләр дә аны кабатлый. Аңа ияреп спорт белән шөгыльләнә башлыйлар», – дия торган иде. Үз-үзенә карата шулкадәр таләпчән булды. Һәр эшкә дә бик тырыш булды. Ул чакта бит әле күп итеп чөгендер җире бүлеп бирәләр иде эшкәртергә. Балалар Мәүлиткә ияреп чыгып китәләр дә, бөтен кешедән алда бетереп, «Ура!» кычкырып кайтып керәләр иде. Гармунда уйнарга өйрәнсә дә, музыка дип әллә ни исе китмәде, техника ярата иде. Радиотехника белән кызыксынды. Бөтен өйне тимерчыбык белән тутырды. Бервакыт, дус малае белән шул чыбыклар арасында әвәрә килә болар. Кинәт шартлау яңгырады да, электр тогы Мәүлитне ишек янына алып ыргытты. Ярый үзенә зыян килмәде тагын.

Пропеллерлар куеп агач самолетлар ясыйлар иде. Ишегалды тулы малай-шалай инде ул чакта. Иң матур очкан самолет Мәүлитнеке була торган иде.

Вәзирә:

– Берсендә иске патрон эченә дары тутырып, ничек шартлавын белү өчен, аны мунчаның кызган ташына куйган абыем. Шартлаганда бөтен битенә дары чәчрәгән, ничек күзенә тимәгәндер, Ходай саклаган инде.

Әти шахмат алып кайткач, баскыч төбе малайларның шахмат турнирына әйләнде. Абый һәркемгә мат куя иде.

Спорт белән бик дус булганга, армиядән кайткач Әлмәт физкультура техникумында укып чыкты абый. Сарманда ДОСААФта эшли башлады, футбол, волейбол командалары оештырды. Шуннан, аны күреп алып, милициягә эшкә чакырдылар. Теләнче Тамакта участок инспекторы булып эшләгәч, район үзәгенә тикшерүче итеп куелды. Югары белем алып, подполковник

Танылган гаилә ансамбленә оныклар да өстәлә.

дәрәҗәсенә күтәрелде, өлкән тикшерүче булып эшләде.

Фатыйма әби:

– Мин аңа баштук әйтеп куйдым: «Улым, безгә Конституция укыттылар. Мин беләм, аның төрле пунктлары бар. Кешенең начарлыгы булса да, җәзаның җиңелрәген бирергә тырыш!» – дидем. Берсендә, әле Академиядә укыган чагында, өч көн ялым бар, бәрәңге алышам, дип кайтып төште бу. Имтиханнарга әзерләнәсем бар, ди. «И улым, – мин әйтәм, – хәзер юлыңа күршедән акча алып чыгып бирәм, чыгып кит», дидем. 75 сум акча алып чыгып бирдем. Китте. Имтиханын биреп кайтты да: «Рәхмәт, әни!» – диде... Ул гадел булды. Андыйларга бу дөньяда яшәве бик авыр бит... Берсендә үзәге өзелеп әйтте: «Бу райком секретарьларын ник алыштырмыйлар икән! Минзәлә белән Мөслим арасында ике ел йөрдем, «Кирәк түгел!» дип, яптылар да куйдылар эшне!» – диде. Бик вакытсыз китте бу якты дөньядан. Гаиләсе, өч баласы калды. Аның эшен улы Руслан дәвам итте. Ул да подполковник дәрәҗәсенә күтәрелде, акыллы, гадел эш итте.

Вәзирә:

– Үзе шаян да, үзе ифрат җитди дә Мәүлит абыебызны бик сагынабыз. Аның киңәшләре, акыллы сүзләре искә төшә. Гомеренең соңгы елларында үзлегеннән өйрәнгән баянда уйнап, моңланып утырулары күз алдыннан китми...

Флүрә

– Әле дә күз алдымда, безнең өйдә ике өстәл тора иде. Берсе аш өстәле. Икенчесендә тегү машинасы һәм музыка уен кораллары: тальян, хромка, баян, скрипка, мандолина, курай... Әти, эштән кайткач, яткан көенчә генә, кызыл төстәге хромкабызда «Арча көе»н уйный иде. Шул көйне тыңлаганда күзләремнән яшьләр бәреп чыга торган иде минем, – дип сөйләп китте Флүрә ханым. – Үземнең беренче уйнаган көем – «Барыня». Аны миңа әни өйрәтте. Өйрәнгәч, тамашачы каршында чыгыш та ясыйсы килә бит инде, мин «сәхнә»гә – лапас төбенә чыгып басам да уйнарга тотынам. Мунчада уйнарга бик ярата идем – анда бит җылы, рәхәт.

Кечкенәдән үк җырларга да бик ярата идем. Туктаусыз җырлап йөрүемә эче поша башлап, әтиебез кайчак: «Тукта инде, колакны тондырасың!» – дип ачуланып та ташлый иде. Беренче класста Рафаиз исемле малай белән «Туган тел»не җырладык. Үртәп тә карадылар инде шуннан соң! Икенче класста инде хромка күтәреп сәхнәгә чыктым. Өченчедә күрше Тәкермән авылында гармунда уйнап классташларны җырлаттым. Башлангычта укытучыбыз Сәлимә апа мандолинада өйрәтә башлады. Бишенче класста без мандолина сатып алдык.

Фатыйма әби кызлары Вәзирә, Мөнирә, Флүрә белән. 2011 ел.

Аннары чират скрипкага җитте, анысында тарих укытучысы Заман абый Кәрамов уйный иде. Ә ул чакта баянның дәрәҗәсе бик зур! Анысын безгә әти белән бик дус булып яшәгән авыл советы рәисе бирде.

Бишенчедә укый идем. Салих-Тукай авылына чикләвек җыярга бардым. Туганыбыз Кәраметдин абыйларга. Кич клубта кино булды. Кинодан соң бер кызны сәхнәгә җырлатырга чыгардылар. Сары чәчле, калын иренле. Минем гармунда уйнаганны беләләр, кызга уйнарга куштылар. Ул «Йөрәк сере»н җырлады. Еллар узгач Зөһрә Сәхәбиева дигән олы җырчыбыз булып танылачак кыз булган икән ул!

...Ул арада Флүр абыебыз Алабуга культура-агарту училищесын тәмамлап Сарманга эшкә кайтты. Аның киңәшен тыңлап, мин 9 класска Сарманга килдем, андагы музыка классында укый башладым. Өстә телогрейка, аякта галош. Ашарга бар, кияргә кием юк иде. Шулкадәр уңайсызлана идем үземнең кыяфәтемнән. Аннары әни үзенең иске пальтосын бирде. Минем хыял Казандагы музыка училищесына керү иде, әмма музыка мәктәбе белемем юк. Шул вакытта Казан дәүләт консерваториясе каршында музыка курслары ачтылар һәм һәр районнан берәр кешене сайладылар. Курсларга Сарманнан мин үттем. Укулар педагогия институтының музыка факультетында оештырылган иде. Баян классын Рәгъде Халитов алып барды. Минем

төп кимчелек – русча белмәү. Шуның аркасында гел кимсенеп йөрдем. Бер көнне, өлкән укытучыбыз Мукьянов янына бардым да: «Минем берни дә чыкмас ахры, җырларга да тавыш юк, булмый миннән», – дидем. Ул исә мине бастырып куйды да, «йәле, менә болай ит», «тегеләй ит» дия-дия, әллә кайдан гына минем тавышымны «өстерәп чыгара» башлады. Шуннан соң: «У вас все от Бога», – диде һәм консерваториянең хор-дирижерлык факультетына барырга кушты. Кая инде анда бару! Әлмәт музыка училищесына юл тоттым. Музыка мәктәбендә укымаганлыктан, аннан кире бордылар.

1969 елда Түбән Камада музыка училищесы ачылды. Белем алу теләге шулкадәр көчле иде, Флүр абыем белән шунда барып кердек. Безнең арттан сеңелебез Вәзирә дә килде. Кая барсаң да кара сакалың артыңнан калмый дигәндәй, монда да рус телен белмәүдән интектек. Музыка дәресләрендә бер проблема юк, инде рус әдәбиятына керсәк, авызга су капкан кебек булабыз. Мине хәтта тел белмәү аркасында училищедан чыгарасы да булганнар, музыка укытучылары яклап алып калган. Укып бетергәч, Җәлил бистәсендәге музыка мәктәбендә баян һәм фортепиано буенча укыттым. Кияүгә чыккач, Чаллыда музыка курсларында фортепиано дәресләре алып бардым; бала тугач инде музыка хезмәткәре булып балалар бакчасына күчтем. Аннан колакка операция ясатып, музыкадан читләшергә туры килде. Алга таба мин бөтенләй башка юнәлешкә борылып, техникумда экономист һөнәре алдым. Һәм төрле-төрле урыннарда – хәрби комиссариатта, кафеда, ашханәдә, ит комбинатында зур урыннарда эшләдем.

Күңелдәге истәлекләрне актара башласаң, әллә ниләр калкып чыга. Комбинатта эшләгәндә үзебезнең продукция белән Кызыл Байракка Сабантуйга бардык. Шунда Казаннан килгән артистларга да зурлап сый-хөрмәт күрсәттек. Табын артында Илһам Шакиров «Авыл көе»н җырлап җибәрде, ә Рөстәм Вәлиев юк, каядыр китеп барган. Башлыгыбыз, «Әйдә, уйна!» – дип, баянны миңа тоттырды. Уйнадым! Җырга Хәйдәр Бигичев та кушылды.

...Һәм, язмышының катлаулы һәм сикәлтәле байтак еллары үткәч, янә «юл башына» әйләнеп кайта Флүрә.

2012 ел. Кәүҗияк авылында яшәүче туганнарына баргач, хуҗа кеше сарайдан тузанга баткан гармун өстерәп чыгара. Телләренә баскалый гына башлый Флүрә, кинәт күңеле өермәдәй кузгала да китә... Шуннан бирле гармуннан аерылмый ул. Атаклы гармунчыбыз,

Фатыйма Гайнемова гомере буе балалары белән сәхнә тота. Баяннарда Вәзирә белән Флүр. 1988 ел.

дусты, адашы Флюра Хөрмәтова белән очрашканда икесе ярышып уйныйлар алар хәзер. 2015 елда Чаллы шәһәрендә узган «Уйнагыз, гармуннар!» фестивалендә беренче дәрәҗә диплом яулый. Зона смотрларының, фестиваль, конкурсларның берсеннән дә калмый – аның гармунының газиз халкыбызга җиткерәсе көйләре, моңнары мөлдерәп тора әле!

Мөнирә

Арада йомшаклыгы, сабырлыгы, хисслелеге белән аерылып торган бу баласын әти кеше аерып ярата, әледән-әле алдына утыртып куя торган була. Курчак кебек чибәр Мөнирә исә, әтисе идәнгә алып куйганчы, кымшанмыйча утыра да утыра. Әнисенең тегү машинасында ялгыш бармагын «теккәннән» соң да, мич башыннан егылып төшкәннән соң да кычкырып еламый бу бала, эченнән генә сызланып, шыңшып утыра.

Абыйлары, апаларыннан күреп, гармунда уйнарга өйрәнә. Ә Флүрә апасыннан мандолинада өйрәнеп алганнан соң, шушы уен коралын бигрәк тә үз итә. Ләкин Мөнирәнең уен коралларына әллә ни исе китми, ул җырларга ярата. Берничә югарылыктагы тавыш белән җырларга сәләтле Мөнирә дә Түбән Кама музыка училищесына барып керер дип торганда, ул, үзе Казанга барып, документларын Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетына илтеп бирә. Мәктәптә барлык фәннәрне дә яхшы билгеләргә генә укып килгән кыз институтта үзенең зиһене белән сокландыра. Институтны тәмамлагач, Сарман урта мәктәбендә укытып ала һәм алга таба Чаллы шәһәренә килеп, Үзәк почта бүлегендә, Чаллы ит комбинатында, «Джойта»

Кызлар триосы: Мөнирә, Флүрә, Вәзирә. 1985 ел.

шоколад фабрикасында җаваплы урыннарда эшли.

– Кайда гына эшләсә дә, аны искиткеч җаваплылыгы, тирә-юнендәгеләргә карата гаделлеге өчен хөрмәт итәләр, – ди Флүрә. – Лаеклы ялга чыгып, тынгысыз тормыш мәшәкатьләреннән арынып, хәрби сукмактан киткән улының уңышларына сөенеп яшәр чак җиткәч кенә, менә әле бер ел элек кенә барыбызны калдырып бакыйлыкка күчте.

Мөнирәбезнең иң яраткан җыры «Мәк чәчәге» иде. Флүр абый җитәкчелегендә оештырылган гаилә концертларында да гел шушы җырны башкара иде ул. Моңлы тавышы колактан китми... Үзәкләр өзелә... Өч кыз трио булып башкара торган җырыбызның исеме белән: «Утыр әле яннарыма!» – диясе килә...

Вәзирә

Вәзирә гаиләдә бишенче бала. Әнисе һәм өлкән туганнары сөйләвенчә, кечкенәдән үк көйләр суза башлый ул. Гармун, баян телләренә баса-баса ритм чыгарып, әле сөйләшә башлаганчы ук, үзенең шул «уңышларына» бик канәгать кыяфәттә йөри торган була. «Әле ике яшьлек чагында ук, өстәлгә менеп, баянны ике кулы белән бер якка тарта торган иде, – дип сөйли Флүрә. – Тарта торгач, өстәлдән идәнгә мәтәлеп төшә. И, этидән эләгә иде инде безгә шуннан соң! Өч яше тулганчы кунаклар алдында урындыкка басып җырлый башлады инде». Фатыйма апа өстәп куя: «Бервакыт шулай, Вәзирәмне өйдә калдырып, йорт тирәсенә чыгып киттем. Суга барыр алдыннан, тукта-ле, бала нишли микән дип өйгә керсәм, шылт иткән тавыш юк. Анда карыйм, монда карыйм – күренми бит! Кинәт өстәл астында нидер кыштырдап куйды. Баянны өстерәп алып кергән дә телләренә баскалап утыра бала. «Булды бу!» дидем дә тынычлап чыгып киттем инде».

Вәзирә алты яшендә хромкада уйный башлый. Беренче тапкыр сәхнәгә район смотрында чыга. Дүртенчедә укыганда Азалак авылында, үзе гармунда уйнап, «Әтиемә хат язам» җырын башкарып, беренче урынны ала. Шуннан соң инде озын тәнәфес саен укучыларны гармунда уйнап җырлату, биетүләр китә. Мәктәптә үткәрелгән чараларда, ярышларда гел алдынгылар рәтендә йөри Вәзирә.

– Авылларда Кичке уеннар гөрләгән чор бу. Бездә алар авыл башында, ындыр артында уза иде, – дип искә ала үзе. – Сигезне тәмамлаганда болында яшьләрне баянга биетә башладым. Болыннан кайтышлый, яшь-җилкенчәк авыл урамнары буйлап җырлап узабыз, ара-тирә биетеп

Төп йортның илаһи моңга күмелгән мәле. 2017 ел.

тә алам үзләрен. Өй тирәсендә су сибү, утын өю кебек эшләрем булса, мине тизрәк Кичке уенга алып чыгу өчен, кызлар килеп эшләремне эшләшәләр иде. Ә балачак хыялым табиб йә укытучы булу иде минем.

Флүр абыйсы белән Флүрә апасы Түбән Кама музыка училищесында укый башлыйлар. Алар икенче курста укыганда Вәзирә дә шушы уку йортының хор-дирижерлык бүлегенә барып керә. Һәм, хор җитәкчесе, сольфеджио, җыр, фортепиано укытучысы белгечлеге алып, Сарман музыка мәктәбенә кайта да башыаягы белән эшкә чума. Коллектив белән агитбригада оештыра. Концертларда үзе төрле уен коралларында уйнап, җырлап, биеп чыгыш ясый. Шушы чорда ул композитор, музыкант, уен кораллары ясау остасы Ифрат Хисамов белән танышып, остадан курай, кубыз кебек кораллар сатып ала. Алга таба алар Ифрат Хисамов белән 60 кешелек хор һәм фольклор ансамбле оештырып җибәрәләр. Әлеге хор Бөтенсоюз хор җәмгыятенең 100 еллыгы уңаеннан Мәскәүнең Съездлар сарае сәхнәсендә чыгыш ясауга ирешә.

Районлагы һәр мәдәни чараның үзәгендә кайный Вәзирә. Сарман данын үстерүгә үзеннән саллы өлеш кертеп, Чаллы шәһәренә күченә һәм биредәге Балалар һәм яшүсмерләр үзәгенә өстәмә белем бирүче педагог булып урнаша. Нәтиҗәләр озак көттерми – Үзәктә аның тарафыннан оештырылган «Гөлләр» фольклор ансамбле, республикакүләм смотрда катнашып, беренче дәрәҗә дипломга лаек була. «Ничек кенә булса да, үзебезнең татар балаларын сәхнәгә чыгарырга, зур-зур фестиваль-конкурсларда катнаштырырга, сәхнәдә татар телен яңгыратырга тырыша идем, – дип искә ала ул бүген. – «Опять татары!» – дип каршы алалар иде дә, чыгышыбыздан соң гөрләтеп кул чабалар иде аннары. Балалар белән бергәләп ясаган чыгышларыбыз шәһәр бәйрәмнәренең чын бизәге була торган иде. Чаллыда мин политехник көллияттә дә студентлар белән җыр, бию, фольклор ансамбле оештырдым. Аерым җырчы солистлар әзерләдем. Үземнең ике улымны тәрбияләү өстенә, тагын күпме балага үземнең җан җылымны биргәнмен, күпмесен җитәкләп музыка сәнгате дигән гүзәл дөньяга калып кергәнмен, аерым җырчылар әзерләгәнмен. Хәзер аларның сәнгатьтәге уңышларына сөенеп туя алмыйм».

Вәзирә Чаллыда «КамАЗ» Мәдәният йортының «Сердәш» җыр ансамблендә җырлый. Беренче соло концерты да шушы Мәдәният йортында уза. Җыр – аның гомерлек юлдашы. Хәзер дә концерт, кичәләрдә булсын, Сабан туйларында булсын, Вәзирәнең һәр чыгышы көтеп алына. Ә хезмәтеңнең кирәклеген тоеп, нәтиҗәсен күреп яшәү үзе зур бәхет бит ул. Төп йортта сине көтеп торучы әниең, синә җан җылысын биреп торучы гаиләң, туганнарың булганда ул бәхет тагы да зурая...

Төмәндә узган федераль Сабантуйда Гайнемөхәмммәтовлар Президентны да бию түгәрәгенә ала. 2013 ел.

Әнүр

Әнүр гаиләдә алтынчы бала, ягъни төпчек. Өлкән туганнары барысы да гармунда уйнагач, ул да кечкенәдән үк «көй эзләп» гармунны өстерәп йөри. «Кунаклар алдында куела торган концертларда әни бию көен уйный башлый да, балалар бер-бер артлы биеп китә. Чират Әнүргә житкәч, ул да кулларын биленә куеп, көйгә басып биеп китә торган иде. Башкалар җырлаганда кушылып җырларга тырыша иде. Аннары мин аңа гармунның бас ягыннан «Барыня»ны уйнарга өйрәттем, – ди Вәзирә апасы. – Биш-алты яшьләрендә гармунда башка көйләрне дөрес итеп чыгара башлады. Һәм бик тә, бик тә җырларга ярата иде. Әтиебезнең 50 яшьлеге уңаеннан, миңа кушылып, «Әнием, синә» җырын җырлавына бик канәгать булып йөргәне хәтердә». Алга таба җырлау һәм уен коралларында уйнау гел янәшә бара. Озын тәнәфесләрдә гармунга укучыларны инде Әнүр биетә башлый. Мәктәп чорында үткәрелгән барлык мәдәни чараларның үзәгендә тора. 9-10 классларда укыганда абыйларыннан ул чакта бик тә модалы булган гитарада уйнарга өйрәнеп ала. Һәм үз тирәсендәге малайларны да гитарага

өйрәтергә тотына. Кич капка төбендә гитарага кушылып җырлап утырулар гадәти күренешкә әйләнә, ә кичке уеннарда Әнүр кулына баян ала. Чаллы шәһәрендә аз гына эшләп алу чорында да ул, үз тирәсенә татар яшьләрен туплап, «пятачок»лар оештыра. Эштән соң, кичләрен уен коралларында уйнап, җырлап, күңелле һәм файдалы итеп үткәрәләр алар.

Әнүр Чистай авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, техник-механик һөнәре ала һәм Сарманның «Сельхозтехника» оешмасында шофер булып эшли башлый. Менә 38 ел инде ул руль артында. «Кураем һәрчак машинамда йөри, – ди Әнүр. – Ял иткән араларда курайда уйнап алсам, хәл кереп китә». Озак вакытлар, «Сельхозтехника» оешмасы каршында оештырылган җыр һәм инструменталь ансамбльдә үз репертуарын туплап, солист булып җырлап йөри ул. Оешмада узган һәр чарага, район күләмендәге бәйрәмнәргә зур җаваплылык белән әзерләнәләр. Күпсанлы лауреат дипломнары, бүләкләр алалар. Чаллы телевидениесе оештырган «Безнең җырчы» төбәкара конкурсында катнашкан Әнүрнең финалга чыгуы, Гала-концертта чыгыш ясавы төп йорттагы әниләре өчен дә, туганнары өчен дә бик олы шатлык була. Бүгенге көндә дә Әнүр, эштән кайткач, Сарман Мәдәният йорты каршында оештырылган «Илек» җыр, бию, уен кораллары ансамбленә ашыга. Ул анда җырчы, уен коралларында уйнаучы буларак чыгыш ясый. Шул ук вакытта ансамбльнең концертларын да оештырып йөри. Сәнгатькә булган мәхәббәт балаларына гына түгел, оныкларына да күчә баруын күреп сөенеп яши ул. Балаларына кунакка килү белән, кулына гармун ала.

... Фатыйма әби, борынгы горефне саклап, безне озатырга да чыкты. Болдырга елышып ук утырган наратка сәерсенеп карап торуыбызны чамалады ахры:

– Җәтим нарат иде бу. Берәүләрнең бушап калган йорт урынында ялгыз утырып калган. Картым алып кайтты, бәләкәй генә ботак хәтле иде. «Карчык, утыртып куйыйк, моңаеп утыра, анда үсә дә алмас инде ул», – диде. Инде әнә баһадир чаклы булды! Тәрәзәләрне дә каплый. Ничек кисәсең инде – үзебезнеке, шушы нигезнеке бит ул хәзер...

Намазымны укыйм да: «Аллага шөкер, бүген дә укыдым бит! – дип сөенәм. – Яшим бит әле! Төп йортымда яшим!» – дим. Ахирәтләрем белән ашларга йөрибез. Җыелып күңел ачабыз. Аларга да гармун уйныйм. «Азалак көе»н, «Карабай»ны, «Әнисә»не... Аннары элеккеге җырларны сузам. «Әллүки»не:

И мөкатдәс моңлы сазым!
Уйнадың син ник бик аз!
Син сынасың, мин сүнәмен,
аерылабыз ахрысы...

Кешесез тора алмыйм мин. Кеше килмәсә, әзерләгән ризыгым да тамагымнан үтми. Шуңа, өемнән көн дә кеше өзелми. Сез дә тагын килерсез бит әле? И, рәхәтләнеп сөйләшеп тә булмады. Тән утырып сөйләшербез дигән идем! Көтеп калам, җәме!

...Әлбәттә, килербез, Фатыйма әби! Тәрәзәңдә утың гына сүнмәсен!

Кодалар, кодагыйлар... Флүр белән Рәзинәнең ике як туганнары бергә җыелгач төшкән фото. 1982 ел.

Бардыр тегәрҗепләрем,

Мин Кукмара районының Сәрдекбаш авылында тудым; гаиләбездәге өч кыз арасында иң олысы. Әти-әнием терлекче булып эшләделәр. Хәзерге көндә алар лаеклы ялда. Безнең әни (мин белә башлаганнан бирле) аз гына вакыты булса чигү алып утыра иде. Аннан күреп, мин дә, әбидән материал кисәге сорап, әни янына килеп утыра идем. Әүвәл әни миңа берәр яфрак яки чәчәк рәсеме төшереп бирә торган иде. Әкренләп-әкренләп кулым күнегә башлады. 9 яшемдә инде бу һөнәрне шактый үзләштереп өлгергән идем.

1990 елда без өй салып башка чыктык. Әни белән икәү, иң беренче эш итеп, өй тәрәзәләренә пәрдә чигеп куйдык. Шуннан мин чын-чынлап чигү белән шөгыльләнә башладым. Яшь киленнәргә килен сөлгеләре, армиягә китүчеләргә кулъяулыклар, кияүгә чыгучы кызларга бирнәлекләр (мендәр тышлары, ашъяулыклар, баш яулыклары) чигеп бирә идек. Бу күренеш хәзер дә дәвам итә. Шөкер, безнең якларда чигүчелек шактый нык сакланган әле. Кияүгә чыгучы кызлар, заказ биреп, хәзер дә бирнәгә мендәр тышлары, ашъяулыклар чиктереп алалар. Армиягә китүче егетләр һаман да чигүле кулъяулыклар асып урам әйләнә.

Чигүчелек һөнәре безгә әниемнең әнисеннән – әбием Ибраһимова Гөлбану Сәгетдин кызыннан күчкән. Ул хәзер 93 яшьтә. Тумышы белән Чишмәбаш авылыннан. Аның балачагы, яшьлеге авыр елларга туры килә, шуңадыр, ул аларны искә төшерергә яратмый. Бик яшьли ятим калган, үги әни белән үскән кыз кечкенәдән үк кулына энә белән җеп ала. «Үземне белә башлаганнан бирле энә белән җеп кулымнан төшмәде», – ди әбием. Ул чигә дә, тегә дә. Баштарак үзенең балаларына киемнәр тегеп киертсә, аннан без оныкларына тегеп бирә иде. Безнең балалар да әбиебез теккән бәби башлыклары, башмаклар киделәр.

Мин үземнең чигү эшләрем белән Республикабызда үткән бик күп Сабантуйларда катнаштым. Хәтта федераль Сабантуйларга, Казахстанда уздырылган Сабантуйга да алып бардым чигүләрдән торган күргәзмәмне. Хәзер дә төрле чаралада даими катнашып торам. Үткән ел уздырылган «Төп йорт» гаилә фестивалендә дә II дәрәҗә лауреат исеме алып кайттык. Халык һөнәрчелегенең, шул исәптән чигүчелекнең дә кадере югалмавын, киресенчә, арттаннан-арта баруын күреп, куанып яшим. Күз нурларыбызны түгеп, күңел җылыбызны биреп башкарган кул эшләребез һәрбер өйне бизәсен, тормышыбызга ямь өстәп торсын иде!

Чулпан ГАЛИЕВА,
Кукмара районының Яңа Сәрдек клубы мөдире

Чигү чигәрлекләрем

Безнең халык элек-электән үзенең һөнәрчелек таланты белән дан тоткан. Купшылыгы, нәфислеге белән теләсә кайсы заман гүзәленең дә һушын алырлык энҗеле калфаклар, изүләре чигүле затлы күлмәкләр, укаланган камзуллар, каюлы читекләр... Болар янәшәсендә үк – киндер сугу, туку станнары... Заманалар үзгәреп, борынгыдан килгән һөнәр-кәсепләрнең күбесе инде тарихка күчеп барса да, халык арасында кул эшләре белән сокландыручы остакуллар шактый очрый әле.

Шундый хезмәт сөючән һәм тырыш гаиләләрнең берсе – Тукай районының Иштирәк авылында яшәп ятучы Нургалиевлар. Гаиләдә парлы канат астында өч кыз тәрбияләнеп үсә. Әни кеше – бирегә Актаныш районының Бикчәнтәй авылыннан килен булып төшкән Эльмира апа – чигү остасы.

– Килеп төпләнгәнемә 28 ел булды, – дип сөйли ул. – Бикчәнтәйдәге гаиләм чигүчеләр гаиләсе иде. Әниемнең мине чигәргә өйрәтүләре әле һаман да истә. Бәхетемә, тормыш иптәшемнең әнисе дә оста чигүче булды. Алтын куллы иде! Мәдәният чараларының күбесендә аның чигүле әйберләре түрдә тора иде. Әллә минем эшләрне күреп, әллә ул осталык каннан бирелә – балаларым да бу һөнәрне үз иттеләр. Кечкенә кызымның кечкенә куллары белән үзе чиккән беренче кульяулыгын тотып килүе күз алдымда тора. Әниләрем инде гүр ияләре булса да, алардан – миңа, миннән – өч кызыма, кызларымнан оныкларыма күчкән талант алдагы буыннарга да тапшырыла барыр дип ышанасы килә. Кышкы озын төннәрдә җылы өйләрдә кадерле кешеләрең белән рәхәтләнеп аралашып, җан тынычлыгы белән, чигеп утыруларга ни җитә?!.

Һәр бала өйдә күргәнне кабатларга тырыша. Нургалиевлар гаиләсендә үскән өч кыз да, әниләренең яраткан һөнәрен үзләштереп кенә калмаганнар, көнкүрештә кулланырлык мендәр тышлары, алъяпкычлар, сөлгеләр, кульяулыклар чигәләр.

Узган ел азагында Нургалиевлар гаиләсе «Төп йорт» республика гаилә фестиваль-конкурсында катнашып, өченче урын алдылар. Бу уңыш алар өчен дә, безнең җирлек өчен дә зур куаныч, үзе бер дәрәҗә.

Бәйгедәге күргәзмәләр күз явын алырлык иде. Эльмира апаның эшләре дә лаеклылар рәтендә булды. Халкыбыз мирасына булган мәхәббәт остакулларыбызның әлеге кул эшләре аша да тәрбияләнә бит. Шушы матурлыкны тудыручы затларга чын күңелдән рәхмәт әйтәсе килә! Илһамнары киләчәктә дә сүнмәсен, иҗатташлары торган саен артсын иде!

Гүзәл ҺАДИЕВА,
Тукай районы Иштирәк авылы Мәдәният йорты режиссеры.

Тамбурлы чигү

Хәтеремдә, Бакырчы дәү әниемнәрнең өе чигүле бизәкләрдән генә тора иде. Тәрәз төбендә кызыл яраннар, ә стенада, шкаф өсләрендә, эленге арасында, киштәләр өстендә дәү әнием кулы белән чәчәкләп, бизәкләп, күз нурын кушып чиккән элмәләр, тастымаллар, сөлгеләр эленгән. Әни белән дәү әниләргә кунакка килгән саен идәнгә ятам да шуларны күзәтәм – балачакның бай фантазиясе ниләр генә күрми дә, ниләр генә уйлап тапмый иде ул бизәкләрдә! Мажара эзләп йөргән кечкенә мин, болардан тыш, чоландагы сәке астында, кеше күрмәгәндә генә ачып карый торган, дәү әти кулы белән ясалган каеш саплы агач чемоданда башка төрле сөлгеләр сакланганын да беләидем. Азрак саргайган, әмма бизәкләре дә, җепләре дә артык купшы һәм бик мавыктыргыч эзләр калдырып чигелгән иде алар. Шундый ук чәчәкләрнең, чигүле бормаларның мич каршында юка пешереп торган дәү әнинең алъяпкыч итәген дә бизәгәнен хәтерлим. Нишләптер, нәкъ шул купшы бизәкләр бигрәк истә калган. Ул бизәкләрнең серен соңыннан музей витриналарындагы язудан укып белдем мин: тамбурлы чигү дип атала икән...

Тамбурлы чигү французча tambour (барабан) дигән сүздән алынган, чөнки тукыма тарттырылган түгәрәк киерге барабанны хәтерләткән. Тамбурлы чигү дигәч, беренче чиратта, чәчәк бәйләмнәре күз алдына килә. Чәчәк бәйләмнәрен бик тә нечкә һәм нәфис бөгелгән сабаклар һәм эре-эре чәчәкләр хасил итә. Чигелешләрдә кайвакыт кош, бал корты, күбәләк сурәтләре дә очратырга була, алар чәчәк-үсемлек бизәгенә якынайтып эшләнелә.

Чын-чынлап төбәлеп карасаң, чигешләрдә ниләр генә юк – чәчәк таҗлары, яфраклар, каурыйлар, йөрәк сурәтләре. Татар халкының табигатькә якынлыгы, шигъри җаны, күңел байлыгы, матур бизәкләр булып, әнә шулай тукымага күчкән.

Тамбурлы чигү, элек-электән үк, татарларда гына түгел, ә бик күп төрки халыкларда (төрекмән, башкорт, үзбәк, әзәрбайҗан, казах, кыргыз) киң таралган була. Аның популярлыгы кирәкле әсбапларның гадилеге һәм эш ысулының ансатлыгы белән аңлатыла. Тамбурлы чәнчем – тукыма аша чөпчеп алынган күз ул. Бер-бер артлы тезелеп килеп, бу күзләр чылбыр хасил итәләр. Тамбур белән чигү өчен махсус энә кулланыла (күз урынына ыргакчыгы була). Чигү осталары башта тамбур энәсе, ыргак белән чиккәннәр, соңрак тамбур машиналары барлыкка килгән. Бу җөйне чигү өчен төсле мулине җепләр, киерге кулланыла.

Татар йорты гомер-гомергә тамбур белән чигелгән япмалар, кашагалар, эскәтер, тастымаллар, намазлык һәм данлыклы Казан сөлгеләре белән бизәлгән була. Хатын-кызларның күкрәкчәләре, алъяпкыч, күлмәкләре, башка яба торган өрпәләре, ирләрнең күлмәк якалары, егетләрнең бәйрәмнәрдә кия торган аяк чолгаулары һәм башка бик күп татар халык киемнәре шулай ук тамбур белән чигеп бизәлгән.

Минем үземә, тамбурлы чигү ул инде музейларда, сәхнә киемнәрендә, сандыклардагы сөлгеләрдә генә очрый торган истәлек-үрнәк булып тоела иде. Юк икән бит! «Түгәрәк уен» редакциясенә килеп ирешкән хәбәр буенча, чигү сәнгатендәге әлеге кабатланмас ысулны бүген дә кадерләп саклап, яңартып торучы осталарыбыз бар икән! Кемнәр дисезме? Свердловск өлкәсенең Түбән Серги районы Әрәкәй авылы хатын-кызлары! Әрәкәйлеләр борынгы әбиләреннән күчә килгән әлеге чигү ысулын күршедәге татар авылларында да торгызмакчы – күптән түгел генә Әрәкәй милли-мәдәни комплексында «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасының Свердловск бүлекчәсе тарафыннан (рәисе Эльвира Ка-

шап кызы Гобәева) тамбурлы чигү буенча зур мастер-класс оештырылган. Милли-мәдәни үзәкнең директоры Салават Сәгетдин улы Гобәев безгә менә нәрсәләр сөйләде: «Бу чарада Свердловск өлкәсенең төрле почмакларыннан сиксәннән артык оста катнашты, хәтта Пермь краеннан да Фәйрүзә Исламова җитәкчелегендә егерме кеше килгән иде.

Тамбурлы чигү безнең урал татарларында борынгыдан ук бик киң таралган була. Иң мөһиме, бу кул эше нәселдән-нәселгә күчеп, безнең көннәргә кадәр сакланып килеп җиткән. Алай гына да түгел, бүген дә тамбурлы чигү осталарыбыз бар, һәм без алардан бу һөнәргә өйрәнә алабыз.

Кайберәүләр, Әрәкәйдәге тамбурлы чигү белән эшләнгән япмаларны, сөлгеләрне күреп, бу бизәкләрнең кул белән чигелгәненә хәтта ышанмады да!

«Ак калфак» хатын-кызлар оешмасы уздырган әлеге чараның төп максаты – Урта Урал җирлегендәге авылларда сакланып калган чигү бизәкләренең (орнамент) төрлелеген, ягъни һәр авылның үзенә генә хас булган үзенчәлекләрен күрсәтү, тамбурлы чигүнең техникасын саклап калуга өлеш кертү иде.

Милли-мәдәни үзәгебез бинасында урын алган Туган якны өйрәнү музеенда 100 еллык тарихы булган тамбурлы чигү үрнәкләре саклана. Әмма алар һич кенә дә киштәләрдә тузан җыеп ятмый: җирле осталар бу үрнәкләрне җете төсләр белән яңадан «терелтә», бүгенге көнкүрешкә кертеп җибәрә. Әрәкәй, Акбаш, Шәкүр, Уфа-Шигери, Үрмәкәй, Перепряжка авылларында сакланган борынгы үрнәкләр янәшәсендә бүгенге осталар кулы белән нәфис-купшы тамбур бизәге чигелгән телефон чехолларын, сувенирларны, кечкенә сумкаларны, өс киемнәрен күреп «аһ» итте мастер-класска җыелган халык. Аннары аларның һәрберсенә үз куллары белән иҗат итеп карау мөмкинлеге бирелде: һәркем зур тырышлык белән кияү кульяулыгы чикте (безнең якта бу йола әле дә сакланып килә)».

Салават әфәнде тагын бер хәбәре белән уртаклашты: агымдагы елда Әрәкәй авылында тамбурлы чигү буенча халыкара мастер-класс оештырылачак икән. Әрәкәй милли-мәдәни үзәге берләштергән алты татар авылында бүген әнә шул колачлы чарага әзерлек бара – Урта Урал кызларының читтәге кардәшләр алдында сынатырга исәбе юк!

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр...



Безнең халык кебек үк театрга мөкиббән халык бармы икән тагын!

Тамаша кылу гына түгел, үзе сәхнәгә менеп, театр дигән серле дөньяга чумарга әзер иҗади затлар да бихисап бездә. Искә төшерә башласак, йә, кайсыбыз гына гомеребездә бер булса да сәхнәгә чыгып карамаган? Ә менә үзешчән театрларның «Идел-йорт» төбәкара фестиваль-конкурсы никадәр үзешчән артистларны башкалабыз сәхнәләренә күтәрде.

«Идел-Йорт» инде Казан тамашачысы тарафыннан ел саен көтеп алына торган бер бәйрәмгә әверелде. Фестиваль спектакльләре барган Мәдәният йортлары залларында алма төшәрлек урын да булмый. Быел ул унҗиденче тапкыр үтте. Шунысы куанычлы, спектакльләрнең сыйфаты да елдан-елга үсә бара. Һәр елны Казан тамшачысын таң калдырырлык яңа спектакльләр калкып чыга. Театр тәнкыйтьчеләрен, драматургләр, режиссерларны берләштергән дәрәҗәле жюри сайлап алган иң яхшы спектакль данлыклы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә күрсәтелә.

Гран-при ияләре шулай ук Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан булдырылган зур бүләк – автобус яисә акчалата сертификат белән дә бүләкләнәләр. Быел бу бәхет Актаныш муниципаль районы Киров авыл Мәдәният йортының халык театры коллективына елмайды. Михәйдәр Фәйзинең «Ак калфак» пьесасын алар чынлап та кайбер профессиональ театрлар көнләшерлек дәрәҗәдә сәхнәләштергәннәр иде. Тамашачы аягүрә торып алкышлады үзләрен.

Нияз Игъламов, *Г.Камал театрының әдәби бүлек мөдире, театр тәнкыйтьчесе, «Идел-йорт» фестиваленең жюри рәисе:*

«Әлеге фестивальне бәяләүдә мин быел беренче тапкыр катнаштым, минем өчен беренче тәҗрибә иде бу. Дөресен әйткәндә, халык арасында шундый җитди театраль тормыш кайный дип уйламаган идем. Минем өчен ачышлар күп булды. Яшьләрнең, кызлар гына түгел, егетләрнең дә күп булуы, Татарстаннан тыш, Башкортостаннан, Ульян, Самара өлкәләреннән татар халык театрларының катнашулары сөендерде. Әлбәттә, театрларның торышы төрлечә: бик югары дәрәҗәдәгеләре дә, йомшаграклары да, бик йомшаклары да бар. Бик көчле 5-6 спектакль булды, финалга мин бөтенләй кертмәс идем дигән берничә спектакльне дә карарга туры килде. Казан артында яхшы коллективлар бар, Тау ягы күтәрелеп килә. Актаныш, Азнакай яклары бик көчле. Шәһәр театрларына җиңелрәктер дип уйлыйм, Бөгелмә, Мөслим кебек кечкенәрәк шәһәрләрдә булса да, авыл җире белән чагыштырганда, үзешчән сәнгатьтә катнашырга мөмкинлекләр күбрәк кебек.

Кайда җирле җитәкчелек ярдәм итә – анысы да күренеп тора. Җирле үзидарә рәисе үзе башында торган коллективны да күрдек. Сөенечле хәл: кайбер җитәкчеләр сәнгатькәрләренә терәк булып, үзләре Казанга кадәр килгәннәр иде.

Фестиваль спектакльләрен бәяләү белән бергә, алга таба ничегрәк эшләргә дигән уйлар да килде. Катнашмасалар да, алдагы еллар-

да урын алган коллективларның җитәкчеләрен фестивальгә ел саен чакырып идем мин. Ул алар өчен тәҗрибә. Гран-при алган спектакльне генә түгел, иң яхшы 5-6 спектакльне башкала театрларында күрсәтсәң дә яхшы булыр иде.

Үзешчән театр җитәкчеләре, сәнгать җитәкчеләре өчен аерым курслар оештырырга кирәк. Аларга күбрәк белем бирергә, яңа алымнар, яңа драматургия белән таныштырырга, театр сәнгатендә дөньяда барган яңалыкларны күрсәтергә. Моңа ихтияҗ бик зур. 21 январьда Өстәмә һөнәри белем бирү институты (ИДПО) базасында Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге оештырган семинар да шуны күрсәтте. Бүгенге режиссурада яңа алымнарны куллану мәсьәләләренә багышланган әлеге семинарга гариза бирүчеләрдән тыш та шактый күп халык җыелган иде, барлыгы 115 кеше катнашты. Билгеле, монда бер-ике дәрес кенә җитми.

«Нәүрүз» Халыкара төрки театрлар фестивале кысаларында үткән форумда Мәдәният министрлыгы үзешчән коллектив җитәкчеләренә дә квота бирсә, кызыксынган кешеләрне күзәтүчеләр итеп чакырып идек. Кызыксынган кешеләр, дип әйтәм, күренә, театр җитәкчеләре арасында чын мәгънәсендә фидакарь затлар, профессионаллар да, очраклы кешеләр дә бар. Без һәр спектакльне карганнан соң анализ ясадык, коллективларны тикшердек. Бу бик кирәкле эш. Профессиональ театр сәнгатенең үсеше өчен дә үзешчән театрларның әһәмияте бәхәссез. Безгә профессиональ актерлар, режиссерлар әзерли бу хәрәкәт. Яшьләр шунда беренче тапкыр сәхнә тәмен тоя, кызыксыну уяна. Театраль мохит тудыруда да фестивальнең роле бик зур. Бу хәрәкәт тормышыбыздагы наркомания, эчкечелек, тәртипсезлек кебек тискәре агымнарга да каршы тора. Җитәкчеләрнең моның мөһимлеген аңлаулары кирәк. Театр җәмгыятьне дәвалый.

Алга таба да бу эштә кулымнан килгәнчә ярдәм итәргә әзер мин. Инде мөрәҗәгать итүчеләр дә бар. Үзешчән коллективларга яңа пьесалар җибәрәм. Башкорт драматургларының әсәрләрен дә тәкъдим иттем. Алар, билгеле, репертуарны үз мөмкинлекләреннән чыгып сайлыйлар: кайдадар олылар күбрәк, кайдадыр егетләргә кытлык...

Тагын шуңа игътибар иттем, фестивальне яктыртуда мәгълүмат чараларының игътибары җитмәде. Телевидение, радио, газета-журнал журналистлары спектакльләрне карамады. Җиңүче коллектив турында гына түгел, башкалары турында да репортажлар булса, аларның күңелләре күтәрелер иде. Игътибарга лаек үзешчән актерлар да, режиссерларның кызыклы табышлары да, сәхнә бизәлешендә үзенчәлекләр дә бар иде югыйсә. Алар барысы да аерым номинацияләрдә бәяләнеп, билгеләп үтелде.

Жюри бик гадел булды. Тәнкыйте дә кирәк, уңышлы якларны да күрсәтә белергә кирәк. Бөтенебез бергәләп, аңлап, дөрес итеп эшләсәк, бу хәрәкәтнең киләчәге колачлы».

Рифат Миндубаев, *Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге методисты:*

«Юкка гына бөек драматург Уильям Шекспир дөньябызны театр белән чагыштырмаган. Чөнки, театрның башлангыч тамыры безнең тормышыбыздан һәм яшәешебездән башланып китә, ә халкыбызны борчыган иң мөһим сораулар сәхнә төрләрендә урын таба. Театр үзе зур көчкә ия булып, гадәти тормышта тиешле дәрәҗәдә игътибар бирмәгән күренешләргә башка яктан карарга мөмкинлек тудыра.

Миңа быел «Идел-йорт» фестиваленең ахыргы турына килгән 20 спектакльне тамаша кылу мөмкинлеге туды.

Фестивальнең өченче туры ике өлешкә бүленеп, беренчесе Казан шәһәренең «Юность» Мәдәният сараенда, икенче өлеше Дәрвишләр бистәсендә урнашкан Сәетгалиев исемендәге Мәдәният сараенда үтте. Коллективлар көндәлек тормышыбызның тирән проблемаларын күтәргән

берсеннән-берсе үзенчәлекле спектакльләр алып килгәннәр иде.

Мирхәйдәр Фәйзинең «Ак калфак» спектаклен (режиссер Ләйсән Шәрәфетдинова) алып килгән Актаныш районы Киров авылы халык театры фестивальнең чын бизәге булды. Костюмнарның һәм декорацияләрнең тиешенчә эшләнүе, тамашага үтә дә табигый керешеп киткән җыр-биюләр, артистларның югары дәрәҗәдәге уены башкала тамашачысын да таң калдырды. Жюри беравыздан аларны Гран-при иясе дип таныды.

Беренче дәрәҗәдәге диплом белән, Чистай шәһәреннән килгән «Эксперимент» урыс халык театры бүләкләнде. Вячеслав Колесников җитәкләгән әлеге коллектив А.П. Чеховның «Секреты семейного счастья» әсәрен тәкъдим итте. Урыс драма театрының барлык кануннарын саклап, Чехов драматургиясенең чын төмен татып башкарылган әлеге спектакль декорацияләрнең зәвыклылыгы, сәхнәдә әйтелгән һәрбер сүзнең табигыйлеге, костюмнарның вакыйга барган чорны чагылдыруы белән истә калды. Ике сәгать ярым бараган тамаша да халыкны ялыктырмады.

Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» пьесасы буенча куелган спектакль (режиссер Нур Хөсәенов) өчен Актаныш районы Иске Кормаш авыл Мәдәният йорты татар халык театры һәм Наил Гаетбаевның «Авылга кызлар килде, яки Моңнар кайтсын авылга» пьесасы буенча куелган спектакль өчен Минзәлә район Мәдәният сарае «Шатлык» татар халык театры (режиссер Ринат Бәдретдинов) икенче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнде.

Өченче дәрәҗәдәге диплом белән Туфан Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр» пьесасы буенча куелган спектакль өчен (режиссер Зөлфирә Дәүләтшина) Мамадыш районы Түбән Сон авыл Мәдәният йорты «Мирас» татар театры һәм Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» пьесасы буенча куелган спектакль өчен (режиссер Алинә Галиева) Сарман район Мәдәният йорты татар халык театры бүләкләнде.

Җюри әгъзалары, шулай ук, иң яхшы хатын-кыз һәм ир-ат рольләрен башкаручыларны билгеләп китте. Әлеге бүләккә Зөлфәт Хәкимнең «Шайтан куентыгы» спектаклендәге Фәнзилә ролен башкарган Земфира Мөхәммәтшина (Апас районы) һәм Туфан Миңнуллинның «Йөрәк маем» комедиясендәге Аләүетдин роле өчен Мингәрәй Әминов (Чирмешән районы) лаек булдылар.

Үзешчән артистларның эчкерсез уеннарын карганда әлеге кешеләргә тирән ихтирам һәм соклану хисләре кичердем. Күп очракта авылларда яшәп, көн буе үзләренең төп эшләрендә хезмәт иткәннән соң, арганлыкларын онытып, шәхси мәшәкатьләрен читкә куеп, репетицияләргә йөреп, бернинди профессиональ белемгә ия булмаган килеш шундый образлар иҗат иткән кешеләр һәртөрле мактауга лаек. Халык театры дигәндә, сүз акча, дан-шөһрәт турында бармый бит.

Озакламый 18 нче «Идел-йорт» төбәкара фестиваль-конкурсының сайлап алу турлары башланып китәчәк. 2018 елдан фестиваль Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының легендар директоры Шамил Зиннур улы Закиров исемен йөртәчәк. Яңа сезонны яңа өметләр белән көтеп калабыз».

Шәкүр карак көе

Мөхтәрәм редакция!

«Түгәрәк уен»да (2017 ел, 4нче сан) Илсөя Шәкүрованың «Ат урлауның ачы тәме» язмасын тетрәнеп укыдым. Тау ягының данлыклы ат карагы күптән инде татар халык иҗатына «Шәкүр карак» булып кереп, легендага әйләнде.

Казан артының Әтнә якларында без, Олы Бәрәзә малайлары да, аның турында бик кечкенәдән ишетеп үстек: «Шәкүр ул байлар атларын гына урлаган, ярлыларныкына тимәгән, урланган атларны атсыз ярлыларга өләшкән», – дип сөйлиләр иде.

Безнең Олы Бәрәзә авылының бездән 12 чакрымда урманда үз делянкасы булды. Аны «Карчыга делянкасы» диләр иде. Шунда Гарифулла абый яшәде. Ул дөм сукыр иде. Авыл халкы аны «Сукыр Карчыга» дип йөртте. Дөрестермеюктырмы, миңа әниемнең энесе Илдус Фәйзрахман улы Сабитов (1930 – 2011) сөйләгәнчә, Гарифулла абый Шәкүр карак командасында булган. Һәм ниндидер сәбәпләр аркасында Карчыгага качып кайткан. Әлбәттә, Шәкүр карак аны эзләп тапкан, безнең янга шымчылар алып килмәсен дип, ике күзен дә сукырайткан, имеш.

Тагын бер чишелмәгән мәсьәлә.

Олы Бәрәзәдә «Чүти нәселе» бар. Чүти Гомәре гомере буе тимерче булды. Ул бик әйбәт һәм кызык кеше иде (урыны оҗмахта булсын!). (Без аның белән әле баҗайлар да була яздык: укытучы Шәрәфиев Хәйретдин абыйның («Казак Хәйретдине») Фирая һәм Клара исемле кызлары артыннан йөрдек. Тик Ходай безгә башка ярлар насыйп итте.) Кайбычтагы Чүти авылын мин күптән ишетеп беләм. Безнең авылдагы Чүти нәселе шул авылдан чыккан кешеләр түгел микән? Чөнки Казан алынганнан соң Казан артындагы тимерчеләрнең йә урыслар, йә Тау ягыннан килгән татарлар булганлыгы мәгълүм бит. Әле 1950нче елларда да бездә Аркадий (Аркаш) атлы урыс тимерче иде. Үзе дә, хатыны да, балалары Борис белән Зина да рәхәтләнеп татарча сөйләштеләр.

Минем бурычым – Чүти – Олы Бәрәзә бәйләнешен эзләү.

Шәкүр карак трагедиясе – халык трагедиясе. Бу турыда роман-трагедия язарга кемнеңдер кулы кычытып йөридер әле!..

Көйне Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, заманында бөек Салих Сәйдәшевнең фатыйхасын алган данлыклы гармунчы Дилүс Мәҗитов (1935 елгы, тумышы белән Әтнә районының Күәм авылыннан) җырлавында магнитофон тасмасына язып алдым һәм нотага салдым.

Илгиз КАДЫЙРОВ,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре



Эльвира КАМАЛОВА

Кама аръягы керәшеннәрендә туй йолалары

Кама аръягы керәшеннәрендәге гаилә йолалары үзләренең музыкаль-поэтик формаларга бай булуы белән сокландыра. Аларның төп өлеше туй йолалары циклы эчендә сакланып калган. Укучыларыбызга тәкъдим ителә торган тикшеренү материалы Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең Фольклор-этнографик кабинеты тарафыннан 2008 – 2009 елларда Татарстанның Түбән Кама һәм Зәй районнарына оештырылган ике фольклор экспедициясендә язып алынган иде. Бу экспедицияләрдә барлыгы 14 торак пункты тикшерелде. Болар: Түбән Кама районының Түбән Кама шәһәре, Ахтуба, Кече Афанасово, Балчыклы, Келәтле, Кашаево авыллары; Зәй районының Дүрт Мунча, Зычебаш, Кадыйр, Түбән Биш, Якты Күл, Кабан Бастрык, Урта Пинәге, Туңылҗа (Тонгузино) авыллары. Әлеге торак пунктлары Зәй елгасының урта агымы турысында урнашкан; бу җирләрдә яшәүче керәшеннәр фәндә Кама аръягы төркемчәсенә кертеп карала.

Керәшеннәрдә туйлар кара көздән алып Бөек постка кадәр дәвам итә. Без туплаган мәгълүматлар буенча, керәшеннәрдәге традицион никахлашу йоласы төп ике рәвештә – яучылык һәм кыз урлау (ябышып чыгу яки ирексезләп урлау) аша бара. Яучылап туй уздыру ике этапка бүленә: туй алды һәм туй чоры. Туй алды чорына никахлашуга кагылышлы гамәлләр керә: кәләш сайлау, яучы җибәрү, никах турындагы сөйләшүләр. Кәләш сайлау һәр ике яктагы ата-ананың карамагындагы җаваплы эш булып тора. Халык хәтерендә балалар әле дөньяга килгәнче үк туй турында килешенү очраклары да сакланып калган. Яучылап алганда, егетнең әти-әнисе туганнар арасыннан аеруча хөрмәтле бер кешене яучы итеп сайлый. Кагыйдә буларак, кыз йортында яучы киләсен алдан ук белеп торганнар. Яучыны ишек бусагасы янында мендәр өстенә утыртканнар. Аннары яучы белән кызның әти-әнисе арасында булачак кияү белән кәләш турында ипле һәм тәфсилле әңгәмә башланган. Әгәр ике як килешә алса, самавыр куеп, чәй табыны әзерләнгән. Шунда ук яучы белән ата-ана ярәшү көнен – кияү белән кәләшнең һәм ике як туганнарның тәүге очрашу көнен билгеләгән.

«Аңар мендәр куялар, йомшакка утра ул. Ул кыз артыннан белергә килгән, әнисе-әтисе белән сөйләшергә килгән. Ошаса инде әйбәтләп, аннары гына килешәләр. Шул ук көнне самовар куялар, өстәл әзерлиләр, әйбәтләп сыйлап җибәрә ийеләр. Аннары көнен әйтәләр, кайчан киләләр кияү, атасы, анасы, урсай атасы, урсай анасы» (Түбән Кама районының Кече Афанасово авылы. Урманчева Пелагея Степановна (1938 елда туган), Борисова Анна Степановна (1928)).

Билгеләнгән ярәшү көнендә кыз йортына булачак кияү, аның әти-әнисе, урса (крестный) әти-әнисе килә. Алар үзләре белән икмәк һәм көмешкә – ипине әчетеп әзерләнгән җиңелчә исерткеч эчемлек алып киләләр. Кәләшнең әти-әнисе табын әзерли, түргә кияү белән кәләш утыртыла. Ярәшүдә туйның көне билгеләнә. Моннан тыш, нәкъ шушы көндә һәр яктан туйга салынасы акча күләме, кунакларның саны һәм башкалар хакында килешенә. Безгә әйтүләренчә, элек керәшеннәрдә зур туйлар уздырылмаган, кагыйдә буларак, туйга иң якын туганнар гына чакырылган.

«Аннары инде туй көнен билгелиләр. Туйга киләләр, олы туй булса – алты атлы, начаррак булса – дүрт-биш атлы. Атларны бик матур киендерәләр – сөлгеләр эләләр, кыңгыраулар. Бөтен урам җаңгырап торадыр эйе» (Урманчева Пелагея Степановна, Борисова Анна Степановна).

Туйга кадәрге калган көннәрдә кәләш бирнәсен әзерләп төгәлләүне башкара. Кәләш бирнәсе чиккән сөлгеләрдән, яулыклардан, япмалардан, тәрәз пәрдәләреннән, ашъяулыклардан, урын-җир җәймәләреннән торган.

«Бәйли, чигә ийе. Ул аны алдан әзерлидер ийе. Иң башлап – тәрәз алъяпкычы чигү, өстәл җапкычы чигә. Бистәр – зурсын, бәләкәен. Аннары постельын да». Урманчева Пелагея Степановна, Борисова Анна Степановна.

Туй йоласы, яучы җибәрү һәм ярәшүне дә кертеп, ике атна чамасы дәвам иткән. Туй мәҗлесе үзе өч көнгә сыешкан, бу көннәрнең һәрберсендә үзенә аерым ритуаль гамәлләр, йолалар башкарылган. Беренче көн кияүнең кәләш йортына килүенә багышланган. Мәҗлеснең икенче көне кияү йортында дәвам иткән. Өченче көн «кода ипие ашау»га багышланган, бу табынга ике яктан да өлкәннәр генә җыелган.

«Элек өч көн була торган ийе. Бер көн – җегет җагында, бер көн – кыз җагында, бер көн – кода ипи ашыйлар инде, анда һәр кеше үз ягында үзе ашый. Элек туганнар килсәләр инде кунырга калалар ийе, икенче көн озатышлы ийе инде» (Түбән Кама районының Кашаево авылы. Федотова Тамара Семеновна (1940), Ефимова Ольга Александровна (1928)).

«Иң беренче кызны алырга баралар. Беренче көн – бер җакта, аннары – икенче якта. Аннан соң, бер атнадан соң «кода ипи ашау» буладыр инде» (Түбән Кама. Шадрина Ольга Феофановна (1936)).

Туйдагы кунаклар арасында аерымлап куелган бердәнбер персонаж – кияү егете – күбесенчә якын туганнар арасыннан сайланган. Аңа туй йолаларның тәртибен, үтәлешен күзәтү бурычы йөкләнгән. Еш кына очракларда кияү егете вазифасы яшь туган-тумача арасындагы өйләнгән ир-атка да йөкләнгән.

«Туйны алып баручы – кияү җегете. Ул инде туйның хуҗасы була. «Кияү җегете» ирле-хатынлы булалар. Алар инде туй вакытында тәртип саклыйлар. Бөтен обыщайларны алып баралар. Кичтән инде төне буе, иртәнгә кадәр гулять итәләр» (Түбән Кама районының Келәтле авылы. Золотов Алексей Михайлович (1933)).

Шулай итеп, туйның беренче көне кәләш йортында уза һәм анда, кияү килү хөрмәтенә, табын корыла. Һәр кунак үзе белән күчтәнәч – савым алып килә: каз, тавык, бәлеш, пилмән... Савымның мәгънәсен ярдәм, булышуның бер төре дип аңлаттылар, ягъни бүләкләр алып килмиләр, табын корырга булышалар.

«Туйга зур өстәл әзерлиләр, чыга бер унунбиш табак. Пильмәне дә бар анда, ите дә, казы да бар, бары да бар» (Түбән Кама

районының Келәтле авылы. Савельева Анна Васильевна (1927)).

«Элек бүләкне салмаганнар инде җегет белән кызга, ә хуҗага булышырга тырышканнар. Һәрбер туйга килгән кеше целой каз алып килгәннәр, каз булмаса, ике тавыгын, например, или итне. Булощкилар пешереп, пельменьын, аш-суын пешереп. «Савым» дип атала бездә ул» (Кашаево авылы. Федотова Тамара Семеновна, Ефимова Ольга Александровна).

Кәләшнең туганнары – яшь егетләр – мылтык тотып кияүне урамда көтәләр. Аларның төп бурычы – кәләшне мөмкин булганча кыйммәтрәккә «сату». Кияү кеше, кәләш ягына зур күләмдә акча биргәч кенә, ишегалдына, йортка уздырыла. Йортка кергәндә кияү һәм

аның туганнары, тугрылыкларын күрсәтеп, тәре яки иконаны үбә, сыйдан – икмәк, тоз, умарта балы һәм аракыдан авыз итә.

«Кызның капкасын бикләп куялар. Капка төбенә бала-чага чыга, көчтәнәч алыр өчен. Тиге яктан мылтык белән торалар. Атлар белән килеп туктагачтын, залп бирәләр, мылтыклар белән аттырып җибәрәләр. Аннары җегет җагыннан бер кеше өйгә кереп сөйләшә, урын сатып ала җегет белән кыз өчен, акча биреп. Дәү капканы ачып, тиге капкадан кертәләр туйны. Аннары ишек алдында тезеләләр. Тәре алып чыгалар, үптерәләр верностька. Өйгә кергәч, тагын урын өчен акча сорыйлар» (Келәтле авылы. Золотов Алексей Михайлович).

Сатып алыш өйдә дә дәвам итә: кәләш тә, өстәл артындагы урын да сатып алына. Шуннан соң кунаклар катгый билгеләнгән тәртип буенча урыннарына утыралар.

«Кызны нык яшерәләр. Ярар, кызны тапкач, өстәл арасына утырырга кирәк, ә урын җук, аны сатып алырга кирәк. Өстәл артында бик строго утыралар: баштан атасы, анасы, урса атасы, урса анасы. Аннан бик җакын туганы: братлары, апалары, аннары племәнниклары» (Урманчева Пелагея Степановна, Борисова Анна Степановна).

Тикшерелгән төбәкнең барлык керәшен авылларында да кәләш ягы әзерләгән казны турау йоласы яши. Аның үз тәртибе бар. Әлеге җаваплы вазифа кияү егетенә тапшырыла. Монда төп хикмәт шунда, һәр кунакка каз телеме эләгергә тиеш, әмма кошның төп скелеты бөтен кала.

«Иң беренче башны казның кисеп аласың дагын, хуҗага бирәсең, ул – баш кеше. Муенын кисәсең дә, бирәсең хатынына хуҗаның. Канатларын кисәсең дә, кызга бирәсең, син моннан очып киттең кәзер, менә сиңа канат. Хәзер сигез бот чыгарырга кирәк – канатыннан дүрт бот чыгарасың, ботыннан тоже дүртне. Анда ите әз ләгә. Шундагы туганнарына бирәсең. Кайсысы тешсезрәк кеше булса, бирәләр дә әйтәләр: «Менә синең тешең бик әйбәт, мә, кимер», дисең. Кызык ясыйлар. Хәзер бар күте казның, аны кисәсең дә кияүгә тоттырасың. Әйтәләр: «Менә син шушының өчен өйләндең, менә хәзер аша!» – дип. Ул каз турау – бик кызык. Каз ябырга өчен, кул сөртергә өчен каз белән бергә чыгаралар полотенце» (Шадрина Ольга Феофановна).

Каздан тыш, кәләшнең туганнары бәйрәм бәлеше әзерлиләр. Тикшерелгән һәр авылда да бәлеш ачу йоласы теркәлде. Бәлешне, шаярып-көлеп, өйләнгән пар ача, ягъни бәлеш капкачын кисеп ала. Әлеге йола «Бәлеш ачу җыры» астында башкарыла.

«Бездә «Бәлеш ачу» бар ийе. Без мужигым белән гел бәлеш ачадыр эйек. Аны киендерә эйек. Ул менеп баса урындыкка. Мин аны тартып төшерәм дә, үзем менеп басам. Ул миңа үренә, мине үбергә. Мин аны үпкән булам да, кырым җагам бөтен җиренә. Элек шундый эйе. Мужигым белән шулай туй саен җөрей ийек» (Урманчева Пелагея Степановна, Борисова Анна Степановна).

Туй мәҗлесенең беренче көненнән соң яшьләр кәләш өендә кунарга кала.

Икенче көннең төп эпизоды булып кәләшнең кияү йортына күченүе санала. Аны кияү, эти-энисе, урса эти-энисе озата бара. Кияү йортына башта кәләш үзе атлап керә, аннары аның бирнәсен кертәләр. Бу вакытта инде кияү йортында килен төшү белән бәйле берничә йола үткәрелгән була. Кияү егете зур акчага килен түшәген сата. Кияүнең урса энисе өйгә килен бирнәләрен – тастымал, эскәтерләрне элә.

«Икенче көнне кызның әйберләрен – түшәкләрен, одеялыларын, мендәрләрен, барын да өяләр ийе тарантас артына, кияү җегетенә алып кайталар. Кыз белән җегет бара ийеләр, урса ата белән урса ана, энки белән этки. Кыз артыннан әйберләрен кертәләр. Анда инде саталар түшәк, саткан-да инде щуть сугышмыйлар. Акча сорыйлар. Сата ийе кияү җегете» (Урманчева Пелагея Степановна, Борисова Анна Степановна).

Туйның өченче – соңгы көне – Кода ипие ашау («кода ипи ашау»). Бу көнне йортка өлкәннәр җыела. Кода ипие ашау еш кына берәр атнадан соң да үткәрелә. Кияү белән кәләш бу йолада катнашмый.

«Өченче көнне кыз белән җегет үз аралый, алар безнең белән түгел. Туганнар гына, кунаклар утрабыз. Алар үз эшләрен карыйлар» (Урманчева Пелагея Степановна, Борисова Анна Степановна).

Халык башкаручылары әйтүенчә, туйның өч көне дә җырлар белән бара. Бүгенге көндә туйга кагылышлы шигъри текстлар традиция булып килүче җирле халык мотивлары рәвешендә күп тавышка да, кыска көйләр булып та башкарыла.

Фотолар Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге фондыннан алынды.

Бакча артларындагы кибәннең



Бакча артларында(й)гы кибәннең
Аякларын үзең куйсана(й).
Минем бәбекәем сезгә бара,
Әнекәең үзең булсана(й).

2008 елның июнь аенда Татарстан Республикасының Түбән Кама районы, Kече Афанасово авылында Урманчева Пелагея Степановна (1938) белән Борисова Анна Степановнадан (1928) язып алдым. Әлеге җырны кодалар бер-берсенә багышлап җырлаган.

Эльвира КАМАЛОВА,
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең
фәнни-тикшеренү бүлеге хезмәткәре.



Алсу БАТТАЛОВА

Малы барның сые бар

Узган санда «Түгәрәк уен» журналы укучыларын Чүпрәле районының татар авылларында сакланып калган һәм хәзерге көндә дә гамәлдә булган мал асрауга бәйле гореф-гадәтләр, йолалар белән таныштырып үткән идек. Бу теманы дәвам итеп, укучыларыбыз игътибарына Әлки, Апас, Тәтеш районы татар авылларындагы мал асрау тәртипләренә бәйле йола-гадәтләрне, ышануларны тәкъдим итәбез. Әлеге мәгълүматлар Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге тарафыннан оештырылган 2015, 2016 еллардагы экспедицияләр вакытында теркәлгән иде.

2015 елда Әлки районы татар авылларында йөргәндә безгә бик кызыклы йола турында сөйләделәр. Нәзер корбанының бер формасы булган бу йола «Ат/бәрән/каз теләге» дип атала. Авылда «теләкле» йортлар бар. Аңлатуларынча, кайчандыр бу нигездә яшәүчеләр үзләренең ниндидер бер теләге барып чыкса, ат /бәрән/каз суяр идем дип сүз биргәннәр һәм теләкләре чынга ашкан очракта әйткән сүзләрен үтәгәннәр. Алар бу теләк нигезгә ябышып кала, буыннан-буынга күчә бара, ягъни аны һәр елны кабатларга кирәк дип ышанганнар. Ягъни, теләк, нәзер корбаныннан аермалы буларак, бер генә тапкыр үткәрелми. Моның өчен теләктә аталган терлекне суеп, ясин укытканнар. Терлек суя алмаган очракта, башка кешедән терлекнең башын гына сатып алып, теләк ясап ашаганнар. Теләк ясиненнән соң, терлекнең баш сөяген абзарның арткы ягына чыгарып, колга башына элеп куя торган булганнар. Ат/бәрән/каз теләге елның теләсә кайсы фасылында, әмма бары тик чәршәмбе көнне генә башкарылган. Аңа кадәр, якшәмбе көнне – нигез ияләре, сишәмбе – җир, җомга көнне су ияләре өчен укытырга кирәк дип санаганнар. Теләкне уздырмаган очракта авырып китәсең, эшең бармый дип ышанганнар. Хәзерге көндә «теләкле» дип саналган йортларда ботка ясап кына ясин укыталар. Ясинне авылның абыстае укый, хуҗабикә табын кора, күрше-күләннән урта-тирә һәм өлкән яшьтәге 4-5 хатын-кыз чакырыла. Балалар һәм ирләр ясин укытуда катнашмый.

Әлки районының Түбән Әлки авылында яшәүче Хәмитҗанова Миңҗиһан апа (1935 елда туган) сөйләгәннәрне җиткерәбез: «Бәрән теләге, ат теләге бу җортта. Ат суеп, бәрән суеп, теләк ясап ашаганнар. Син авырыйсың икән, йә нәрсә дә эшләргә буламы, шушы нием уңса, ат суяр идем, дип әтәләр. Аты бул-

маганда башын гына кешедән алып ашый булганнар. Без хәзер бутка пешерәбез. Безнең йорт теләкле йорт. Әни әйтеп калдырды: «Минем белән үлә булсыннар, син уздырып тормассың», – диде. Үлмәгән шул алар. Мин бик каты ике тапкыр авырдым. Яңадан уздырдым. Башта нигез буткасын уздырырга, бәрән теләге, ат теләге, аларга өч төрле ясин укытырга кирәк. Вторник – җиргә укытырга, пятница – суга укытырга, среда көнне – теләкләргә. Ял көнне – нигезнекенә. Акча бирәсең өч төрле. Уздырмасаң – авырыйсың. Ат теләген, бәрән теләген уздыргач, башын элеп куябыз. Кергән кешегә ябыша. Син дә бер сәләмәңне калдыр. Нәзерле йортлар бик сирәк. Бәрән теләге дигәндә, корбанга чалган кебек, бер яшьлекне суялар. Авыргачтан, «тотты микән?» дип уйлап уздырдым».

Миңҗиһан апа хәзер дә бу йоланы үти, үтәмәгән очракта, чир-сырхау киләчәк, дип ышана. Аның ихатасында колга башына эленеп торган ат, бәрән башы сөякләрен фотога төшереп алдык.

Мал асраган, тормыш-көнкүрешен хайван үстереп һәм үрчетеп көйләгән татар кешесе терлеккә, майлы, тәмле һәм мул сөткә күз тиюгә ихластан ышанган, күз тиюдән саклануның төрле юлларын, чараларын эзләгән. Түбәндә Татарстан Республикасының Әлки, Апас, Тәтеш районнарының татар авылларында теркәлгән мәгълүматларны китерәбез:

• Күз адәмне гүргә, хайванны казанга кертермен дигән.

• Көтүгә чыкканда, күз тимәсенгә, башына, муенына лента урап җибәрәбез, йә адәм күзе төшәрлек чүпрәк (Тәтеш районының Олы Тархан авылы. Әбелханова Фәүзия Мәүлет кызы (1950)).

• Сыерны савып кергәч, сөткә, бисмилла әйтеп, әз генә тоз сибәргә кушалар, күз тимәсен өчен (Әлки районының Түбән Әлки авылы. Хуҗина Сания Сәетдин кызы (1950)).

• Хайванга күз тимәсен өчен, төрле-төрле чүпрәкләр бәйләп, муенына асып җибәрәбез. Алар өч төрле төстә булырга тиеш (Апас районының Кече Күккүз авылы. Насыйров Гайнулла Нургали авылы (1935)).

• Муенына чук тагабыз бозауның, күз тимәсенгә.

• Хайванга туры карарга кушмыйлар, җиргә карарга кушалар, күз тими, җиргә карагач (Апас районының Олы Күккүз авылы. Мөбәрәкшина Фәнзирә Борһан кызы (1939)).

• Маңгаена чүпрәк бәйлиләр инде, күз шунда төшсен дип инде, лак сөртәләр инде, баштан күз шунда төшсен дип инде. Чүпрәк, күбесенчә, кызыл төстә була. Кызылга яхшырак күз төшә. Койрыгына да тагалар. Койрык арттан күренә, маңгай алдан (Әлки районының Карглы авылы. Хәсәнҗанова Кадрия Вакыйф кызы (1937)).

• Яшьрәк терлекләргә төймә тага идек. Төрле чүпрәктән менә мылай, менә мылай ясый идек тә, муенга бәйләп куя идек. Йә буяу, мөгезенә бер нәстә бәйләп җибәрә инде. Күз беренче шунда төшсен өчен (Тәтеш районының Бидәнге авылы. Сәгъдиева Вәсилә Миңгали кызы (1936)).

• Көтүгә куганда кайсы маңгаена ябыштыра, кайсы мөгезенә кызыл тасма бәйли. Хайванга төшми, күз аңа төшә (Тәтеш районының Сөендек авылы. Арсланова Дамирә Кадыйр кызы (1947)).

• Күз тимәсенгә, койрыгына тасмалар тагабыз. Кызыл тасма тагабыз, маңгаена да. Безнең зур җиленле, сөтле сыер иде. Сыерның җиленен сөәл басты. Озын-озын. Фәлән кешенең күзе тиде. Әбигә кереп укыттым. Шул сөәл өшкертүгә үзалдына камап-корып, матурланды сыерның җиленнәре.

• Сөткә шырпы салалар, чеметеп (Тәтеш районының Олы Тархан авылы. Абдуллина Зөмәрә Кәмәретдин кызы (1948)).

• Җилен капчыгын буйый идек, күз тимәсенгә (Тәтеш районының Түбән Тархан авылы. Вәлиева Гөлсирә Хәйретдин кызы (1931)).

• Сөткә дә күз тия. Сөт бирмә келәгәндә печән вагын өстенә тондырырга кирәк (Тәтеш районының Түбән Тархан авылы. Шәмсетдинова Фәридә Әхмәтсафа кызы (1940)).

• Сөтне биргәндә, сөтеңә шырпы сындырып сал ди иде әнкәй (Тәтеш районының Түбән Тархан авылы. Вәлиева Гөлсирә Хәйретдин кызы (1931)).

• Сөткә күз тия. Банкы кырыена тоз сибеп кертергә кирәк, кешегә биргәндә.

• Үрдәк-чебиләрне имән ботагы аша үткәрергә кушалар. Күз тиюдән (Тәтеш районының Бакырчы авылы. Әхсәнова Хәмдия Рәшит кызы (1982)).

• Сөткә күз тия. Сөт өстенә йә күмер, йә салам салырга кирәк (Тәтеш районының Олы Торма авылы. Гимәтуллина Фәүзия Нургали кызы (1940)).

• Кайнанам каз бибиләрен ыштан балагыннан чыгара иде, кечкенә бибиләрне, күз тимәскә, йә агач ботагыннан (Тәтеш районының Алабирде авылы. Әскәрова Фәйрүзә Миңнулла кызы (1965)).

Хайванны сатып алуга, сатып җибәрүгә бәйле ышанулар

– Саткан вакытта кул арты китмәсен дип җонын җолкып калалар да, абзарның бер җиренә кыстыралар. Күрмәгәндә эшләргә кирәк.

– Хайванны арт белән кертеп, арт белән чыгарсаң, аларга начар була, миңа яхшы (Әлки районың Түбән Әлки авылы. Хуҗина Сания Сәетдин кызы (1950).

– Саткан вакытта кул арты китмәсен дип әбиебез укый. Авыр куллы кешеләргә китте сарыкларыбыз. Кара эчле кешеләргә. Шуннан соң сарыкларыбыз үрчемәде (Әлки районының Түбән Әлки авылы. Хәмитҗанова Миңҗиһан).

– Хайван сатып алып кайтканда, бисмилла әйтеп, дога кылып абзарга җибәрәбез (Апас районының Кече Күккүз авылы. Сафин Ильяс Хөсәен улы (1939)).

Име-томы шул булсын!

Мал-туар авырып киткән очракта, аны савыктыру чарасы итеп, гадәттә, имләүләр кулланыла. Түбәндәге имләүләрне без Тәтеш районының татар авылларында теркәдек:

1) Йә илаһе Мөхәммәд, Мөхәммәд рәсуллуллах!

Йә илаһе Мөхәммәд, Мөхәммәд рәсуллуллах!

Йә илаһе Мөхәммәд, Мөхәммәд рәсуллуллах!

Бисмилляхир-рахмани-р-рахим Мәрмәр,
Бисмилляхир-рахмани-р-рахим Сарсар,
Бисмилляхир-рахмани-р-рахим Истәҗил,
Бисмилляхир-рахмани-р-рахим Аккуҗа,
66 кара күз,
76 соры күз,
Карамадым-күрмәдем,
Кем икәнен белмәдем!

Көллек өстеннән «шифара, өф-өф!» дисең дә инде, аннары, өрәсең өстенә, хайванга дамы, адәмгә дәме. Шулай өшкерәсең аннары (Тәтеш районының Бидәнге авылы. Әбелханова Фирдәвес Шәрәфислам кызы (1938)).

2) Агач гөмбәсенә ут элдереп җибәрәсең дә, 3 кат бисмилла укыйсың, 3 кат Әлһәм, 3 кат Колһуалла, 3 кат Аятел-көрси укыйсың. Укыганнан соң:

1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9 – Туктасын! (Тагын 3 кат укыйсың догаларны);

1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 – Җитеп торсын! (Тагын 3 кат укыйсың догаларны);

1, 2, 3, 4, 5 – Бизсен! (Тагын 3 кат укыйсың догаларны);

1, 2, 3 – Очсын! (Тагын 3 кат укыйсың догаларны).

«Име-томы шул булсын, башка кабатланмасын!» дип тәгәлләргә кирәк. Янган гөмбәне сул яктан әйләндереп йөртәсең, санаган вакытта әйләнәсе (Тәтеш районының Байраш авылы. Хәйретдинов Таһир Кадыйр улы (1939), Хәйретдинова Зәйтүнә Җиһангир кызы (1941)).

3)Зәңгәр күз, кара күз,
Яшел күз, соры күз.

Каян килдең, шунда кит! – дисең дә, «тфү-тфү» дип 3 мәртәбә әйтәсең дә, «Минем сулыш булмасын, Хозыр Ильяс сулышы булсын!» – дисең инде. Кичә шулай сыерның аякларын укып өшкереп, сулар белән җудым да, сыер аякка басты (Тәтеш районының Алабирде авылы. Әскәрова Фәйрүзә Миңнулла кызы (1965)).

4)Туйрада үсә гөмбә. Аны күз тигәнгә яндыра да, тәтенен дә иснәтә. Уң як мөгез арасыннан тотына.

Карт күз , яшь күз,

Каян килдең, шунда кит! – дип, төкерә-төкерә имли.

Нәс сүрәсен 7 тапкыр укый, әлеге сүзләрне дә 7 тапкыр әйтә дә, мөгез арасыннан башлап әйләнә (Тәтеш районының Зур Әтрәч авылы. Минаева Рәхимә Габделхак кызы (1933)).

(Дәвамы бар.)

Татар риваятьләре хәзинәсеннән

Укучыларыбыз игътибарына үземнең тарафтан Казан арты авылларында XX йөзнең икенче яртысында телдән һәм кульязма китаплардан тупланган борынгы татар риваятьләре мирасыннан берничә мифологик сюжет тәкъдим итәм.

«Келәү боткасы» яки «Йорт боткасы»

«Бу – йорт ияләре өчен борайдан ясап пешерелгән ботка. Аны ашаганда сөйләшмиләр. Элек келәүне бер капчыкка төрле сөякләр тутырып (мәсәлән, ат башы сөяге), келәткә, сарай-абзарларга, чормаларга аса торганнар иде. Келәүнең тиюенә ышаналар иде. «Келәү кәтә», дип, чатлык-чотлык җирләргә аңа акчалар ыргыталар иде.

Әүвәлдә келәү асмаган кеше белән «Келәвең дә юк синең!» – дип кычкырыша торган булганнар. Бүгенге көндә Чувашиядә, Кармыш дигән татар авылында яшәүче бер туганыбыз унсигез яшендә безгә кунакка килгәч, моның күзенә безнең бакчада ботак төртелә. Ул шул көннән бирле, «Келәү тотты» дип ышанып, ел саен май аенда әүвәлге бакыр акчаларны китереп, шул тирәгә ташларга тырыша. Келәүгә дип ташланган акчаларны алырга ярамый, алган кешегә зарар тия» (Татарстанның хәзерге Теләче районының Айдар авылында Сәгъдиева Фәгыйлә ападан 1972 елда язып алдым).

Яшерен сәдака

«Күәстәге калдык ипи камырыннан кабартма зурлыгындагы күмәч пешерәләр. Аны «Гәрдә», «Яшерен сәдака», «Төн сәдакасы» дигән исемнәр белән атыйлар.

Әгәр яшь бала елак булса, анасы төнлә урамга чыгып, беренче очраган кешенең куенына, сөйләшмичә генә, теге күмәчне кыстырып китәргә тиеш» (Питрәч районының Тау иле авылында Рәхимә ападан 1972 елда язып алдым).

Чалпы салу

«Әгәр берәр кеше караңгы төшкәч (ягъни «кеше аягы сыер булгач»), егылып аягын яки башка әгъзасын авырттырса, шул урынга барып, төнгә карап белгән догаларын укырга һәм сул кулы белән уң җилкәсе аша чалпы ташларга тиеш. Чалпы – акча яки көл. Көлне яхшырак диләр. Кайтканда башка юл белән кайтырга кирәк» (Әтнә районының Бәрәскә авылында Әхмәтҗанова Галимә ападан 1972 елда язып алдым).

Су тоткан чиргә ырым

«Кешенең тәнендә кып-кызыл таплар барлыкка килсә, аларны «су чәчәге» дип атаганнар, бу кешене «Су тоткан» дип уйлаганнар. Су тоткан кеше бер чүпрәккә тоз белән ярма төйни дә, төнлә, сөйләшмичә генә су буена барып, чүпрәкне суга агызып җибәрә. Ташлаганда түбәндәге сүзләрне әйтә:

Су атасы – Сары сакал,
Су инәсе – Сылубикә,
Шушыны ашагыз!
Шушыны эчегез!
Шушының белән бәхилләгез!
(Арча районының Яңа Кенәр авылында 1971 елда язып алдым).

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,
филология фәннәре докторы.

Илсөяр ИКСАНОВА



Иҗтиһат иткән – морадына җиткән

Мари Эл Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татар милли-мәдәни үзәгенең сәнгать җитәкчесе Гәрәй Габдрахман улы Мәгъсүмҗановның татар гөсләсен торгызу юлындагы хезмәтләре турында альманахыбыз битләрендә шактый сүз булды. «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивальләрендә ул безне үзенең яңа казанышлары белән елдан-елга сокландырып килде: башта татар гөсләсен табып, шуны яңартты, аннан үзе гөсләләр ясый башады, аннан гөсләчеләр ансамбле оештырып җибәрде.

Тик татар гөсләсен торгызу ул әле Гәрәй әфәнденең соңгы еллардагы эшчәнлеге генә. Без аны иң элек киңкырлы, чын мәгънәсендә зур музыкант, гаҗәеп оста баянчы дип беләбез. Үзәкләргә үтәрлек итеп сызландырып та, күңелләрне канатландырып, дәртләндереп тә уйнауларын күп тапкырлар ишетеп ләззәтләнергә насыйп булды. Дөресен әйткәндә, гаҗәеп тыйнак, сабыр гына үз эшен башкарып йөрүче Гәрәй әфәндене без бик тиз күреп алдык дип булмый. Без аны һәр очрашу саен әкренләп-әкренләп ача бардык. Байтак кешеләргә хас булганча, «мин шуны эшләр идем, эшемне бәяләүче юк», дип кемнәрнедер сүгеп тә, «эшләр өчен шартлар юк», дип зарланып та йөрми генә, кулыннан килгәнне максатчан рәвештә тормышка ашыра барган бу шәхес күпләргә үрнәк булырлык. Шунысын да ассызыкларга кирәк, гомере буе Татарстаннан читтә, башка милли-мәдәни мохиттә яшәп, мари, рус мәдәнияте өлкәсендә эшләргә мәҗбүр булса да, беренче урынга милли мәнфәгатьләрне куеп, җаны-тәне белән үз татарына хезмәт иткән хөрмәткә лаек зат ул. Каян килгән аңа бу кадәр сәләт, сәнгатькә бирелгәнлек? Сүзне, гадәттәгечә, балачактан ук башладык.

– Мари Эл республикасының Мари Төрәк районы Ступкин (рәсми исеме Ведерники) авылында туып-үстем, – дип сөйләп китте ул. – Безнең авыл яныннан тимер юл үтәргә тиеш булган, вокзал бинасын да төзеп куйганнар. Мөгаен, бу урында Стопкин («Сто пятый километр») станциясе тәгаенләнгән булгандыр. Тормышка ашмаган ул максатлардан халык телендә авылыбызның исеме генә калган. Безнең авылда нигездә Татарстаннан күчеп килгән татарлар яши, өч-дүрт кенә рус гаиләсе бар иде. Ахырдан алар да китеп бетте, татарлар гына калды. Марилар исә бездә бөтенләй булмады.

Әтием – балта остасы, әнием хуҗабикә иде. Без җиде бала: биш малай, ике кыз үстек. Хәзер ике абыем вафат инде. Биш малай – барыбыз да гармунда уйныйбыз, кызлар җырлый иде. Гармунга өйрәнәселәре килсә дә, нишләптер уйнап китмәделәр.

– Гармунга хиреслек каян килә, әтиәниегез уйный идеме?

– Юк, алар уйнамады, әнием бик матур җырлый иде. Ә гармун гаиләгә болай килеп керде. Олы абыебыз – Зәфәр абыйның күрше Түнтәр авылында иптәш малае бар иде. Түнтәр безгә биш километр. Абыем гел шунда йөри, чөнки иптәш малаеның әтисенең гармуны бар. Әтисе йокыга киткәч, болар гармунны алып, мунчага төшәләр дә шунда уйнарга өйрәнәләр икән. Абыем әзрәк уйный башлагач, әти аның үзенә гармун алып бирде. Аннан икенче абыем, аннан соң инде башкалары да өйрәнде. Мин кечкенә әле ул чакта – дүртбиш яшь миңа. Мин үзем биш яшьтә уйный башладым дип уйлый идем, апам әйтә: «Юк, син дүрт яшьтә уйный идең инде, абыйларга караганда син җиңелрәк өйрәндең», – ди.

Беренче гармуным – әти алып биргән тальян иде, аннан олы абый, әле үзе мәктәптә укыганда ук, каникул вакытында эшләгән акчасына ике рәтле гармун алды. Аннан инде өйгә баян кайтты.

– Ул тальяннар, баяннар өйдә генә уйналмагандыр инде?

– Без үскәндә әле гармуннар белән клубка барулар, «вечерга чыгу»лар бар иде. Алай гына түгел, без барыбыз да гармунда уйнагач, клубка барып җиткәнче әле ике-өч авылны гармун тартып җырлап узабыз. Бергә укыган руслар, марилар, удмуртлар да безгә кушылып, татарча җырлап йөриләр иде.

– Сез рус мәктәбендә укыдыгызмы?

– Дружино авылы мәктәбендә 8нче сыйныфка кадәр саф татарча укыдык, аннан 9-10 класска Карлыган мәктәбенә киттек. Анда инде русча белем алдык; татарлар, марилар, руслар – күпмилләтле мәктәп иде безнең. Үзара дүрт телдә аралаша идек. Әзрәк марича, әзрәк удмуртча... без аларны татарчага өйрәтәбез. Рус авылында үскән малайлар-кызлар да безнең белән чип-чиста татарча сөйләшәләр, бернинди акцентлары да юк иде хәтта. Соңгы вакытта мәктәпләрдә туган телне укыту тирәсендә барган шау-шуларны ишеткәч тә мин үзебезнең балачакны искә төшердем. Телләр белү безнең беребезгә дә комачау итмәде, ә тормышта бик кирәк чаклары булды.

– Аннан музыка училищесына киттегезме?

– Әйе, Йошкар-Оладагы музыка училищесына кердем. Баян буенча. Мин бит музыка мәктәбендә укымадым, музыкаль белемем булмагач, башта ике еллык әзерлек курсына керергә туры килде. Әзерлек курсын бер елда тәмамлап, төп төркемгә кереп киттем. Өченче курста музыка мәктәбен тәмамлап килгән иптәшләремне куып җиттем.

– Ә башка уен кораллары белән кызыксыну шунда укыганда тудымы?

– Анда халык уен кораллары оркестры бар иде. Без ул уен коралларында: балалайка, думбыра, контрабас... барысында да уйный белергә тиеш. Дәүләт имтиханын тапшырганда беренче имтихан белгечлек (минеке – баян) буенча булса, икенче имтихан оркестр белән дирижерлык итү буенча иде. Чөнки без училищедан «Балалар музыка мәктәбе укытучысы һәм үзешчән халык уен кораллары оркестры җитәкчесе» дигән диплом алып чыктык.

– Училищеда укыган еллар шәхси тормышыгызны коруда да хәлиткеч чор дип беләбез.

– Әйе, хатыным Татьяна белән училищеда таныштык; белгечлегебез буенча икебез дә бер педагогта укыдык. Мин тулай торакта яши идем, ул – шәһәр кызы. Дүрт ел дуслашып йөрдек. Алдан ук, «укып бетергәч, өйләнешәбез», дип сөйләшеп куйдык. Мин инде Алексеевскида (Йошкар-Оладан 30 км ераклыктагы бистә) эшли башлаган идем. Анда яңа гына Мәдәният йорты ачылды, шунда ук музыка мәктәбенең филиалы да булырга тиеш иде. «Булачак хатыным да баянчы» дигәч, район мәдәният бүлеге башлыгы, икегезне дә үземә эшкә алам, дип, училищега заявка да җибәрде. Тик... мине Мари-Төрәккә, Татьяныны Келемарга билгеләделәр. Июльдә диплом алдык, 30 июльдә туй иттек, 1 августта, ни булса, шул булыр, дип Алексеевскига киттек. Мине Мәдәният йортына аккомпаниатор, Таняны музыка мәктәбенә баян укытучысы итеп алдылар. «Билгеләнгән районнарыгызга барыгыз!» дип министрлыктан хатлар да килде...

Аннан икебез дә читтән торып Казан дәүләт Мәдәният институтына укырга кердек. Дүртенче курста улыбыз Илдар туса да, Таняның миннән каласы килмәде, бала туганчы алдан имтиханнарын биреп куйды да, кышкы сессиягә бергә барып, диплом алдык.

– Концертларда Татьянаның гаҗәеп матур сопрано белән:

«Сандугач сайрыйдыр кайларда,

Төлке тун, камчат бүрек байларда», – дип саф татарча җырлап утыруларына сокланганыбыз булды. Балаларга Венера, Илдар исемнәрен дә ул сайлады, дигән идегез.

Гәрәй әфәнде сөекле хатыны Татьяна белән Мари Элда узган «Түгәрәк уен» фестивале көннәрендә. Йошкар-Ола, 2015 ел.

Гаиләдә милли каршылыклар булмагандыр кебек.

– Юк, андый проблемалар тумады, шөкер! Әти-әнием дә Таняны бик яратып кабул иттеләр. Таныштырырга алып кайтканда, башка милләттән булгач риза булмаслар, дип бик курыккан үзе. Соңыннан: «Мине алар кебек җылы итеп каршы алган кеше юк иде», – диде. Никах укыттык. Татарча сөйләшмәсә да, аңлавын аңлый. Кызыбыз Венера, җәй көннәрен авылда торгач, татарчаны күбрәк аңлый, билгеле.

Без Алексеевскида 23 ел эшләдек. Анда күпчелек марилар яши. Руслар аз, татарлардан без һәм тагын ике генә гаилә бар иде.

– Сез 23 ел мари сәнгатенә хезмәт иттегез дип әйтеп була инде алайса.

– Дөрес, мари сәнгате белән шөгыльләндем: марича җырладым, биедем. Мари телен яхшы белүем эшемдә нык ярдәм итте. 3-4 ай аккомпаниатор булып эшләгәч, сәнгать җитәкчесе итеп куйдылар. Үземнең халык уен кораллары ансамблем бар иде анда. Бер үк вакытта музыка мәктәбендә дә эшләдем. Аннан бөтенләй мәктәпкә күчәргә өндәделәр. Анда китеп бер ел эшләгәч, «Кире кайт, монда эш тарала», – дип, янә Мәдәният йортына чакырдылар. Шунда: «Ике бүлмәле фатир бирсәгез, кайтам», – дип шарт куйдым. Безнең чор кешеләренең күбесенә хас булганча, фатир мәсьәләсендә шактый кыенлыклар күрергә туры килде. Эшли башлагач, ике катлы ике бүлмәле өйдән бер бүлмә биргәннәр иде. Күрше белән. Күршеләрнең балалары күп, үзләре икесе дә салырга ярата торган булып чыкты. Аш бүлмәсе беренче катта иде. Без ашарга утырабыз гына, күрше балалары килеп баса. Аларны да үз яныбызга утыртабыз инде. Әниләренә ошамады бу. Яңа ел алдыннан концерт куеп клубтан кайтып керсәк, аш бүлмәсе бикле! Ярый әле суыткыч бу якта иде. Су кайнаткыч белән чәй кайнатып, пилмән пешереп, бу якта калган савыт-саба белән Яңа елны каршы алдык. Бер ел шунда яшәдек. Аннан яңа йорт салдылар да, безгә бер бүлмәле фатир бирделәр. Ике бала белән анда да бик иркен түгел иде билгеле. Инде форсат чыккач, ике бүлмәлене сорадым. Бирделәр. Яңадан Мәдәният йортына сәнгать җитәкчесе булып кайттым. Күпмедер вакыт музыка мәктәбендә директор булып та эшләргә туры килде әле.

Марилар белән эшлим, ә күңел барыбер үзеңнекенә – татарга тарта. Ничек тә булса үзебезнең көйләрне уйнарга тырышам, концертларда татар халык көйләрен эшкәртеп баянда уйный идем.

Мари Эл телевидениясендә татарча «Туган тел» тапшырулары бара иде. 1997 елны шул тапшыру аша Йошкар-Олада Татар милли-мәдәни үзәге ачылуы, анда музыкант эзләүләре хакында белдем. Бу – мин теләгән, мин омтылган эш иде. 2005 елга кадәр Алексеевскидан килеп эшләп йөрдем. Җыр түгәрәген алып бардым. Беренче көннән алып шул түгәрәккә йөргән җырчыларыбыз Илтөзәр абый Таһиров, Марзия апа Хаҗиевалар бүген дә сәхнәдә.

2005 елны, ниһаять, Йошкар-Олада фатирлы булдык һәм монда килеп төпләндек.

– Татар мәдәни үзәгенең директоры булып та эшләдегез бит әле сез.

– Ике ел. Үзем директор, үзем сәнгать җитәкчесе, үзем завхоз, сантехник, электрик, маляр... Директор итеп билгеләгәндә таулар вәгъдә иткән иделәр, берсе дә юк. Җитмәсә, шул вакытта безнең бинабызны сатарга булдылар. Министрлыкка чакырып, бинаны тапшырырга куштылар, безгә бер бүлмә вәгъдә иттеләр. Бер ычкындырсаң, мондый бинаны кире кайтарып булмаслыгы көн кебек ачык иде. Төбәк татар милли-мәдәни автономиясенә бардым, анда да: «Министрлык кушкач, бир!» – дигән җавап кына булды. Ярый халык кузгалды, иҗтимагый хәрәкәт башланды. Мин «больничный» алдым. Үзем эшкә йөрим инде. Шылтыраталар өстән. «Терелеп эшкә чыккач, кул куярмын», – дип вакытны сузам. Җәмәгатьчелек хатлар яза.

Мин ясаган гөсләләр матур да булсын, җайлы да булсын дип тырышам.

Шулай итеп саклап калдык бинаны, килешүне 25 елга озынайттылар.

Директор булып Илгис Зәйнелгарәб улы Гайсин килгәч, мин җиңел сулап куйдым. Ул тәҗрибәле, хуҗалык эшләрен бик яхшы белә, ныклы элемтәләре бар, нәкъ менә үз урынындагы кеше булды. Мин дә үз урыныма кайттым – сәнгать ягын алып барам. Монысы – минеке!

– Әйе, сез чын мәгънәсендә сәнгать кешесе: талантлы, зәвыкълы, эзләнүчән. Татар гөсләсен кайтару җәһәтеннән алып барган эшчәнлегегез үзе генә ни тора!

– Бу эшкә фольклорчы галим Геннадий Макаров белән булган бер сөйләшү этәрде. «Сезнең якларда гөслә киң таралган булган бит, эзләсәң, бәлки, әле хәзер дә борынгы гөсләсен дә, гөсләдә уйнаучысын да табып буладыр», – дигән иде ул. Шунда кылт итеп исемә төште: балачакта күрше керәшен авылы Нослада яшәүче кодагыебыз Фәния апаның гөсләдә уйнаганын күргәнем бар иде бит. Геннадий Макаров ясап биргән гөсләне кыстырып, киттем Нослага. Монда инде элеккеләрдән беркем дә калмаган диярлек. Дружино авылында яшәүче Василий ага Ивановта 30 ел элек ясалган гөсләләр сакланган булып чыкты, үзе дә ясый белә икән. Аннан, сораша торгач, Татарстанның Арча районы Сәрдәбаш авылында заманында гөслә ясаучылар булганлыгын белдек. Анда киттек. Элек өй саен гөслә булган Сәрдәбашта. Хәзер уйный белүче ике генә кеше калган. Таисия апа Ефимова безгә «Сәрдәбаш көе»н уйнап күрсәтте. Җан эреде инде шуңа!

Соңрак, 2015 елның җәендә, Мари Төрәк районының Носла авылында, Кулакаева Сайнә апаларның келәтләрендә бик борынгы гөслә табылды. Ике кулга уйнала торган гөслә иде бу. Кайчандыр әлеге уен коралында бертуган кызлар – Елизавета белән Анастасия уйнаган. Гөсләнең бер корпусы гына исән иде, яңадан кыллар тарттырып, җан кертергә туры килде. Хәзер бу уен коралын ансамблебездә кулланабыз. Башка гөсләләрдән аерылып тора ул: тавышы бик матур, эчендә, тальяндагы кебек, кечкенә кыңгыраулар бар. Таба шикелле бер зур кыңгыравы да бар, анысына мин темп бирер өчен сугып алам.

– Аннан үзегез дә гөсләләр ясый башладыгыз...

– Уйнарга теләүчеләре табылды, уен кораллары юк. Үземә тотынып карамый чара калмады.

– Әтиегез балта остасы булгач, агач эшенә әвәслек сезнең каннан да килә дип әйтеп буладыр, мөгаен. Балачакта әтиегез тирәсендә кайнаша идегезме?

– Әти – төзүче. Өйләр, мунчалар, абзарлар сала, коймалар, түбәләр ясый. Безне дә кечкенәдән үзе белән йөртә иде, балта эшенә өйрәтте. Алексеевскида торганда, бер бүлмәле фатирга күчкәч, үзем «стенка» ясадым. Әти килгәч: «Каян алдыгыз моны?» – ди. «Үзем ясадым», – дим. «Кем өйрәтте?» – ди. «Минем әти кем соң?» – дип көлеп җибәрдем.

– Шәкерт остазын узар, ди халык мәкале. Ул шулай булырга тиеш тә. Сез дә әтегезнең һөнәрен яңа югарылыкка күтәрдегез. Инде



Гөсләчеләр ансамбле үсә, яңа биеклекләр яулый бара.

шактый күп гөсләләр ясадыгыз бит. Әйтүе генә җиңел, аны ясау өчен осталык та, шартлар да кирәк бит әле.

– Безнең төп мәсьәлә дә шунда, уен кораллары ясар өчен аерым остаханәләр юк. Әмма, остаханә юк дип утырсаң, бу эш беркайчан да урыныннан кузгалмас иде. Мин үземнең машина гаражымда эшли башладым. Кырымда узган «Түгәрәк уен» фестиваленә ике кулга уйнала торган гөслә алып барасым килде. Эссе җәйдә көне-төне гаражда ятып, иртәгә китәсе дигән көнне төнге сәгать унбердә өлгерттем. Иртүк юлга чыгып киттек, ансамбль белән уйнап карарга да вакыт булмады. Хезмәт урынымдагы бүлмәмдә дә, өйдә дә эшләргә туры килә. Әлбәттә, остаханә булса, ул инде икенче булыр иде...

– Әле аның материалын да табарга кирәк бит.

– Дөрес. Анысы үзе бер проблема. Төзелеш кибетләрендә йөрим эзләнеп. Яхшы материал табу җиңел түгел. Беренче гөсләне нараттан ясадым. Билгеле беренчесен ясау җиңел булмады. Тәҗрибә юк. Тагын ничегрәк итеп эшләп карыйм икән дип, төннәр буе уйланып ятам. Интернеттан да эзләндем. Аскы һәм өске декасы гадәттә чыршыдан ясала икән. Иске фортепиано алып, шул материалдан да ясап карадым. Аның декасы калынрак – 1 сантиметр. Ә гөслә өчен 0,4-0,5 сантиметр кирәк. Шул юкалыкка калганчы кул белән шомарттым. Бик озак вакытны алды, билгеле. Тик нәтиҗәсе дә куанырлык булды, яхшы гөслә чыкты.

– Бик катлаулы эш инде, күңел төшеп, кул селтисе килгән чаклар буламы?

– Юк, мин бу эштә үземне сабый бала өммәтендә хис итәм. Кечкенә бала, иртәгә уенчык алабыз дигәч, ничек дулкынланып, таң атуын көтсә, мин дә эш башлагач, тизрәк төнне үткәреп, эшкә тотынырга ашкынып торам. Дизайнын камилләштерү турында да уйланам, карарга да матур булсын, музыкант өчен уйнарга да җайлы булсын, иң мөһиме, билгеле инде яңгырашы яхшы булырга тиеш.

– Сездән күреп, бу һөнәр белән кызыксынучылар юкмы тагын?

– Киявем – кызым Венераның ире Александр кызыксына башлады. Кулы агач эшенә ята аның. Хәзер бу уен коралы белән кызыксынучылар да арта бара. Үземнең ансамбльдәгеләрнең һәммәсенә житәрлек уен кораллары ясадым, инде сорап мөрәҗәгать итүчеләрнең үтенечләрен дә кире какмыйм. Мари гөсләсен сораучылар да бар. Тик анысына тотынып караганым юк әле.

– Мари, рус гөсләләре татарныкыннан нәрсәсе белән аерыла?

– Формасы белән дә, размеры белән дә аерыла. Мари гөсләсе зур, 35 кыллы. Татар гөсләсе 12 кыллы гына. Бездә кыллар – турыга гына, русларда ике яклап тартылган, аларда тональностьны үзгәртергә була.

– Йошкар-Ола шәһәрендә узган «Звените гусли над Кокшагой» дип аталган гөсләчеләрнең Халыкара фестиваль-конкурсында катнашкан идегез. Анда тагын сезнең кебек үзләре ясаган гөсләләрдә уйнаучылар булдымы?

– Юк, андыйлардан бер без генә идек. Һәм, чынлап та, жюри әгъзалары: «Татар гөсләсен дә күрдек», – дип, безнең чыгышыбызны ассызыклап үттеләр. Белгәнегезчә, мариларда гөслә бик популяр. Бу уен коралына республика җитәкчелеге тарафыннан да зур игътибар бирелә: балалар музыка мәктәпләрендә, мәдәният колледжында гөслә класслары бар. Фестивальдә катнашкан рус һәм чуашлар арасында да әлеге уен коралы югалып тормаган. Россия һәм Мари Эл Мәдәният министрлыкларының уртак чарасы булган фестивальдә, шундый көндәшләр арасында чыгыш ясау безнең өчен үзе бер имтихан ул. Имтиханны уңышлы тапшырдык дип авыз тутырып әйтергә мөмкин, без быел анда беренче урынны алык! Узган фестивальдә беренче тапкыр катнашып, II урын алган идек. Ул вакытта ансамблебездә әле биш кенә кеше иде. Хәзер инде без ундүрткә җиттек.

– Һәм ансамбльнең нигезен Мәгъсүмҗановлар гаиләсе тәшкил итә, дисәк тә ялгыш булмас шәт...

– Әйе, барыбыз да диярлек шул ансамбльдә: үзем, хатыным, кызым, ике оныгым.

Әле 13 гыйнварда гына «Туым жондозы» керәшен фольклоры фестиваленең ун еллык юбилеенда катнашып, фестиваль лауреатларының кубогын алып кайттык. 2016 елда «Туым жондозы»нда беренче урынны алган идек без, быел лауреатлар җыелды.

– Котлыйбыз! Алага таба да яңа җиңүләр, яңа эзләнү-табышлар насыйп булсын!

Мең яшә, Сараланым!

Ул кичәнең хатирәсе күңелемне әле дә жылытып тора. Бигрәк мәгънәле, истәлекле, хатирәләргә бай кичә булды шул ул.

Алдагы көнне генә – 2017 елның 10 ноябрендә – Татар Сараланы авылында (Лаеш районы) яңа клуб һәм китапханә бинасы ачылган иде. Ачылу тантанасында Татарстан Республикасы мәдәният министры Айрат Миңнемулла улы Сибагатуллин һәм район башлыгы Михаил Павлович Афанасьев катнашу, клубыбыз мөдире Тәнзилә Нуруллинага Татарстан Республикасы Президентының 100 мең сумлык «Бүләк сертификаты» тапшырылуы бу вакыйганы бер бәйрәмгә әверелдерде.

Икенче көнне үк яңа бинада, авылдашыбыз, ярты гасырга якын гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган, Татарстанның атказанган укытучысы, Россиянең халык мәгарифе отличнигы, күп санлы дәреслекләр, методик җыентыклар авторы Гыймадиева Нәҗия Сәләх кызының «Меңьяшәр Сараланым» дигән чираттагы китабын тәкъдир итү кичәсе үтте.

2014 елда Нәҗия Сәләх кызы Татар Сараланы авылы мәктәбенең 100 еллыгына багышлап «Мәктәбем – якты юлым» дип исемләнгән китап батырып чыгарган иде инде.

«Меңьяшәр Сараланым» китабын шагыйрь Равил Файзуллинның:

«Һәр нигезнең, һәр авылның,
Һәр каланың үткәне бар.
Гыйбрәт алырлык мирасның
Калганы бар, киткәне бар...» дигән сүзләре белән башлый Нәҗия апа.

Саралан исеме астында Казан ханлыгы чорыннан ук яшәп килгән авылыбыз чыннан да бик борынгы, күп тарихи вакыйгаларга шаһит.

Китап нигездә XX гасыр аралыгын эченә ала. Авыл һәм аның халкы кичергән вакыйгалар китапта кеше язмышлары белән үрелеп сурәтләнә. Сугышта катнашкан авылдашларның тулы исемлеге, яңа авылга күчкәндә йортларның урнашу тәртибе, үзләре үк күпне сөйләп торган фотосурәтләр аерым игътибарга лаек.

Нәҗия апа чыгышын китап өчен материаллар туплауда булышкан авылыбызның өлкән буын кешеләре Фәһимә апага, Әминә апага, туганнары Халидә, Зәкия апаларына, Габделхәбир абыйга, классташларына, авылдашларына рәхмәт сүзеннән башлады. «Авылыбызның тарихында сугыштан соң иң зур сынау, Куйбышев исемендәге сусаклагыч төзелү сәбәпле, 1953-1954 елда авылның икенче урынга күчерелүе булды, – диде ул. – Шул вакытта авылыбызга кагылышлы күп кенә тарихи материаллар юкка чыккан. Тагын бер фаҗига – 1985 елда мәктәп яну. Берәмтекләп җыйган тарихи истәлекләр, солдат хатлары – барысы да шунда янып бетте. Шуңа да авыл хакында китап язуда зур кыенлыклар туды».

Нәҗия Гыймадиеваны сыйныфташы Сөембикә Гәрәева яңа китабы белән котлый.

Кичә барышында тамашачылар Саралан тарихына кагылышлы бик күп яңалыклар ишеттеләр: чыгыш ясаган һәркем үзләренең истәлекләре белән уртаклашты. Бигрәк тә ветеран укытучылар Зәйтүнә Насыйбуллина,

Яңа Мәдәният йорты ишекләрен ачты.

Роза Кушмина, Әминә Шакировалар сирәк кешеләргә генә мәгълүм вакыйгаларны искә төшерделәр. Шагыйрә, язучы Илсөяр Иксанова, табиб-профессор Хәйдәр Иксанов, Нәҗия апаның сыйныфташлары: Татарстан Республикасының атказанган табибы Сөембикә Гәрәева һәм запастагы ПВО полковнигы Валерий Ханафеев, әлеге кичәгә махсус кунак булып кайткан «Түгәрәк уен» альманахының баш мөхәррир урынбасары Гөлсинә Хәмидуллина чыгышлары кичәгә аерым ямь өстәде.

Авылыбызда булган кызык-мәзәкләрне сөйләп, көлешеп алулар да, Саралан тарихында булган фаҗигаи хәлләрне искә төшереп, күзләребез яшьләнгән минутлар да булды. Инде арабыздан киткән бик күп авылдашларыбызны ядь итү белән дә бу кичә үзгә бер мәгънә алды.

Кичә барышында китапка һәм авторга карата бик урынлы матур сүзләр, теләкләр әйтелде.

Миңа тагын нык тәэсир иткәне Нәҗия апаның туганнары булды. Аларның кунакларны зурлап каршы алулары, үзләре пешереп килгән милли ризыклар белән сыйлауларына сокланып, һәр гаиләдә дә шундый туганлык хисләре яшәсен иде, дип уйладым.

Яңа ачылган клубта узган тәүге чараның шулкадәр тәэсирле булып, авылыбыз бәйрәменә әверелеп китүе алдагы эшләребезгә дә аерым бер мәгънә өстәгән кебек тоелды.

Наилә ҖИҺАНШИНА,.
Татар Сараланы авылы китапханәчесе.

Нәҗия Гыймадиева китапханәче Наилә Җиһаншина һәм җирле үзидарә сәркатибе Нурзия Гыймадиева белән.

Нәҗия
ГЫЙМАДИЕВА



Гомер иткән җирләр кала...

...Күченүләр, аһ бу күченүләр!
Оя туздытуның җилләре.
Табигатьнең һәр нарасый җанын
Уттан утка чөеп җилгәрдә.

(Зөлфәт)

Авылыбыз сугыштан соң ятимләнеп калды. Сугыш яралары әле үзләрен озак еллар сиздереп, күңелләрне әрнетеп торды. Балалар кече яшьтән үк олыгаеп китте. Ирләр эшендә һаман да тол калган хатыннар, иртә өлгергән әтисез яшүсмерләр эшли. Авылда атлар юк диярлек, алар урынына үгез, сыер җигәләр, һәр йортта төп транспорт булып «уфалла» арбасы тора. Тормышлар бераз җайланды дигәндә генә – яңа хәбәр: 1950 елның 21нче августында СССР хөкүмәте «Идел елгасында Куйбышев гидроэлектростанциясе төзү турында» дигән карарын кабул итә. Бу карардан соң, бездән ерак түгел Атабай, Агачбашы, Мишә Тамагы авыллары янында бик зур диңгез булачак, моның өчен күп кенә авыллар, бистәләр күчерелачәк икән, дигән хәбәрләр тарала.

Бу хәбәр авыл халкына башларына күсәк белән суккан кебек тәэсир итә. Ирләрсез калган авыл шундый коточкыч авыр эшләрне ничек башкарыр?! Күпләр ышанып бетми. Әле генә сугыштан чыккан илгә тагын куркыныч яный, дип уйлаучылар да була. Ләкин

ышанырга туры килә: 1952 елның 27 июнендә СССР Министрлар Советының 2187-1037 номерлы карарлары нигезендә Куйбышев ГЭСы төзелешенең проекты раслана. ГЭСны төзү эшләре 1950 елда башланып, 1955 елда тәмамланырга тиеш була. Халыкка авылларны күчерүнең максатын аңлату эшләре башлана. Төп эш тагын укытучылар өстенә төшә. Укытучыларның аңлатмаларын елый-елый тыңлыйлар. Аларны Идел елгасында иң зур сусаклагыч төзү эшләре борчымый, өйләрен күчерү мәшәкатьләре куркыта, бу хәбәрләрне чираттагы фаҗига буларак кабул итәләр. (...)

Ульяновск тикшеренүчесе Евгений Бурдинның исәпләүләренә караганда, Татарстанда 149 торак пунктны су баса. Шуларның 88е тулысынча, 61е өлешчә су астында кала. Куйбышев сусаклагычын төзү бик зур чыгымнар таләп итә. Чөнки күп авылларны, күп корылмаларны тулысынча диярлек күчерергә кирәк була. Күчерерлек булмаганнары да бихисап: урман-болыннар, балыклы күлләр, терлекчелек (фермалар), культ корылмалары (чиркәү һәм мәчетләр), таш йортлар, зиратлар, юллар һәм башка бик күп объектлар.

(...) Күченү-күченмәүне халыктан сорап тормыйлар, бары да өстә хәл ителә. Каршы сүз әйтергә, киңәш бирергә тырышкан авыл советлары, колхоз рәисләренең фикерләре нигезсез дип табыла. Каршы килүчеләрнең кайберләре кара исемлеккә кертелеп, «ерак» җирләргә җибәрелә. Шулай да күчкән кешеләргә дәүләт тарафыннан компенсация карала, акча түләнә, колхозчы һәм хезмәткәрләр 2 елга авыл хуҗалыгы продуктлары тапшырудан, налог һәм страховка түләүдән азат ителә. Шулай ук авыл хуҗалыгы банкына төзелеш һәм ремонт өчен 2-3 елга кредит бирергә кушыла. Ләкин бу ярдәмнәрне тиз генә алып булмый. Күчерү эшләре өчен җаваплы кешеләр үз вазифаларын төгәл белми. (...)

Күчерү эше ашыктырыла. Безнең Саралан авылы 1953 елда күчеп бетәргә тиеш була. Авыл күчереләчәк урын ачыклана. Хәзер авыл ике исем белән йөртелә башлый: Иске авыл һәм Яңа авыл. Яңа авыл 3 км ераклыкта, тау башында булачак! Анда көне-төне җил улап тора. Туфрагы – комлык. Аларына түзеп тә булыр иде, монда су юк. Иске авылда һәр урамда, аерым йортларда да коелар бар, су 7-8 метрдан чыга, авыл уртасында зур күл җәелеп ята: су да коеналар, керләр дә юып чайкыйлар, кош-корт та шунда. Яңа авылның ике ягында коры елгалар бар: Олы елга, Тар елга (халык Тары елгасы дип йөртә). Безнең якта чишмәләр юк диярлек. Булса да авылдан еракта, урман эчендә, Идел ярында гына. Яңа авылда эчә торган су бөтенләй юк. Коелар казу файдасыз, чөнки су 80-90 метр тирәнлектән генә чыга. Дөрес, авыл эчендә кош-корт коена торган ике күл бар, аның берсе (Нәбиулла абый күле) җәй кызу килгәндә кибә; зуррагы – Әхмәтша абыйлар күле, бала-чага чупырдарга һәм каз-үрдәкләр өчен генә хезмәт итә. Авылдан 3 км ераклыкта тирәякта матурлыгы, чисталыгы, суының йомшаклыгы белән дан тоткан күл бар барын. Аны Мүкле күле дип атыйлар. Күлнең уртасында күчеп йөри торган мүк-утрау бар. Хәзер утрау инде яргаберегеп калды, аны агачкуаклар каплап алган. Авылның икенче ягында (3-4 км ераклыкта) көтү өчен казылган тагын бер күл бар. Шул урыннарда хуҗалык терлекләрен көтәләр, аларны сугарырга кирәк. Аны Казыган күл дип тә, Карамалы чокыр дип тә йөртәләр. Күл янында элек карама агачлары үсә иде, хәзер аларны кисеп бетерделәр. Авылдан бер чакрым ераклыктагы урман эчендә бер-ике саз бар. (...) Яңа авылга күчкәч, халык менә шушы сулыклардан файдаланды. Комлыктан уфалла арбасы тартып су ташулар бер дә җиңел эш түгел иде. Дөрес, авылда артезиан кое төзеделәр, әмма 80 м тирәнлектән су чыгару бик авыр эш. Әле авылда электр юк, шуңа күрә коены җил тегермәне белән эшли торган итеп кордылар. Ләкин бусы да тиешле нәтиҗәне бирмәде. Җил булса – су була, булмаса – юк. Кешеләр, җил чыкканны көтеп, кое янында көн үткәрәләр. Кичке уеннан кайтучылар кое янына кагылып китә торган булалар.

Су килсә, төне буе ташыйлар. Әмма мондый бәхетләр бик еш елмаймый. Кайдан гына су эчмәде авыл халкы? Атлары булган кешеләргә җиңелрәк: алар Мүкледән, Карамалы чокырдан, Яксаздан, күрше Рус Сараланыннан, Сиңгел, Атабайдан эчә торган су алып кайта торганнар иде. (...) Авыл кучкәч, халык мунчасыз интекте. Иске авылдагыларын сүттереп бетерттеләр. «Барысы да күчеп бетте», – дип районга хисап бирергә кирәк иде. (...)

Авыл күчү ничә гасырлык тарихны югалтты, тормыш-көнкүреш рәвешләренә, тәртипләренә үзгәрешләр кертте. Кыскасы, бу вакыйга – авыл халкы өчен тарихи фаҗига булды. Шуның аркасында күп гаиләләр авылдан бөтенләйгә китеп бардылар, туган җирләрен, туган-тумачаларын югалттылар. (...) Күчерү эшләре бик авыр булып чыкты.(...). Йортларны сүтәргә колхоз кешеләр бирә, бүрәнәләрен яңа авылга менгезеп тә куялар, әмма йорт кирәк-яракларын күчерү кешенең үз эше. Йортларны бит әле бастырып та куярга кирәк. Аерым бригадалар төзелде. Кайбер йортларны яңадан торгызу мөмкин булмады, сүткәндә алар бөтенләй таркалды, череп беткәннәр иде. Авылны акча эшләп алу нияте белән эш эзләп килгән кешеләр басты. Эш барышында күренде: аларның күпчелеге балта эшен бөтенләй белми икән, кайберләрен куып та җибәргәләделәр.

Күченү – мәшәкатьле эш

Иске авылда 360лап хуҗалык, участок больницасы, урта мәктәп, сыер һәм сарык фермалары, ат абзары, складлар, ашлык чистарту һәм саклау урыннары, янгын каланчасы һәм башка җәмәгать биналары, клуб, кибет булган. 1953 елда больница һәм кайбер фермалар күчерелми. Авылның бер генә урамын да су басмый, зират та шул килеш кала. Гомумән, күчәргә кирәк булдымы икән? Әмма каршы килү безнең эш түгел.

Авыл кешесе үз урамнары белән күчеп утырырга тели. Юк, алай булмый, һәр йортның урыны районда ук билгеләнгән дип аңлаталар. Шундый зур авыл кешеләре, гомер уздырган күршеләреннән аерылып, төрле урамнарга күчеп утырырга тиеш булалар. Бу хәл бигрәк тә картларга һәм балаларга авыр тәэсир итә. Юксынышалар, бер-берсе белән елаша-елаша күрешәләр, ә берсен-берсе моңарчы белмәгән балалар

Төзүчеләр бригадасы.
Алгы планда Гәрәй Сафиуллин.

тиз генә аралашып китә алмыйлар, үз урам дусларын эзләп йөриләр.

Һәрбер йорт каршына агач утырту мәҗбүри куела, чөнки авылда яшеллек юк дәрәҗәсендә. Йорт каршына каен, миләш һ.б. урман агачлары утыртырга тәкъдим итела. Акыллырак кешеләр җиләк-җимеш агачлары утырталар. Күпчелек исә каен, миләш, шомырт агачлары утырта. Утырту өчен урманда агач күп.

Йортлар билгеле бер тигезлектә булырга тиеш. Аркылы торган йортларны хупламыйлар. Урамда төзелеш материаллары тәртипсез ятарга тиеш түгел. Беренче урамда (аны Бер канатлы урам дип атыйлар) юлның икенче ягында тал чыбыгыннан плетән тотарга кушылды. Ул плетән урамны матурайтып җибәрде. Кешеләрнең утыннары, печәннәре плетәннең теге ягына чыгарылды, җәйге абзар-куралар да шунда күчте, мунчаларны да шунда сала башладылар.

Иртәгә күченүне башлыйбыз дигән төндә тетрәндергеч бер вакыйга була. Һәрбер яңалык мәчет янында беленгәнгә күрә, кичтән халык тагын шунда җыела. Җитәкчеләр эшне мәчет манарасын кисеп төшерүдән башламакчы булалар, халыкка да җиткерәләр. Халык бу эшне хупламый, манараны кисүгә беркем дә алынмый, һәрберсе башын иеп кайтып китә. Башлыклар 2 урысны, бер керәшенне яллаарга булалар. Төнлә җил-давыл кузгала, коеп яңгыр ява, яшен яшьни. Иртә белән ни күрсеннәр – манара авып төшкән. Сынмаган да, ватылмаган да, айлы

ягы мәчеткә таба борылып, ямь-яшел чирәм өстендә ята. Бу хәбәр тиз арада бөтен авылга тарала. Кешеләр, елый-елый, мәчет янына җыелалар. Манарага кяферләр кулы тидермәгән Ходайга рәхмәт укыйлар. Соңыннан бу айны яңа зиратның капкасына илтеп куялар.

Күченү тиз генә булмый әле. Яңа авылда өй түбәләрен салам белән ябарга ярамый: такта, шифер яки калай булырга тиеш. Һәр кеше дә булдыра алмый бу эшләрне. Табуын да табып булыр (алыпсатарлар бервакытта да бетмәгән), тик акчасын кайдан табасың? Колхоз урманнан бүрәнә кисеп алып кайтырга рөхсәт бирә. Бу инде такта белән яп, дигән сүз. Тик шунысы бар: агачны авыл яныннан түгел, су басасы урыннан, тау астыннан кисәсе. Бу эш күп кешенең кулыннан килми. Кискән очракта да аны Идел ярыннан ничек алып менәсең? Ә безнең авыл янында яр бик текә. (...) Көч-хәл белән алып кайткан бүрәнәләрне такта итеп ярасы да бар бит әле. Авылда яңа һөнәр ияләре барлыкка килә – такта яручылар. Бу эшләргә беренчеләрдән булып Яхуш Гали абый белән Корбан Ислам абыйлар, Пипук Әсәте, Сибгатьнекеләр керешә. Аларга Шәксезнекеләр, Бозау Закирыныкылар кушыла. Болар – нык, таза егетләр була. Шулай итеп, өйләре такта белән ябылган түбәләр күбәя бара. Искергән өйләрнең идән-түшәмнәрен дә яңа такта белән алыштыралар, өйләр яңарып киткәндәй тоела. Балта осталары тәрәзә яңаклары ясый. Нурул Зиннәте, Фәтхеттин, Бүре Газизләре балта эшләренең остасы булып танылалар.

Авылның үзенең оста мич чыгаручылары булган. Быжым Хәсәне, әтиемнең энесе Шәрәфетдин абый, Буаз Кәлие мич чыгаралар. Авыл халкы үзе кирпеч суга башлый. Бу эш җиңелләрдән түгел, көч таләп итә. Кирпеч сугу эшенә яшь кызлар һәм егетләр алына. Минем күршем Миннегали абый чалгы саплый, уфалла арбасы ясый. Иләкчиләкне ямау, самовар, сәгать, сепаратор, тегү машинасы төзәтү эшләрен Нуруллин Зиннәт, Мөбәракшин Кыям, Хәмәдияров Ринатлар (соңрак) бик оста башкаралар. Аларның балалары да әтиләренең һөнәрләрен үзләштереп калганнар, бүген дә авыл халкына ярдәм итәләр.

Кораңгыш Нәбиуллласы, Төх Галиме, Тәкә Мингазе, Бүре Газизе гомерләре буена авыл халкына итек бастылар. Иске авылдагы күршем Ярый Исмәгыйле, яңа авылдагысы Гайникә Миннегалиләре иң оста чабата үрүчеләр иде. Алар үргән чабаталарны киеп, Казанга җәяү барып кайтырга мөмкин булган. (...)

1 Майда Төксер тавында: Минҗиһан Шәрәпова, Галия Гыймадиева һәм кунак кызы Язилә Шакирова.

Үзебездә үк гармун ясаучылар да (Сукыр Гали), скрипка һәм мандолина эшләүчеләр дә булган. «Яңа авылга күчкәч, Зиннәт абыйның әтисе Нурулла бабай, кич белән өй артларына чыгып, үзе ясаган мандолина һәм скрипкада уйнап утыра иде. Без, балачага, җыелышып, гаҗәпләнеп, тыңлап, карап тора идек. Хәзер дә тыңлыйсы иде шул көйләрне», – дип сагынып искә төшерә шул урамга күчкән Рәисә Нигъмәтуллина.

Яңа авылга күчкәч, 1нче Май бәйрәмен бәйрәм итү дә яңа төс алды: бу көнне халык иртәдән Төксер тавына (Идел ярының бу тирәдәге иң биек урыны) ашыкты. Яшьләр гармуннар уйнап, җырлашып-биешеп күңел ачтылар, бала-чага үзләре белән алып килгән буялган йомыркаларын, кәнфитпрәннекләрен ашап сыйландылар. Беренче тапкыр су коенучылар да булды. Яз соңрак килгән елларда умырзаялар да җыйдылар. Кайбер елларда авыл кибете шунда ашамлыклар сатуны да оештыра, үзешчәннәр концерт күрсәтләр иде. Төксердәге 1нче Май бәйрәме 90нчы елларга кадәр дәвам итте.

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Күңелләргә кагучы «Иделкәй»

Минем өчен моңа чаклы Югары Ослан ул – кышларын Казанны «якынайтучы» Идел өстенә сузылган бозлы юл, җәйләрен паром белән Идел аша кичкәндә арьяктагы тукталыш һәм тауга менүле-төшүле бормалы юллар иле иде. Бу районда рус милләтле халык күп яшәгәнен, хуш исле алма бакчасы бар икәнен дә беләбез. Һәм минем өчен яңа ачыш: монда бит әле җырга-моңга гашыйк татар йөрәге дә янып яши икән!

Югары Осланда үз районнарын гына түгел, тирә-күршеләрне дә җырлары белән гашыйк иткән «Иделкәй» ансамбле эшләп килә. Монда йөрүче апа-абыйларның фидакарьлегенә, «безнең ансамблебез» дип өзелеп торуларына, кышкы зәмһәрир суыкта атка утырып бер авылдан икенчесенә концерт куеп йөрүләренә һәм башка бик күп-бик күп күркәм эш-гамәлләренә исең китәрлек.

1992 елда, иҗади күңелле кешеләрнең уртак теләге белән, «Тамырлар» дип аталган төркем оеша Югары Осланда. Гармунчы егетләр (ир уртасы булса ни!), җырчы кызлар (илледә дә күңел унҗидедә лә ул!), халык җырларын барлап, төрле бәйрәмнәрдә, авыл сәхнәләрендә чыгыш ясап йөри башлыйлар. «Түгәрәк уен» журналы белән очрашуга ансамбльнең иң актив артистлары килгән иде. Әйдәгез, барысын да тәфсилләбрәк үзләреннән сөйләтик әле!

– «Тамырлар» төркемендә егермедән артык кеше йөри иде, – ди коллективны әйдәп баручы Фидания апа Нурисламова. – Һәр чыгышыбызны халык йолаларына багышланган театральләштерелгән күренештән башлап җибәреп, концерт номерлары белән дәвам итә идек. 2002 елда, «Тамырлар»дан аерылып чыгып, «Иделкәй» ансамбле булып оештык. Фольклорны да, вокалны да алып бара торган бер уникаль ансамбльгә әйләндек. «Балкыш» фестивалендә берничә тапкыр лауреат, «Иске Казан Түгәрәк уены» республика фестивалендә III дәрәҗә Дипломга лаек булдык. Ансамбльгә йөрүчеләрнең фидакарь хезмәте игътибарсыз калмады – халык ансамбле исемен алуга да ирештек. Бүгенге көнгә ирешелгән уңышларыбызга сөенеп туя алмыйбыз, кая барсак та, таныйлар, үз итеп кабул итәләр. Шөкер, ансамбльнең 15 еллыгын да зурлап уздыру бәхетенә ирештек.

– Безне телевизордан да еш күрсәтәләр, – дип сүзен башлады егетләрне көнләштерерлек җилгерлеге булган 85 яшьлек Фатыйх абый Хикмәтуллин. – «Аулак өй» тапшыруында да, «Манзара»да да булганыбыз бар. Берничә ел элек «Уйна гармун!» («Играй, гармонь любимая!») тапшыруында төшеп, Беренче каналдан да күрсәттеләр безне! Менә шундый нәни җиңүләребезне зур итеп күреп, шатланып яшибез инде без. Тамашачы яратып кабул иткән һәр чыгышка сөенәбез. Гел хәрәкәттә без. Тарихка дәһшәтле исеме белән кереп калган Суслонгерга барып, билгесез солдатларга таш кую тантанасында татарча чыгыш ясап кайттык. Суслонгер корбаннары арасында безнең районныкылар да бик күп. Чувашиянең башкаласы Чабаксар шәһәрендә Сабантуйда җырладык. Казанда бөек Тукаебызның туган көнендә уза торган «Шигырь бәйрәме»ндә дә ел саен катнашабыз. Кызыл Байракта композитор Салих Сәйдәшевнең туган көненә багышлап уздырыла торган бәйрәмдә дә катнашмый калганыбыз юк. Тирә-күрше районнардагы авылларга да концертлар куярга йөрибез.

Сәхнә костюмнарын булдыру тарихын да сөйләп алдылар. Бала итәкле костюмнарны башта ансамбльнең җитәкчесе Фидания апа Нурисламова үзе тегә. Ләкин тора-бара бу киемнәр канәгатьләндерми башлый, халык алдына затлырак костюмнар киеп чыгу хыялы туа.

Әлеге хыялны чынга ашыруны тынгысыз Фатыйх абый Хикмәтуллин үз кулына ала. Татар дәүләт филармониясенә, Җыр һәм бию ансамбленә дә барып сөйләшә ул, спонсорларга да мөрәҗәгать итә. Йөри торгач, чигүле камзуллы яшел костюмнар тектереп кияләр. Берничә елдан Мәдәният министрлыгы ярдәме белән чәчәклечуклы күлмәкләр дә барлыкка килә. Аннан зәңгәр бәрхетләре... «Иделкәй» үзенең иҗатында да торган саен югарыга үрли. Ә инде сүзләрен татар теле укытучысы Рузалия Җиһаншина, көен Рамил Курамшин язган «Осланым!» җыры ансамбльнең визит карточкасына әйләнә.

Фатыйх абый турында аерым әйтеп үтми булмый. Ул ансамбльдәге иң олы яшьтәгеләрнең берсе – күптән түгел генә 85 яшьлек гомер бәйрәмен каршылады. (Ансамбльнең тагын бер алыштыргысыз җырчысы Лена апа Сайкина белән яшьтәшләр алар.) Әмма бу яшь аңа ансамбльнең йөзек кашы, көчле тавышлы солисты булып йөрергә бер дә комачауламый. Яшьлегендә Борнаш авылыннан армиягә китеп, шуннан Пермь якларында урман кисү эшендә калган, тормышның ачысын-төчесен күргән ир-ат йөрәгенә моң шактый җыелгандыр, күрәсең. «Иделкәй»дә алар тормыш иптәше Роза апа белән парлап җырлыйлар. Кайбыч районында узган «Төп йорт» республика гаилә фестиваленең зональ турына барып, гаиләләре белән чыгыш ясап кайтканнар.

Безнең очрашу җыр-моң белән аралашып бара. Менә ансамбльнең гармунчысы Сәлим абый Кадыйров «Кердем карурманнарга...»ны сузып җибәрә, аны Фирдинә апа күтәреп ала...

Сәлим абый алты яшендә тальянда уйнарга өйрәнгән. Беренче класста инде ул концертларда тальяны белән чыгыш ясап йөргән, алга таба баянны да үзләштергән. Хәзер инде ул «Иделкәй»дә алыштыргысыз кеше! Үзе әйткәндәй, «күңел өчен генә» көйләр дә язгалый икән.

Илсөяр апа Мөхетдинова да «Иделкәй»гә күптән йөри. Үзе гомер буе хокук саклау хезмәтендә эшләгән. Милиция майоры дәрәҗәсен алып лаеклы ялга чыккан. Илсөяр апа шигырьләр дә иҗат итә икән.

– Төрле кызык хәлләр булды инде, – ди ул. – Кыш көне атлар белән бер авылдан икенчесенә барып концертлар куеп йөрибез. Чыгыш ясыйсы авылның клуб ишеге төбенә килеп туктыйбыз, клуб әле ачылмаган була. Җырлый-җырлый клуб ачылганны көтеп утырабыз. Тормышыбызны «Иделкәй»дән башка күз алдына да китерә алмыйбыз, ансамбльгә йөри башлагач, ун елга яшәрдек. Репетицияләргә дә, концертка да очып килеп җитәбез. Без бит монда шау-гөр килеп, үзенә күрә бер тормыш белән яшәп ятабыз!

– Концертлар булмыйрак торса, «әллә миннән башка гына йөрисезме?» дип шалтырата ук башлыйлар, – дип көлә Фидания апа.

Үзләре сөйлиләр, күзләрендә – ут, күңелләрендә дәрт янып тора. Киләчәккә мең төрле планнары, хыяллары бар әле апа-абыйларның.

– Телебезгә, милләтебезгә җырларыбыз белән хезмәт итәргә тырышабыз. Чыгышларыбыз эчтәлекле булсын өчен, әбиләрдән отып калган җырларны күбрәк башкарабыз, «Туй алдыннан өй бизәү», «Чишмә юлында» кебек фольклор-этнографик күренешләр кертеп җибәрәбез. «Оныгым җырыгызны яратып калган, сүзләрен язып бирегез әле», – дип шалтыратучы дәү әниләр дә бар. Ә инде Бакчасарай авылына баргач, бер ханым, «җырлыйсым килә» дип, безнең белән бергә сәхнәгә чыгып җырлады. Җыр белән бергә халыкның күңеле уяна бит аның! – дип, сөенешәкуаныша сөйләделәр алар.

...Урамда әле һаман кар ява. Югары Ослан ярларына сыенган Иделгә дә боз каткан. Очрашудан чыккан күңелем генә һаман тынычлана алмый. «Иделкәй»ләр кузгаткан җыр бураны дулый, моң бураны...

Ярты гасыр яши нур чәчеп

Әле күп җирләрдә иске мәчетләрне клуб итеп яшәгәндә, тумышыннан ук мәдәният учагы булып халыкка хезмәт итүче Кукмара районы Зур Сәрдек Мәдәният йортының илле еллык юбилее узып китте. Бинаһая зур итеп салынган бу бинаның бик үзгә тарихы бар. 1966 елда, «Коммунизмга» колхозын җитәкләгән колхоз рәисе, Социалистик Хезмәт Герое Камил Фаяз улы Шакиров, Мәдәният йорты салу нияте белән, рөхсәт сорап, район җитәкчелегенә бара. Бина өчен урын итеп авылның нәкъ уртасын сайлый ул. Ләкин, район җитәкчелеге, авыл уртасына саласы булсагыз, проект та, кирпеч тә бирмибез, диләр. Дуамал холыклы, бик тә тәвәккәл һәм һәрвакыт халык мәнфәгатьләрен кайгыртучан рәис, проект эшләүне сорап, Зур Сәрдек урта мәктәбендә хезмәт дәресләре укытучы Бөек Ватан сугышы ветераны Гаян Гариф улы Әхмәтшинга мөрәҗәгать итә. Немец концлагереннан азат ителгәч, Франциядәге партизан хәрәкәтләрендә катнашкан елларындагы күзәтүчәнлеге ярдәм иткәнме, табигатьтән бирелгән осталыкмы – Гаян ага тиз көндә проектны эшләп тә чыга. Зур Сәрдек җирлеге элек-электән балта осталарына бай як, тирә-күрше авылларның бар осталарын җыеп, төзелешне башлап та җибәрәләр. Шакиров Нәфикъ җитәкчелегендәге ташчылар бригадасы бинага нигез сала. Ташны тирә-яктагы барлык үзәннәрдән җыялар, яңа таш карьерлары ачыла. Бураны, Нократ елгасыннан агып килгән сал агачларын тракторлар белән ташып бурыйлар. Төзелешкә кырык йортлык агач керә. Бура бурауда йөз кеше эшли һәм 1966 елның көзенә бина түбә астына кертелә. Эчке бизәү эшләрен Хәсәенов Фазыл җитәкчелегендәге штукатур-малярлар бригадасы башкара. Барлык төзелеш эшләренә Гаян ага Әхмәтшин үзе җитәкчелек итә. Колхоз рәисе сәхнә киемнәрен, тынлы һәм кыллы оркестр уен коралларын Мәскәүдән кайтарта. Ачылыш тантанасында оркестр уйнап торсын өчен, авыл балаларын уен коралларында уйнарга өйрәтергә Казаннан Мәсгуть Латыйпов дигән музыка белгече чакыртыла.

400 урынлы тамаша залы, кино кую җайланмасы, грим бүлмәләре, бай китапханәсе, иркен фойесы булган уникаль бина Бөек Октябрьнең 50 еллыгына, 1967 елның 7 ноябрендә ишекләрен ача. Ачылу тантанасы концертына чыгыш ясарга күренекле сәхнә осталары Гали Җәмлиханов, Фәйзулла Туишев, Зөләйха Хисмәтуллина, Әзәл Яһудиннар килә. Шуннан бирле, ярты гасыр буена, безнең сәхнәдә халкыбызның иң күренекле сәхнә осталары, барлык театрлары, әдипләре күп тапкырлар чыгыш ясадылар. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакльләре дә элек һәр сезонда безнең сәхнәбездә куелып килде.

Зур Сәрдек халкы – профессиональ тамашаларны алкышларга күнеккән, шул чыгышлар белән тәрбияләнгән халык. Сәхнәдән чыгыш ясаучы үзешчән артистларга да аның таләбе югары, килеп җитмәгән җиргә үз тәнкыйте бар. Халыкка мәдәни хезмәт күрсәтүче коллективыбыз, шул югарылыкны тотарга тырышып, бик тотрыклы иҗат итеп яши. 90-елларда вокаль инструменталь ансамбль белән Казан шәһәренә гастрольләргә килеп, Мәдәният сарайларында концертлар биргән бердәнбер авыл Мәдәният йорты буларак та тарихка кереп калдык. 2007 елда Мәдәният йортына, 40 еллыгы уңаеннан, Камил Шакиров исеме бирелде.

Бүгенге көндә тулы көченә иҗат итеп яшәүче ике «халык» коллективыбыз бар – 2007 елда халык театры исемен алган һәм

регионара халык театрлары фестивале лауреаты дигән дәрәҗә яулаган драма коллективы һәм 1997 елда халык коллективы исемен алган «Чәчкә» бию ансамбле. Бу ансамбль Туапсе шәһәрендә уздырылган бөтенрәсәй фестиваленнән ЮНЕСКО сертификаты алып кайтты. «Сердәш» фольклор төркеме дә «ТНВ» каналында, Федераль авыл Сабан туйларында еш чыгыш ясый. «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасының кул эшләре күргәзмәсе республикакүләм зур чараларда чит ил кунакларына күрсәтелә, Казахстанның башкаласы Астана шәһәренең Сабан туе кунакларына да тәкъдим ителде. Зур китап фонды, иркен уку залы булган китапханә дә бер дә бушап тормый. Студентлар һәм гимназия укучылары күп булу сәбәпле, нинди генә мәгълүмат алыйм дисәң – шул бар безнең китапханәдә. Халык китапны күп укый. Биредә мультимедиа чараларын киң кулланып уздырылган видеолекторийлар, истәлекле даталарга багышлап куелган китап күргәзмәләре даими яңарып тора. Экспонатларга бай музейга да авыл халкы бик теләп килә.

Соңгы елларда ирешкән уңышларыбыз – халык театрының 50 мең сумлык, Зур Сәрдек китапханәсенең 100 мең сумлык, «Мирас» музей проектының 160 мең сумлык, «Илле еллык мәдәният учагы» проектының 500 мең сумлык грантлар отуы; наркоманиягә каршы «Хәерле атна» проектының ноутбук белән бүләкләнүе – болар барысы да озак еллар буена тотрыклы коллектив булып иҗади эшләүнең нәтиҗәләре.

Бинабызның уңайлылыгына еллар узган саен гаҗәпләнәбез. Рәсәйдә тиңе булмаган Мәдәният йортын гап-гади авыл агайлары төзеп чыккан бит! Юбилей алдыннан, район җитәкчелеге ярдәме белән, Мәдәният йортының иденнәре яңартылды. Бәйрәм көнендә исә бу бинага гомер биргән ике шәхескә – Камил Фаяз улы Шакиров һәм Гаян Гариф улы Әхмәтшин истәлегенә бина диварына мемориаль такталар куелды.

Юбилей кичәсе һәркемнең күңелендә онытылмаслык хатирә булып калыр дип ышанабыз. Район башлыгы Сергей Димитриевич Димитриевка ихлас котлау сүзләре, тыйнак хезмәтебезне хөрмәтләп алып килгән бүләкләре, халык алдында безгә олы бәя бирүе өчен чиксез рәхмәтлебез. Якташларыбыз, Г.Тукай премиясе лауреаты, шагыйрь Газинур Морат, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты, Татарстанның атказанган артисты Фәрит Гафиятуллин, биология фәннәре кандидаты Мәһинур Сәмигуллина, медицина фәннәре кандидаты Илсур Шәймәрданов һәм башка бик күпләрнең чыгышлары кичәгә аерым бер ямь бирде, аның эчтәлеген тагын да тирәнәйтте. Инде аз санда гына калган булсалар да, диварларда кул җылылары сакланган төзүчеләребез дә килгән иде бәйрәмгә. Аларга җирлек башлыгының махсус әзерләгән кучтәнәчләре тапшырылды.

Юбилей кичәсенең иң зур иганәчесе «Игенче» хуҗалыгы җитәкчелеге булды. Районыбызның Мәдәният идарәсе җитәкчелегенә дә, уңышларыбызга ихластан куанып, үсендереп, куәт өстәп торуы өчен бик рәхмәтлебез. Ә без, үз чиратыбызда, тамашачы күзенә туры карап, сәхнәсе җыр-биюдән бушап тормаган Мәдәният йортыбызның, авылыбызның, Кукмарабызның исемен гомер буе зур сәхнәләрдән яңгыратып яшәдек, дип горурланып әйтә алабыз. Иҗат кешесе өчен менә шул зур бәхеттер.

Рәмзия ХӨСӘЕНОВА,
Зур Сәрдек мәдәният йортының
сәнгать җитәкчесе,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ

Татар халык җырларының поэтикасы

(Ахыры. Башы 2016 елның 4 нче, 2017 елның 1-4 саннарында)

Җыр һәм көй

Җырның музыкасы... Ул нәрсә? М. Исаковский бу сорауга болай җавап бирә: «Музыка – ул көй ярдәмендә кеше йөрәге белән шагыйрь сүзләре арасында урнаша торган үзенчәлекле контакт чарасы»[1]. Көй (музыка, мелодия) җырның сүзләренә канат куя, шагыйрь (халык) фикеренең таралу радиусын киңәйтә, җырга гомер өсти. Көй аркасында җырның таралу тизлеге арта. Шуңа күрә җырның абруе сүз мәгънәсенә генә түгел, көйнең аһәңенә дә бәйле.

Татар җырлары арасында сөю-мәхәббәт лирикасының драматик бер варианты булган «Башмагым» җыры яши. Мәгълүм булганча, бу җырның махсус көе дә бар. Бу җыр кайчан тугандыр, аны билгеләп булмый, әмма унтугызынчы гасыр дәфтәрләрендә ул инде очрый. Һәм бу җыр бүгенге көндә дә популяр. Халык җырларына ияреп «сонгый» (сәнгатьчә – «искусственный») җырлар язучы фольклорчы Ф.Туйкин 1912 елда «Сабанчы бабай җыры»н иҗат итә һәм матбугатта бастырып чыгара. Җырның текстына, «Башмак көенә» дип, искәрмә дә ясый. Әмма «Сабанчы бабай җыры» халык арасында популяр була алмый, чөнки аның мәгънәсе (яшь гомер узган, бабай, шул гомерен сагынып, сабанга чыккач, җырлап җибәрә) халыкта элек яшәп килгән «Башмагым» көенә туры килми. «Башмагым» көенә нинди сыйфатлар хас? Мәхәббәт, яшьлек наянлыгы – аның нигезендә әнә шундый аһәңнәр. «Сабанчы бабай җыры»нда исә гомернең фанилеге, пессимизм. Димәк, көй үзенең аһәңенә туры килерлек текст белән генә органик бәйләнешкә керә һәм яши ала. Халык җырлары өчен бу төп шарт.

Шундый ук хәл профессиональ сәнгатьтә дә күзәтелә. М. Исаковскийның «Лучше нету того цвету» исемле шигыренә өч композитор көй язып карый. Ләкин бары тик М. Блантер музыкасы гына шигырьнең мәгънәсенә тәңгәл килә, һәм бары тик шул көй генә җырны халыкка алып чыга. Моңа татар җырлары арасында да байтак мисал бар. Ә. Фәйзинең «Умырзая» шигыре 1934 елда языла, 1935 елда бу шигырьгә Җ. Фәйзи көй яза. Заманында аны Р. Ваһапов кебек талантлы җырчылар сәхнәдә җырлыйлар. Әмма «Умырзая»дагы мәгънәгә, фәлсәфи фикергә яшь композитор Җ. Фәйзи язган көй туры килми, һәм җыр умырзаяның үзе кебек кыска гомерле булып чыга. Җыр югала. Еллар уза, илле бишенче елларда бу җырның яңа варианты табыла. Шул ук сүзләрне халык үзе көйгә салган була. Димәк, текст, үзенә туры килерлек көйне көтеп, халык күңелендә еллар буе яткан. Тагы да кыскарак вакыт эчендә көй алмаштырган җырлар да була. М. Әмирнең «Тормыш җыры» драмасында Басыйр беренче вариантта бөтенләй башка көйгә җырлый иде. Халык исә икенче вариантын – Җ. Фәйзи вариантын кабул итте. Шулай да җырның нигезен сүз тәшкил итә. Фольклор белгечләренең әйтүенчә, сүздән башка көй яши алмый. Көй белән сүз кушылганда исә җырның төп мәгънәсе сүз өстенә төшә. Бик күп җыр иҗат иткән шагыйрь М. Исаковский да шул ук фикердә. Ул болай ди: «Җырдагы көй, үзен генә алганда, әгәр шулай әйтергә яраса, «конкрет түгел», ул әле ачык түгел. Көй кеше күңелендә аерым бер кәеф уятырга мөмкин, моны тон бирү дип атыйлар, әмма шулай да җырның сөйләменең конкрет мәгънәсенә кеше җырның сүз материалыннан төшенә»[2].

Татар халык җырларының эчтәлек, мәгънә ягыннан милли үзенчәлекләре булган кебек, татар халык көйләренең дә үзенчәлеге бар. Моны тикшерү музыка галимнәренең бурычы. Әмма татар халык көйләренең, музыка гыйлеменнән махсус хәзерлеге булмаган кеше дә сизә һәм аера ала торган сыйфатлары

бар: ул – тавышның юаш һәм тыйнак булуы һәм көй белән милли музыка коралының охшашлыклары. Татар халык көйләрендәге бу сыйфатны беренче булып Г. Тукай билгеләгән! «Бездә җырланган чакта тавышның йомшак булуы вә бераз уен коралы авазына охшашрак булуы, вә иреннәрнең дә мөмкин кадәр аз ачылуы мәкъбул вә мөстәхсән күрелә...

Минем исемдә калган: мәдрәсәдә чакта һәр шәкертнең хөсне тәвәҗҗеһен җәлеп иткән бер җырлаучы, үзенең иренен каты кәгазь сыярлык итеп кенә ачып, озын вә кыска көйләрне җырлап җибәрә иде».[3]

Җырларның бу милли үзенчәлеге нәрсә белән бәйле соң? Ихтимал, монда халыкның яшәгән географик район, хезмәт-көнкүреш үзенчәлекләре төп фактор булып саналырга тиештер. Африка негрларының көчле экспрессиягә корылган тиз ритмлы көйләре куе урман эчендә ерткыч хайваннарга ау процессының хәвефенә, һәр секундның сюрприз китерү мөмкинлегенә бәйле булуы ихтимал. Дала халкының көнкүреше исә акрын уйлауга, фикерләүгә, күзәтүгә бәйле. Шуңа күрә аларның көйләре озын, акрын темп белән башкарыла. Татар халкының көнкүреше дә акрын темптагы хезмәткә – терлек асрау, иген игү, йон эрләү, киндер туку, күн эшкәртү кебек хезмәтләргә бәйле. Татар җырларындагы салмак темп гасырлар буе барган әнә шундый салмак хезмәт нәтиҗәсе буларак туган дип уйларга нигез бар.

Фольклор белгече К. Бюхнер, борынгы җырларның барысында да көй белән сүз бергә туган, дип билгели[4]. Цивилизация заманында да халык җырлары көй белән бергә туганмы, әллә, аерым-аерым туып, бергә кушылганнармы – гомумән нәтиҗә ясавы кыен. Монда һәр ике очракның да булуы мөмкин. Әмма җырлар (көе мәгълүм булган текстлар) арасында еш кына аһәңе белән тексты бер дәрәҗәдә булмаганы да очрый. Конкрет әйткәндә, бик көчле аһәңле, эмоциональ бер көйнең эчендә гади генә текст яши. Мондый очраклар профессиональ поэзиядә дә күзгә ташлана: әйтик, рус композиторы А.А. Алябьевның «Сандугач» җыры бөтен дөньяга мәшһүр әсәр. Солистлар өчен бу җыр әле дә осталыкның иң югары баскычында булуны таләп итә. Сүзләре исә бик гади: «Соловей, мой соловей...»

Фольклор әсәрләрендә исә гади текстның көчле, эмоциональ көй белән янәшә яши алуы бер гипотезага юл калдыра: теге көйнең төп тексты югалмаганмы? Җыр текстларын көйләре белән «кавыштыру» бездә 1905 ел революциясеннән соң гына башланган бит. Дөрес, XIX гасырда ук төрле милләт галимнәре тарафыннан төрле максатларда татар җырларын җыю эше барган. Әмма 1930 елда Германиядә чыккан «Tatarishe Texte» дигән китапта берничә җырның исеме үзгәртелеп бирелгән. Мондый үзгәртүләр XIX йөз китапларында һәм егерменче йөз башында чыккан җыр җыентыкларында булмагандыр дип, әйтә алабызмы? Бу мәсьәлә киләчәктә ныклап өйрәнүне сорый.

Халык җырларының башка жанрлар белән уртаклыгы

Татар халык җырларының кайберләре мәкальләр белән уртак була алуына беренче башлап Н. Исәнбәт игътибар итте. Ул мондый җырны мисалга алган иде.

Аяз булса, айга көч,
Болыт булса, көнгә көч.
Кая барсаң да бер кояш –
Күбәләктәй җанга көч.

Тулысы белән алганда бу текст, әлбәттә, җыр, әмма бу җырның текстыннан мәкальләр дә аерып алып, ягъни текстны «таркатып» була. Монда менә нинди мәкальләр бар: а) Аяз булса, айга көч; б) Болыт булса, көнгә көч, в) Кая барсаң да бер кояш. Һәм соңгы юлы – Күбәләктәй җанга көч – әйтем. Тагын бер җырны мисалга китерик.

Манара биек булса да,
Кошлар оя ясамый.
Ал булса да, гөл булса да,
Туган илгә охшамый.

Җырның соңгы ике юлы – мәкаль. Бу мәкаль текстологик яктан төрле вариацияләрдә очрый. Кыскасы, җыр жанрының мәкаль жанры белән уртаклыгы бар икән, һәм бу уртаклык җыр текстының эченә афористик кисәкләрнең теркәлүе формасында икән.

Шундый ук, яки башкачарак характердагы уртаклыкларны без җыр белән әкият арасында да очратабыз.

Әкиятләр һәм җырларда еш кына бер үк образлы сурәтләү чаралары кулланыла. Кайбер вакытта бу чаралар берничә жанр (мәкаль, бәет, мәзәк һ.б.) өчен дә уртак була. «Уңга киткән уңар, сулга киткән туңар» мәкаль булса, җырга ул болай килеп кергән:

Без авылдан чыккан чакта
Уңга киткән юл булыр.
Чыгар кояш, сибәр нурын,
Бездин сәлам шул булыр.

Ләкин «уңга киткән уңар...» дигән мәкаль үзе үк әкияттән. Татар халык әкиятләрендә батыр егет бик еш кына шундый дилемма алдында кала – ике юл чатындагы язуны укып, карар кабул итә...

Әкиятләрдә очрый торган җиде төн уртасы, җиде юл чаты, җиде туган, җиде көн туй ясау җырларның әкият җанры белән уртак элементларын тәшкил итәләр.

Җиде уятып, җиде үбә
Җиде төн уртасында.

Җиде ятны үз итәләр,
Әле дә рәхмәт кызларга.

Җиде төн урталарында
Аһ, дусларым, дип әйтәм.

Җырларның бәетләр белән уртаклыгы зур. Кайбер җырлар халык күңелендә җыр буларак та, бәет буларак та яшәп килгәннәр. Боларның жанрын билгеләп, төгәллек кертергә тырышуның, безнеңчә, принципиаль әһәмияте юк. Мәсәлән, халыкта «Баламишкин бәете» дигән популяр бәет бар. Аны бәет буларак әйткәннәр, ул бәет Мишкин исемле бер яшь купецның акылына зәгыйфьлек килү аркасында Идел суына батып үлүе сәбәпле чыгарылган. Аның махсус көе дә бар. Әгәр моны, «Без әйтәбез, сез тыңлагыз – Баламишкин бәете» дип, башлап китәсең икән – бу бәет. Ләкин инде берәү Баламишкин көенә менә болай дип җыр башлый икән:

Әйдә, дуслар, җырлыйк әле
Баламишкин көенә.
Күләгәләрен күрсәм дә,
Күңелләрем сөенә, –
бу инде җыр.

(«Күләгәләрен күрсәм дә» – татар җырлары өчен генә хас синтаксик берәмлек. Кешенең, үзен күрмичә, күләгәсен күреп булмый, бу – алогизм. Әмма битен-гәүдәсен каплап урамнан узган татар кызын күргән егет нәрсә дисен тагын? Ул бит иң күбе шул күләгәне генә күрә).

Салават турындагы җыр да шулай гасырлар буе җыр булып та, бәет булып та йөри. Кем белә, бәлки «Газизәкәй балдыз» да заманында бәет булгандыр? Аның эчтәлегендә дә конкрет бер фаҗига яки драма төсмерләнә бит.

Татар халкы арасында бик популяр булган Зөлхәбирә бәете дә җыр жанрына зур тәэсир ясаган. Зөлхәбирә (карта уенында оттырылган кыз) образы җырларга татар кызының бәхетсез язмышын сурәтләүче җыелма образ буларак кергән, бу төр җырлар аеруча моңлы көйләргә җырланганнар.

Зөлхәбирә көлтә бирә
Арбадан кибәннәргә:
Башыңны имә, сереңне бирмә
Үзеңнән түбәннәргә, –

дип җырланган текстта кыз баланы горур булырга, үз бәхетенә аяк чалуларына баш имәскә чакыру ноталары яңгырый.

Табышмаклар белән халык җырларының уртаклыгы, беренче чиратта, әлбәттә, ритмикада. Күп кенә табышмаклар, нәкъ халык җырлары кебек, 7–8 яки 7–7 үлчәве белән төзелгәннәр. Аларда рифма, ритм, аллитерация кебек чаралар халык җырларындагы кебек. Мәсәлән:

Өй артында ак тана,
Мөгезем бар дип, мактана.

Бу табышмак үзенең көе, ритмикасы белән дүртьюллык җырның беренче яртысыннан бер дә аерылмый. Халык җыры «Шомыртым», мәсәлән, нәкъ шулай башлана:

Өй артымда шомыртым,
Яннарында кушкаен.

Кайбер табышмаклар тулысы белән җыр формасында төзелгәннәр. Кояш чыгу, бату турындагы табышмак, мәсәлән, дүртьюллык кыска җыр формасында төзелгән.

Алтын капка ачыла,
Тәңкәләре чәчелә;
Алтын капка ябыла,
Тәңкәләре җыела[5].

Ләкин болар «техник» яктан охшашлыклар гына булды. Әмма охшашлык – уртаклыкның төп сыйфаты – бу жанрларның мәгънәләрендә әле. Табышмаклар «тыңлаучылар алдына асылы читләтеп әйтү аша белдерелгән билгесез әйбер яки күренешне эзләп табу бурычын куялар»[6]. Хәзер охшашлыкны шул планда тикшереп карыйк.

Табышмакларда без, нәкъ җырлардагы кебек, параллелизмнар белән очрашабыз. Әмма табышмакта бу параллелизмның җырдан үзгә формасы – инкяр итү формасы ешрак кулланыла. «Агач түгел – яфраклы, тун түгел – тегелгән», дип әйтелә икән, без монда инкяр параллелизмы белән очрашабыз. Татар халык җырларында инкяр параллелизмнары бик сирәк күренеш. Ләкин немец, грек, литва халык җырларында параллелизмның бу төре очрый икән[7].

Татар халык җырларында исә табышмаклар белән уртаклык башкачарак. Беренче чиратта, әлбәттә, күчерелмә мәгънәлелек турында әйтергә кирәк. Табышмакта да күче-

релмә мәгънәлелек яки кинаяя еш очрый. Нәкъ менә шул сыйфатлар халык җырларының да поэтикасын тәшкил итә. Мисал:

Китәм дисең, китәм дисең,
Китсәң, мине дә ала кит (минедалакит),
Җәлләмәсәң, я утларга,
Я суларга сала кит.

Тексттан күренгәнчә, бу җыр – гашыйклар диалогының бер өлеше. Тексттагы сүзләр күчермә мәгънәгә ия: сүз бит чыннан да утка салу яки суга салу турында бармый. Монда күчерелмә мәгънә – табышмаклык бар. Я гыйшык утында яна торган итеп калдыр мине, ди гашыйк кыз (егет), я булмаса, араларны өзеп, өметләрне сүндереп кит... Суга салу – утны сүндерү.

Октябрь революциясенә кадәрге фольклор хезмәтләрендә такмаклар дигән жанрны аерып карау күзгә ташлана. Такмаклар фольклорның бик күп жанрлары белән бик тыгыз бәйләнештә. Аларның кайберләре тулысы белән табышмактан килә, ә кайберләре уен-бию җырлары белән аралаша, шулар эчендә «күмелеп кала». Уен-бию җырлары, такмаклар мәхәббәт һәм социаль эчтәлекле булырга тиеш. Уен-бию җырлары, такмаклар белән халык җырларының уртаклыгы турында сөйләп торуның әһәмияте юк. Болар арасындагы аерманы гына билгеләргә кирәктер. Аерма ритмикада, аларның кеше тормышындагы эстетик функцияләре бер үк. Уен-бию җырлары безнең фольклористикада тарихи яктан әлегә аз тикшерелгән. Югыйсә алардан бик күп нәрсә ачыклап булыр иде.

Югарыда китерелгән мисаллар җырның, ялгыз үскән жанр булмыйча, күп сыйфатлар белән фольклорның барлык жанрларына да бәйле булуын күрсәтә.

[1] М. Исаковкий. О поэтах, о стихах, о песнях. М., 1972, стр. 128.
[2] Шунда ук.
[3] Кара: Г. Т у к а й, т. 2, 271 б.
[4] К. Бюхнер. Работа и ритм. М., 1923, стр. 265.
[5] Татар халык иҗаты. Табышмаклар. Казан, 1977, 37 б.
[6] Шунда ук, 5 б.
[7] С.И. Минц, Э.В. Померанцева. Русская фольклористика. М., 1971, стр. 165.

Дуслык, туганлык, мәҗлес җырлары

Арыслан да белән, ай, юлбарыс –
Кайсы икән шуларның зирәге?
Җыен дус-иш бергә килгәч,
Онытыладыр дөнья кирәге.

Һаваларда очкан кошлар әйтә:
Агач башы безгә бостан, дип;
Кемне генә күрсәм, шулар әйтә:
Аерылма иске дустан, дип.

Ай яктылары бик якты
Утырып кына мәрҗән тезәргә;
Үз туганкайларың бигрәк яхшы
Утырып ла киңәш төзәргә.

Ындырларым тулы наратым,
Сарайларым тулы сары атым;
Егылганнар чакта таянырга
Сез булдыгыз минем канатым.

Бакчаларда гөлләр түтәл-түтәл,
Арасыннан былбыл кош үтәр;
Бу дөньялар шулай үтәр китәр,
Бергәлеккә, туганкай, ни җитәр.

Ак ла яулыкның парчасы
Һәрбер яулыкларда булсачы;
Сез туганнарның нурлы йөзе
Көн дә күз алдымда булсачы.

Беләзеккәйләрем сары алтын,
Туганым, күңелләрең ник салкын?
Туганым, күңелең салкынлыктан
Яна йөрәкләрем ут-ялкын.

Кара урманнарның, ай, артында
Ишетелә чалгы кайравы;
Сез туганнарның сөйләгән сүзе –
Сары сандугачның сайравы.

Ак кәгазьләргә май таммасын,
Кырып алу белән җуелмас;
Егетләргә кайгы берни булмас,
Дус-ишләре белән бер булгач.

Ямьле икән бу яланнар
Ак тирмәләр корып җәйләргә;
Кайда йөрсәң дуслар кирәк
Каршы чыгып атың бәйләргә.

Чыганак: Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (дүртьюллыклар). Казан, Тат. кит. нәшр., 1976, 141-143 битләр.

«Әгәр акылың җитмәсә, җыр тыңла»...

Мин тумышым белән Омски өлкәсенең Тара шәһәреннән. Нәселебез тарихы үзе бер гыйбрәтле китап, насыйп булса, журнал укучыларына бәлки ул китапның да кайбер сәхифәләрен җиткерермен, бу язмам исә җыр турында.

Мин Казанга килеп белем алып, 40 ел буена төрле югары уку йортларында югары математика укыттым. Җыр дигән дөньяның бөтен тирәнлеген бик соң – пенсиягә чыккач, әниемне югалткач кына аңладым. Әтием инде күптән вафат иде. Минем исемә, кинәт кенә, әтиемнең «Уел»лары», «Иске кара урман»нары, «Саҗидә»ләре бер-бер артлы төшә башлады. Ә мин бит аларны бик күптән, 10 яшемдә, әтием Галләметдин Кулеев совет концлагереннан кайткач тыңлаган идем! Аның тавышы искиткеч матур, моңлы иде, өстәл артында, күзләрен каядыр еракка төбәп, әнә шул йөрәк өзгеч моңлы тавышы белән җырлап утыра иде ул. Ул чакта, әлбәттә, аңламаганмын, 10 ел буена нахактан лагерьларда газап чиксәң (мин әти кулга алынып бер ай вакыт узгач дөньяга килгәнмен), кайткач та 9 ел һаман «халык дошманы» булып саналсаң, яраткан укытучылык эшенә юл ябылса, моңланырсың да шул.

Минем халык алдында чыгыш ясый башлавыма исә бер очрак этәргеч булды. КХТИда югары математика кафедрасында укыткан чагым. Укытучылар бүлмәсендә пианино бар. Без¬нең бер профессор шул пианинода төрле көйләр уйнап утырганда, мин Рөстәм Яхинның «Син кайда идең» җырын уйнавын сорадым, ә ул: «Җырлап күрсәтегез», – диде. Мин җырлап күрсәттем. Уйнаучыга ошады, һәм миңа Идел буе студентлар олимпиадасында җырларга тәкъдим иттеләр. Сәхнәгә юлым менә шулай башланды.

1997 елда мин Казан шәһәре Идел буе районының репрессия корбаннары оешмасын җитәкли башладым. Бу вазыйфаны җилкәмә алырга мине нәселебездән Сталин репрессиясенә эләгеп юк ителгән 10 (!) кешенең (шулар арасында икесе – бабаларым) язмышы этәрде. Биредә эшләгән 20 ел вакыт эчендә нинди генә язмышлар белән очрамадым мин! Элек Казанның һәрбер районында ветераннар өчен Көндезге ял итү үзәге (Стационар дневного пребывания) дигән нәрсә бар иде. Бу стационарларда гомер буена эшләп, ялга чыккан ветераннар, ике атна буена, яртышар көн ял итәләр иде. Иртән бер сумса белән бер стакан чәй эчеп, көндез беренче, икенче, өченчене ашап, аннан соң төрле лекцияләр тыңлап, концертлар карап уза иде көннәре. Кемнәр генә юк иде алар арасында: рәссамнар, шагыйрьләр, җырчылар, төрле музыка коралларында уйнаучылар. Әлеге үзәктә булган талантыңны күрсәтү өчен дә мөмкинлекләр бик зур иде. Без, курайда һәм мандолинада профессиональ дәрәҗәдә уйнаучы Вольфрам Газиев белән, вокаль-инструменталь дуэт оештырдык та әнә шул үзәктә атна саен концерт бирә башладык. Бу 2005 ел иде. Минем репертуарым, әлбәттә инде, әтиемнән откан борынгы көйләребездән тора иде. Әмма ветераннарның бу мәдәни-күңел ачу үзәкләре, себер татарлары әйтмешли, кемнеңдер «итенә тигән» ахры, Үзгәртеп кору чоры башлангач, алар барысы да берәм-берәм ябылды. Югары даирәләргә үзәкләрне калдыруны сорап хатлар җибәрдек. Хатларыбызда «без бушлай әбәтләрдән ваз кичәргә ризабыз, шул Р. Зорге урамындагы 35 йортның 4 бүлмәле фатирында урнашкан мәдәни-ял итү үзәген без – Бөек Ватан сугышы, тыл ветераннары, Сталин репрессиясе

корбаннары, Ленинград блокадасын, фашист балалар концлагерьларын узганнар һәм башкалар өчен калдырыгызчы!» дигән юллар бар иде. Хатлар җавапсыз калды.

Бутлеров урамында югары эрудицияле, талантлы кешеләрне үзенә туплаган Галимнәр йорты бар иде. Анда да бик күп чыгышлар ясарга насыйп булды. Бу вакытта инде безнең дуэтыбыз, киңәеп, җиде кешедән торган «Гөлҗамал» ансамбленә әверелгән иде. Ни аяныч, бу үзәк тә бетерелде.

Федосеев урамында, ямьле Казансу буенда Картлар йорты бар иде. Анда әби-бабайларга концертлар биреп, аларның җырлауларын, язмышлары турында сөйләүләрен тыңлап, күңелләрен күтәреп кайтып китә идек. (Андагы әби-бабайларның күбесенең балалары исәнсау икәнен ишеткәндә, әтием мәрхүмнең: «Табаклы аш кебек алдыңа килә барысы да», – дигән сүзләре искә төшә иде…) Ни кызганыч, ул йорт та ябылды, урамның да эзе калмады. Арча картлар йортында ясаган чыгышларыбыз да моңсу хатирәләр булып күз алдында калды. Казандагы «Сөләйман» мәчетендә без күзләре начар күргән, яисә дөм сукыр кешеләр алдында акапелла җырладык. Алар арасында Чечня, Ингушетия, Дагыстан, Башкортстан һ.б. җирләрдән килгән дин кардәшләребез дә бар иде, безнең белән бергә кушылып җырлыйлар иде.

Безнең «Гөлҗамал» ансамбле 8 ел буена ай саен Медиклар клубында концерт бирде. Ул мәһабәт сарайны җир белән тигезләделәр, аның холлары, инкрустацияләр белән бизәлгән баскыч рәшәткәләре, грим бүлмәләрендәге матур өстәлләр, креслолар, артистлар өчен бизәнү көзгеләре һәм башка бик күп элекке заман җиһазлары исемә төшсә, себерәк әйтмешли, эчем ачый. Клуб мөдире Сәйфетдинов Айдар Илдус улы безнең ансамбльне һәрвакыт мөләем йөз, ихтирам белән каршы алып, концерт уздырырга берсүзсез рөхсәт биреп килде. Бу клубның юкка чыгуы мәдәниятебез өчен шулкадәр зур югалту дип саныйм.

Әмма без беркайчан да күңел төшенкелегенә бирелмәдек. Алдыбызга куйган максат – татар халык җырларын, мәшһүр татар композиторларыбызның әсәрләрен саклап калу, килер буыннарга тапшыру максаты безгә һаман көч биреп, алга әтәреп торды. Үзебезнең Идел буе районында, шәһәребездә, авыл Сабантуйларында, Республика көнендә, «Балкыш» ветераннар фестивалендә ясаган чыгышларыбыз, яулаган дипломнарыбыз, грамоталарыбыз, рәхмәт хатларыбыз тырышлыгыбызның бушка китмәвенә дәлил булып тора.

Шунысын да әйтим, барлык җирдә дә бушлай җырладык һәм күп вакытта юл чыгымнарын да үз акчабызга күтәрдек. Кайбыч районының Борындык авылында җырлап кайткач, «Дулкын» гәҗитендә чыккан мәкаләдән өзек китерәм: «Менә кемнәрне сәхнәнең түренә менгезергә кирәк! Менә кемнәрне телевизордан күрсәтергә кирәк! Менә кемнәр ул чын татар моңын халыкка җиткерүчеләр! Фәрзәнәнең башындагы калфагыннан да, өстендәге камзулыннан да, бала итәкле күлмәгеннән дә чын татар рухы сирпелеп тора». Моннан да зуррак бәя була аламы!

2015 елда Дуслык йортында үзебезнең җыр эшчәнлегебезнең 10 еллыгы уңаеннан чыгыш ясадык. Шунда Бөтендөнья татар конгрессы «Гөлҗамал» ансамбленең һәрбер җырчысына, уен-коралында уйнаучысына – барыбызга Рәхмәт хатлары тапшырды. Бу күңелле мизгелләрне кичерү – бәхет, зур шатлык иде.

«Балкыш» 16 фестивалендә безнең ансамбль шәһәр җыелма хорында һәм Идел буе районы өчен җырларга тиеш булып чыкты. Җыелма хорны Альберт Зариф улы Шакиров җитәкли, ә Идел буе һәм Вахитов районнарының хорын Мулланур Гаян улы Габитов алып бара диделәр. Шуннан без ике урынга: Сәетгалиев исемендәге Мәдәният сараена һәм Мөгаллимнәр йортына йөри башладык. Хорда җырлау җиңел эш түгел икән, әмма хор җитәкчесе үзенең эшенә җаны-тәне белән бирелгән югары профессиональ җырчы, педагог һәм оста оештыручы булганда, тавышы, теләге булган һәркем коллективта җырлый ала дип уйлыйм. Беренче мәртәбә Мулланур Габитов җитәкчелегендәге «Мөгаллим»нең җырлавын тыңлагач, таң калдым. Мондый хорыбыз булгач, безнең телебез, моңыбыз үлми икән. Тик хорны югары биеклеккә күтәрергә кирәк. Казанда гына, Татарстанда гына түгел, ә Россиянең төбәкләрендә дә танытырга кирәк. Хор уңышлы эшләсен өчен шартлар кирәк. Беренчесе – инструмент, ягъни баян. Аның «көе китсә», бәреп-бәреп алалар – кем әйтмешли, көләрсең дә, еларсың да. Җырчыларга матур костюмнар кирәк, хәзергеләре хан заманында тегелгән. Ирләрнең сәхнә киеме бөтенләй юк. «Брановские бабушки» бөтен дөньяны гизеп йөри, без алардан киммени?

Туган шәһәрем Тарада беренче мәртәбә концертымда җырлагач (баянда икедән туган сеңлем Җинан уйнады), туганнарымның,

сабакташларымның, якташларымның исе китте: «Фәрзәнә, син бит биюче идең, инде жырлавың белән шаккатырдың», – диләр. «Мине жыр дөньясына әтием «кертеп җибәрде», – дидем. Үйлап-уйлап карыйм да, бу моңнар йөрәгемдә Сталин репрессияләрендә, сугыш кырларында һәлак булган нәселдәшләрем, кардәшләрем өчен әрнүдән туадыр. Милләтемнең киләчәк язмышы өчен хәсрәтләнеп, ана телебез бетеп барганга сыкранып моңланамдыр... (Безгә хәзер чит илләрдә – Австралия, Кытай, Финляндия, Америка һәм башка кыйтгаларда яшәүче милләттәшләребезнең динне дә, моңны да, телне дә саклавына сокланып, аларны үзебез өчен үрнәк итеп күрсәтергә генә калды бит.) Халкыбызның йөзек кашы булган «Ашказар», «Мәдинәкәй», «Сәгать чылбыры» кебек көйләребезнең бүген бөтенләй җырланмавы, «Сарман»нар, «Шахта»лар, «Уел»лар онытылып баруы җанны көйдерә. Хәзерге кайбер яшь композиторларның язган җырларында татар моңының әсәре дә юк.

Безнең һәрбер халык җырын мини спектакль дип санап була, аларны тыңлагач, эчтәлеге күз алдыңа килеп баса. Моңа бик күп мисаллар: «Гөлҗамал», «Порт-Артур», «Көзге ачы җилләрдә», «Уел»... Мин аларны бик яратып башкарам. 2007 елда үзем башкара торган татар халык көйләреннән торган компакт-дискымны да чыгардым. Безнең асыл җырларыбызны җиренә җиткереп җырласаң, башка милләт кешеләренең дә тәне чымырдый: бу хәлне мин Себердә, Вильнюста, Мәскәүдә, башка төбәкләрдә күзәттем.

Бервакыт бакчада агач төбендә өч ир эчеп яталар, мин яннарына килдем дә: «Әйдәгез мин сезгә җырлап бирим», – дидем. Күз алдымда концлагерьда 10 ел гомерен сарыф иткән әтиемнең «Уел»ны җырлавы гәүдәләнде. Мин дә «Уел»ны сузып җибәрдем. Җырлап туктагач, бөтен тәнен наколкалар каплаган урыс мужигы: «Минем тәнем чымырдый, каз тәне чыкты, нинди тормыш белән мин яшим», – дип сукрана башлады. Менә шундый ул безнең татар җырлары: сискәндереп уйландыралар да, җырлаталар да, елаталар да... Һәм тормышыңны яңа өметле юлга салырга да булышалар. Кыскасы, безнең себерәкләр әйтмешли, «Әгәр акылың җитмәсә, җыр тыңла...»

Фәрзәнә КУЛЕЕВА,
«Гөлҗамал» фольклор ансамбле җитәкчесе

Мәңге саекмас чишмәләр

Бу язмама Фәнзилә Җәүһәреваның «Кеше китә, җыры кала...» мәкаләсе этәргеч бирде («Түгәрәк уен», 2017 ел, 3нче сан). Анда манси һәм хант халыкларына хас булган мәдәни феномен – кешенең бакыйга күчәр алдыннан балаларына җыр калдыру йоласы турында әйтелә. Бу язма минем өчен бик әһәмиятле, чөнки 1968–1977 елларда Көнбатыш Себер – Төмән, Омски, Новосибирски, Томски һәм Кемерово өлкәләрендә себер татарларының музыкаль-поэтик хәзинәсен җыеп йөрдем. Ә Төмән белән Омски җирләрендә татарлар күрше ханты-мансилар белән гомербакый аралашып яшәгәннәр.

Җыр калдыру йоласы турында мәкалә авторына 70 яшьләр тирәсендәге манси хатыны Ханты-Мансийски шәһәрендә үткән фольклор фестивалендә сөйләгән. Һәм әлеге сөйләшүдән соң Ф.Җәүһәрева бик тә кызыклы нәтиҗә ясый: «...мин әлеге күренешнең буыннар арасындагы бәйләнешкә, нәсел-ыру мөнәсәбәтләренә кагылышлы фәлсәфә икәнлеген аңладым».

Манси хатыны бу йоланың мәгънәви эчтәлеген болайрак аңлата: «...эти-баба җыры – ул синең миеңдә, акылыңда... Аны теләсә ничек башкарып булмый. Ул, үз вакыты җиткәч, яшәешеңә бәя булып, синең күңелеңә кереп урнаша, күңел аркылы гына авазга әйләнә. Аваз исә җыр булып бик озак еллардан соң гына көйләнә башлый».

Бу ханымга 70 яшьләр тирәсе, тик ул әле әтисе җырын һаман күңеленнән генә башкара, балаларына җырлап күрсәткәне юк, «мәңгелеккә киткәнче, насыйп булса, җырлармын», ди.

Моннан нәкъ илле ел элек, 1968 елның җәендә без Фатыйх Урманчеев белән Омски өлкәсенең Ишемтамак (Усть-Ишим) районының Зур Тибенде авылында Биктимер Абитов дигән (1918 елгы) бик тә кызыклы кешегә тап булдык. Сугыш ветераны Биктимер абый безне себер татарларының борынгы һәм шул замандагы җырларын күп белүе белән таң калдырды. Ул

безгә 40тан артык җыр тапшырды. Атна буе аны яза-яза хәлдән тайган 15 килолы магнитофоныбыз ахыр чиктә ватылып тынып калды. Бездән бигрәк, Биктимер абый кара кайгыга батты: инде җырлар, Казанга китмичә, аның күңелендә генә калачакмыни? Колхоздан тиз генә машина юнәтеп, район үзәге Ишемтамакта магнитофонны төзәтеп кайттык.

Биктимер абыйның өе халык белән шыгрым. «Җиктем күк юрга», «Исәт», «Сәвә», «Милай Мәхмүсә», «Абуталип», «Прахуп Мәхүп», «Өмә җыры», «Сәйфелмөлек» кебек якут-җәүһәрләрне Зур Тибенде кешеләре дә тыңлады, безнең магнитофон да отып алды. Казанга кайткач, бу җырлар 1972–1985 елларда Казан телевидениесе аша барган «Халык җәүһәрләре» тапшыруында, күпсанлы радиотапшыруларда, Бөтенсоюз фольклор конференцияләрендә яңгырады.

Ә менә аның иң бәхетле җыры «Ямщикәй» булды. Ул Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең репертуарында үз урынын алды; шуның өстенә, ТНВ каналы аша бу җыр белән бик тә үзенчәлекле клип та күрсәтелә башлады.

Хикмәт шунда ки, Биктимер абый бу зур мирасның күп өлешен әтисеннән өйрәнгән. Әтисе, Мәлик бабай, әйләнә-тирәдә дан тоткан җырчы-ямщик булган. Безне таң калдырганы: Мәлик бабай, үлем түшәгендә дә, улына җырлар өйрәтеп яткан.

Менә кайда музыкаль традициянең көче, менә кайда саекмас чишмәләр!

(Шунысын да әйтеп үтәм: Биктимер абый кебек феноменнар әкият сөйләүчеләр арасында да бар. Мәсәлән, шул ук Ишемтамак районының Эбаргуль авылында 70 яшьлек Хамматов Әхмәт бабай егерме әкият яздырды.)

Инде хантлардагы феноменга әйләнеп кайтыйк. Аларда балаларга җыр тапшырып калдыру йоласы белән Мәлик абыйның улына үлгәндә дә җыр өйрәтеп ятуы арасында тәңгәллек бармы? Минемчә, бар. Сәбәп, алдан әйтеп үтелгәнчә, себер татарларының ханты-мансилар белән янәшәлегендә. Галимнәр фикеренчә, Омски өлкәсенең Усть-Ишим районы себер татарларының Курдак-саргат (Тевриз) төркеменә карый. «Тевризский район занимает окраинную ее часть, а основной массив татарского населения сосредоточен здесь в Усть-Ишимском районе, где проживают потомки саргатов и курдаков» (Н.А.Томилов. Тюркоязычное население Западно-сибирской равнины. Изд-во Томского университета. Томск, 1981, 114 б.). Шушы ук китапта тагын мондый кызыклы мәгълүмат бар: «От хантов Васюганья курдакско-саргатские татары были отделены болотами. Но в состав самого этого тюркского населения в качестве компонента частично вошли и угры, вернее всего, южные ханты, проживающие к приходу сюда тюрков по Иртышу. Массовая ассимиляция хантов тюркским населением началась, как считают археологи, в лесном Прииртышье с начала XIII в., хотя отдельные группы тюрков проникали в этот район и раньше» (118 бит).

...Ә минем бурыч – Биктимер абый миңа тапшырган җырларны, нотага салып, китапка тапшыру. Китап бу хәзинәне себертатар халкына җиткерер. Бу халыкның уллары-кызлары ул җырларны өйрәнеп, үзләренең улларына-кызларына тапшырыр. Бу да феноменаль тәҗрибә, күренеш, йола-гадәт бит!

Илгиз КАДЫЙРОВ,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

Иртыш буенда яшәгән себертатар гаиләсе. XX гасыр башы. Фото интернет челтәреннән алынды.

Наис ГАМБӘР

МА-ТУ-У-У!!!

(хикәя)

* * *

Казанга без таң алдыннан килеп төштек. Машина бәллүендә йокымсырап барган җиремнән күзләремне ачсам, ни күрим: ул болынкырлар, ул урман-үзәнлекләр – бар табигать алсу нурлар балкышына күмелгән иде; нәкъ Тукайдагыча «галибанә яктырып, әкрен генә ал таң» атып килә иде. Әйе, язлар үтеп, җәйләр җиткәч, печән өсте кергәч кенә була торган, анда да йөз елга бер генә тапкыр кабатлана алырдай үтә дә сәгадәтле вә хиссиятле бер иртә иде ул: Кояш әле агач биеклеге дә күтәрелергә өлгермәгән, дөнья-хәят инде сихри нурлар белән тулган. Офыклар – алсу, алсу; кая күз текәмә – яшеллек, яшеллек: урманнар – яшел, кырлар – яшел... Күктә исә – җәяүле болытлар төркеме, кошлар өне, кошлар моңы...

«Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә». Кыскасы, җиһанда уяну шатлыгы, яшәү хөрлеге! Әнә иртәнге таң нурларында балкып утырган Казан да күренде. Исәнме, иртә! Исәнме, Казан!

* * *

Шулай да Мөслим – Казан юлы безне шактый талчыктырган иде, «КамАЗ»ыбызны йөк алырга килгән склад каршына китереп туктаттык та, эш сәгате башланганчы бераз баш терәп алу зыян итмәс иде дип, һәркайсыбыз үзенчә урын хәстәрләргә керештe. Шофер егет белән Рәйхан Хантимеров кабинада баш төртеп калдылар, ә мин, җаныма урын табалмыйча, машина әрҗәсенә үрмәләдем. Төнлә белән юлда безне узып киткән йөк машинасыннан төшеп калган берничә фанера кисәген алып салган идек һәм мин соңгы бер ел эчендә өстән төшмәгән фуфайкамны алдым да урман исе, туган як каены исе аңкытып торган ятагыма аудым. Ләкин кая ди ул йоклау! Уйлап кына кара син: әйткәнемчә, күз алдымда аллы-гөлле нурлар биешә, ә күңелдә – борчулар, борчулар...

Безнең ул чакта рәссам егет Рәйхан Хантимеров белән Мөслим районы үзәгендә Туган якны өйрәнү музее оештыру нияте белән җенләнеп (мин башкача әйтә алмыйм) йөргән көннәребез иде. Казанга килүебез дә шул хаҗәттән иде: ясалма киез кирәк безгә һәм бик күп кирәк. Табып булырмы аны, без теләгәнчә бирерләрме, буш кул белән кайтып китмәбезме? Гавәм каршында көлкегә калмабызмы? Зурдан куптык ла, хәерсез; җитмәсә, бу дөньяда, сине аңлаучыдан битәр, алдаучылар күбрәк ич. Мөслимдә дә, әнә туган җирендә, күз күргән кешеләрең, моңа турыдан-туры «җаваплы иптәшләр», күпме тупсалар таптап йөреп тә музей ачу өчен яраклы бина табып бирә алмадылар. Һәм без череп беткән бер «тавык кетәге»нә кереп утырырга мәҗбүр булдык. Югыйсә, без уйлаганча, бу эшкә бөтен район җәмәгатьчелеге кубарылырга тиеш иде дә бит, юк шул, юк. Мөслимнең әле бу, әле теге почмагында шәхси «хан сарайлары» гөмбәдәй үсеп чыккан бер мәлдә, без – ике хәерче дивана! – үз дөньябызны онытып, оешмадан оешмага бусага таптап йөрдек: «Фәлән Фәләнеч, ярдәм итегез инде, музей өчен бер-ике кило кадак» яки «бер-ике кубометр такта табып булмасмы», янәсе. Йә, хурлык түгел идемени бу? Әйтерсең лә музей дигәннәре безгә генә кирәк!..

Ярый, без бу хурлыкка түздек. Илшат та түзде (ул музейчылар командасының өченче әгъзасы иде). Безнең көндәлек сорауларга, әлбәттә, «тиешле иптәшләр» дә түзде. Чөнки күп очракта, аларның колагы ишетми, күзләре күрми торган иде. Ә бит музей аларга да «кирәк» иде. Рухи хаҗәтләрен канәгатьләндерү, халык алдында, тарих алдында торган бурычларны үтәү өчен түгел, әлбәттә, югарыдан килгән рәсми кунаклар алдында: «Менә без дә тик ят-

мыйбыз, халык өчен яшибез», – дип шапырыну өчен кирәк иде музей аларга. Шулай булмаса, алар без бушка эшләп йөргәндә, әйтик, булган экспонатларны саклап калу ниятеннән музейга магистраль үткәргечтән җылылык кертү өчен күкрәгебез белән диярлек асфальт юл астыннан тоннель тишеп чыкканда: «Первыйның рөхсәте юк», – дип, әрекмән астына качмаслар иде дә, ахыр чиктә, «Первый» өйдә юк чакта без эшкә керешкәч: «Юлны бозсагыз, үзегез җавап бирерсез», – дип, бармак янамаслар иде. Хәер, андыйлардан ни сорыйсың, куркаклыклары өстенә, түргә иске чабата элеп куйсак, музей була, дип уйлый иде ич алар.

Ләкин монда бер яманаты чыккан партократияне генә гаепләү дөрес ук тә булып бетмәс иде. Әйтик, алар «по назначению» шулай сукырлык язмышына мәхрүм ителгән дә булсыннар, ди, ә аларны сырып алган укымышлылар кайда иде? Аннары, бер уйласаң, аларны да гаепләп булмый кебек: халкыңның миеннән гасырлар буена тарихи аң суырып алынгач, ни хәл итәсең; икенчедән, илдә гомуми буталыш барган бер мәлдә нигә әле үзеңне кайгыртып, калганына күз йомып яшәмәскә – җайлы ич!

Тарихи аң, дигәннән, шундый бер хәл булып алды. Кечерәк кенә бер оешмада баш инженер булып эшләүче бер иптәш – замана зыялысы! – үтеп барышлый музейга сугылып чыккан иде. Менә шул түшәмгә асылынып куелган мамонт сөяген күреп алды да: «Бәй, бездә дә тарих булганмыни?» – дип гаҗәпкә калды. Менә шулай, җәмәгать!

Сүз дә юк, «илдә бер дус булмаса да, ил бөтен дошман түгел» дигәндәй, музей төзелешенә дә ихлас күңелдән ярдәм итүчеләр аз булмады. Исемнәрен аерып атамастан, шуны гына әйтә алам: кылган игелекләре күләменчә халык исеменнән рәхмәтләр яусын аларга!

Ләкин музей ачылу көнен иң зарыгып көтүчеләр – балалар иде. Хәтердә ич, музей төзелә икән, дигән хәбәр таралуга ук көн саен диярлек биш-алты укучы бала килә иде дә:

– Абыйлар, көне-төне шакылдыйсыз, сездә бик кызык, диләр, карап кына чыгыйк инде, – дип, күз яшьләре белән генә ялвармыйлар иде.

Аннары әбиләр, бабайлар килә иде. Алар исә, яшьлекләрен исләренә төшереп, барлыюклы экспонатлар белән танышып йөргәннән соң:

– И оланнар, бик тә рәхмәтле эш башлагансыз икән, Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламасын, – дип, берсеннән-берсе матур теләкләр теләп, үсендереп чыгып китәләр иде. Ходай түгел, нәкъ менә алар һәм энтузиастлар, авыл мәктәпләрендә музей почмаклары оештырган фидакярләр үзләренең ярдәменнән ташламады безне. Аларның тырышлыгы белән чүплек башларында аунап яткан, йә булмаса сандык төпләрендә, чорма-чоланнарда кадерләп сакланган халыкның күңел җәүһәрләре музей түрендә урын ала башлады. Шулай ул, шулай булырга да тиеш: музейны аны бер-ике кеше генә төземи, төзи дә алмый, аны халык үзе тудыра: көндәлек эше, яшәеше, көн итеше белән барлыкка китерә. Их, җәмәгать, төрледән-төрле музейлары булган халык нинди бәхетле халык ул! Беркөнне радиодан ишетеп калдым: Германиядә ел саен йөзләгән музей ачыла икән. Ә безнең... авылларда түгел, Казаныбызда – башкалабызда! – тарихыбызны өйрәнүче музей юк. Адәм көлкесе. Милли музеебыз юк!..

* * *

Менә шундый уйлар белән йокыга китә алмыйча күпме изаланып ятканмындыр, бервакыт лаштыр-лоштыр атлап килгән берәүнең нәкъ безнең машина янында туктап калуы сискәндереп җибәрде – таң ката нишләп йөри бу бәндә? Мин теләр-теләмәс кенә урынымнан күтәрелергә мәҗбүр булдым. Карасам, өстенә аксыл төстәге таушалганрак плащ, башына ямьшәйгән кәпәч кигән берәү кулларын маңгаена куйган да, янтая төшеп, Күк йөзенә текәлгән. Ә Күктә... Күктә – тантана: Кояш инде шактый күтәрелергә өлгергән: гөмбәзи җиһан – биек, тирән, ачык; көн туып килгән офыкның бер читенә «туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене... аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме».

Теге Диванам әнә шул биниһая тирәнлеккә кереп чумган да уйга талган. Ул Күк йөзен күзәтә, мин – аны. Һәм шул мәлдә миемне бер гасабилы уй көйдереп узып китте: «Йа Хода бәндәсе, тегеләйрәк түгелме сон син?»

Әйе, ул акылга җиңелрәк бер бәндә иде; көл төсле йончу йөзенә саран гына сирпелгән елмаюы да ничектер, гадәти кешеләргә хас булмаганча, үтә дә моңсу һәм газаплы иде шул аның.

«...Ни күрә икән ул тирән Күк чоңгылларында? Нинди уйлар бәргәләнә икән аның зәгыйфь аңында? Нинди кичләр сулкылдый икән аның йончыган, талчыккан, талкынган җанында?»

Чү! Тукта! Ни хакым бар соң әле минем аны шулай кимсетергә?! Каян беләсең, бәлки, рухы белән ул миннән мең мәртәбә сәламәтрәктер? Бәлки, бу дөньяның барышын миннән миллион тапкыр дөресрәк тә, тулырак та аңлый торгандыр? Бәлки, ул көндезен дә Күк гөмбәзенә

сибелгән йолдызларны күрә алу кодрәтенә ия булган бер җан ияседер?..

Менә аның сүрән, моңсу күз карашлары кинәт яктырып китте, кипшергән иреннәренә, бүлтәеп торган бит очларына (әллә офыктан сирпелгән нурлар уйнаклавы гына идеме ул?) алсулык йөгерде, янтык-какча гәүдәсе тураеп, күкрәге киерелеп киткәндәй булды. Кыскасы, аны күз алдымда алыштырып куйдылармыни: әле генә боегып басып торган җан иясе бу минутларда барлык җаны-тәне белән, барлык вөҗүде белән көлә-шатлана тантана итә иде; газаплы авырудан соң кинәт савыгып киткән кеше кебегрәк бер ләззәтле халәттә булса кирәк иде ул.

Талгын җил исеп куйды. Ул, кәпәчен кулына алды да, башын горуранә тоткан хәлдә, сакаурак күкрәк тавышы белән Күккә текәлеп бер сүз, бары бер сүз әйтте:

– Ма-ту-у-у!..

Миңа ничектер уңайсыз булып китте, үземне ярамаган эш өстендә тотылган кешедәй хис иттем. Ул бит берүзе, тулы бер Җиһан белән күзгә-күз калып сөйләшә иде ләбаса! Дөресрәге, ул мине шәйләмәгәндер дә әле, шушы тузанга баткан машиналар, акшары коелып беткән шыксыз йортлар, вак-төяк мәшәкатьләр каршында дер калтырап торган кешеләр – берсе дә, берсе дә юк иде аның өчен бу минутта! Ул бар да Җиһан бар...

Аннары ул, шулай сәер генә көлемсерәп бераз басып торды да, әкрен генә, җирне авырттыра күрмим дигәндәй, сак кына атлап, урыныннан кузгалды. Биш-алты адым киткәч, тагын Күк йөзенә күтәрелеп карады һәм тагын, үзе генә аңлаган телдә, әлеге сүзне кабатлады:

– Ма-ту-у-у!..

Ул китеп барды. Минем өчен гелгә, мәңгелеккә... Шул китүе белән мәңге чишелмәслек сорау да биреп калдырды: «Әй, кем идең син матурлыкны дөньядагы барлык адәми затлардан да ныграк тоя алган зәгыйфь акыллы изге җан иясе? Күктәге матурлыкка гына гашыйкәсир идеңме син, әллә күңелеңдә изрәп яткан изге хисләрең кодрәти сүз булып оешып чыктымы?»

Мин тәмам гаҗиз идем. Бер атылуда машинадан сикереп төштем дә Рәйханны дер селкетә башладым.

– Син нәрсә, понимаешь, сәхәр вакытында төш күрә-күрә йокы симертәсең, җаны бар кешеләр әнә Җиһан белән сөйләшәләр...

Үзем шаяртмакчы булам, үземнең башта бөтенләй башка уйлар. Рәйхан да минем кебек юләррәк кеше: югыйсә тора салып буш кул белән музей төзүгә алынып идемени, булып узган вакыйга хакында бер-ике сүз әйтү белән чикләвекнең юкәдә икәнлегенә тиз төшенеп алды – машина яныннан бер-ике адым читкәрәк китте дә Күк йөзенә текәлеп:

– Нигә, ма-ту-у-у... ич! – дип куйды.

– Чынлап та, ма-ту-у-у... ич!

Бу юлы инде әлеге Илаһи сүзне без икебез беравыздан кабатладык.

* * *

Бу хәлләр әле кичә генә булып узган кебек иде, уйласаң, биш ел гомер узып та киткән икән. Гомер узгандыр, анысы, уза инде ул, әә шул вакыт эчендә бик күп вакыйга-күренешләр күңелгә кагылмыйча да узып киткәндер, бәлкем, ләкин әлеге хикмәтле Сүз колак төбемдә һәрдаим яңгырап торды, дисәм, валлаһи, гөнаһ булмастыр. Үләргә җитеп йөргән иң бәхетсез көннәремдә дә, түбәм белән болытларга орынып үткән мизгелләрдә дә шул бер Сүз гел күкрәгемдә сулкылдап килде:

– Ма-ту-у-у!..

Моңарчы мин аны, таңда Хозыр Ильястай пәйда булган теге гөнаһсыз зат кебек, Алла белән сөйләшкәндәй, бары үзалдыма гына пышылдый идем. Юк, алай гына да түгел, ул җаным буйлап үз уңаена, эчтән тын гына ага бирә иде. Ләкин күңелгә кайчак шом да килә: «Нигә соң әле бу дөньяның ма-тур-лы-гын күбрәк күрә алган, тормышны матурайту сәләтенә ия булган кешеләргә яшәве торган саен ныграк кыенлаша бара? Нигә ишетмиләр аларның кодрәтле сүзләрен? Әллә бөтен гавәм чукракланып беттеме соң, каһәр суккыры! Каты күңелле «Акыллы»лар күбәйгән саен, нечкә күңелле «Исәрләр» азая барамы соң әллә?»...

Шуңа да минем менә бүген Күкләрне яңгыратырлык, Җиһанны иңрәтерлек итеп кычкырасым килә: җаны исәннәр – ишетерләр, теле барлар – кабатларлар, күзе барлар – күрерләр, иншалла!..

– Ма-ту-у-у-у!..

– Ма-ту-у-у-у!..

1993

Төксер тавында 1 май бәйрәме. 1967 ел.

Фотолар
Иксановларның
гаилә альбомыннан алынды.
Лаеш районы,
Татар Сараланы авылы.

Балалар бакчасында. 1950 нче еллар.

Авыл яңа урынга күчкәннән соң, клуб бакчасына агачлар утырту. 1954 ел.

Мөхәммәт ГАЛЛӘМ

Байлык вә мал

Аллаһу Тәгалә Хәзрәтләре һәр акыллы һәм сәламәт кешегә хезмәт итеп, эшләп, дөнья кирәк-яракларын табуны, мөлкәткә ирешүне әмер иткән. Кешеләрнең җилкәсенә йөк булмау фарыз ителгән, көче-куәте бар кешегә теләнеп йөрү хәрам кылынган.

Җиһан – төрле ризыклар, нигъмәтләр белән бизәлгән, гомуми бөек бер ашъяулыктыр. Һәр тарафтан Аллаһ колларына мал казану яки ирешү ишекләрен ачык вә ирекле куйган.

Дөнья – ахирәткә юнәлгән күз бәбәге кебектер, аны никадәр яхшы һәм тугры куллансак, ул шул дәрәҗәдә әбәди яки мәңгелек юлчылыгыбызга хисап үлчәме булыр.

Ислам динендә яшәү ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен садака, зәкят бирү, Хаҗ кылу кебек гыйбадәтләр белән бәрабәр, дошманнардан саклану өчен гаскәр тоту, бала-чага үстерү вә өйләндерү, күршеләргә, мосафирларга – ярдәмчел, ятимнәргә игътибарлы булу кебек инсани вә әхлакый гүзәллекләр, вазыйфалар да бардыр. Боларның һәммәсе табигате белән казанышка, хезмәткә вә, ниһаять, бай булып яшәүгә кайтып кала. Шулай булгач, мөселманлыкның нигезендә башкаларга йөк булып, хезмәттә, эштә булдыксызлык күрсәтеп, ачарбак булып йөрүләр һич кенә дә юктыр. Бу рәвештә яшәү ислами тормышка саналмас. Шәригать кануннары нигезендә дөньяның һәртөрле нигъмәтләреннән файдалану динебезнең әмередер.

Коръән Кәримнең «Бәкара» сүрәсенең 29 нчы аятендә болай диелә:

«Җир йөзендә ни булса, Ул барысын да сезнең өчен яралтты. Соңра Күккә юнәлде, аны җиде кат итеп корды. Ул барысын да белүче».

«Әгъраф» сүрәсенең 31-32 нче аятьләрендә бодай диелә:

«Әй, Адәм балалары, намаз укый торган урынга барганда һәрвакыт пакь киемнәр киегез; ашагыз, эчегез, ләкин (артыгын) исраф кылмагыз. Аллаһ исрафчыларны сөйми».

Ә «Нәхел» сүрәсенең 114 нче аятендә болай боерыла: «Аллаһ биргән хәләл һәм саф ризыкларны ашагыз. Аллаһның юмартлыгына шөкер итегез. Әгәр сез, чыннан да, Аңа гына гыйбадәт кыласыз икән».

Бу нигездә тагы да бихисап аятьләр бардыр ки; алар мөэмин кешенең дөнья нигъмәтләренә вә дәүләтенә лаек булып яшәвен белдерәдер.

Әфәндебез хәзрәтләре дә хәдис шәрифләрендә бу мәсьәләгә кагылган мөһим нәсыйхәтләр бәян итә. «Аллаһым! Фәкыйрьлектән, юклыктан, хурлык-кимсетелүдән Сиңа сыгынамын», – дип боера.

Икенче бер хәдис шәрифтә исә:

«Аллаһудан курыккан кешегә бай булу куркыныч түгел, ә үзе бер куанычтыр. Ләкин Аллаһ бәндәсе өчен саулык-сәламәтлек – байлыктан да яхшырактыр, күңел тынычлыгы, җан рәхәте – мөһим нигъмәтләрдәндер», – дип боерыла.

Башка бер хәдис шәрифтә дә:

«Аллаһ бай бәндәне – изгелекләрне яшерен башкаручыны, фәкыйрьләр өчен әченгән-өзгәләнгән колын бик сөяр», – дип бәян ителә.

Аңлашыладыр ки, аять җәлилә вә хәдис шәрифләрдә, байлык һәм барлык мактауга лаек ителә. Әмма Аллаһ колы булу, туклыкта яшәү, шөкер итү, гүзәл әхлак шарт итеп куела. Дин вә әхлакка таянмаган байлыкларның баш бәласе, ахирәт газабы булуы бәян ителә. Никадәр үрнәктер ки «Нух» сүрәсенең 11-13 нче аятьләрендә әйтелгән сүзләр: «Яманлыктан баш тартсагыз, Аллаһ өстегезгә мул яңгыр яудырыр, дидем. Сезнең малларыгызны, угылларыгызны арттырыр, сезгә бакчалар (җимеш бостаннары), чишмәләр бирер, дидем. Нишләп соң сез Аллаһны кирәгенчә олыламыйсыз?»

Әйе, бу матур галәмдә бакчалар, елгалар арасында гаилә тормышының язларын яшәрткән Аллаһуга шөкердә булу, бу дөньяда кеше буларак җаваплы, вазыйфа-

лы булганыбызны һичбер минутта онытмау, тәрбияле бер кол булу нинди бөек дәрәҗә булса, боларны инкарь итү нинди түбәнчел тәкәбберлектер. Мондый каты бәгырьлелекнең үлчәнәчәк аршыны кайда дисәк, җавап: «Аллаһуның нигъмәтләре эчендә яшәп тә, Раббыбызга каршы булу, дөресрәге, Аллаһуның нигъмәтләрен Аллаһуга каршы кую хатасын, аның гөнаһларын җәһәннәм уты тазартыр».

Мөхтәрәм мөэминнәр! Байлык вә мал мәсьәләсенә Ислам дине хуплау-мактау белән бәрабәр, тәнкыйть күзе белән дә карый. Ислам диненең байлыкны мактавы яисә тәнкыйтьләве, дөнья малын яхшылыккамы вә яманлыккамы куллану-файдалануга бәйле.

Аллаһуны зикер итүдән, гыйбадәтләрдән ераклашмау, ахирәт юлыннан тайпылмау, гөнаһларга, исрафларга, хөсет-дошманлыкка, урлашу вә саранлыкларга батмау, бирүче кул булу, фәкыйрьләрне кызгану шартларына туры килгән байлык – хупланган, яки Аллаһ каршында кабул булган байлыктыр.

Дөнья алдаткычларына уралмаган, мәңгелек киләчәкне – ахирәтне аңлаган, шөкранә кылучы, ярдәмчел, изгелек кылучы, Аллаһуның әмерен җиренә җиткерүче, зәкят, Хаҗ вазыйфаларын тугрылык, хаклык белән башкаручы ачык күңелле байлар – хәлле кешеләр Ислам каршында бик кыйммәтледер. Ләкин борынын ике аршын күтәргән саран, тар күңелле, исраф итүче, мәрхәмәтсез, гөнаһ бәндәсе булган байларның һичбер кыйммәте булмас. Аларның малы – сыртларындагы ут газабыдыр.

Коръән Кәримнең «Монафикълар» сүрәсенең 9 нчы аятендә Аллаһу Тәгалә боерадыр ки:

«Әй, иман китергән халык, малларыгыз (байлыгыгыз), балаларыгыз Аллаһны оныттырмасын. Кем Аллаһның исемен оныта, шул зыян-зәхмәт күрер».

Мал-мөлкәт

Акыллыга баш кыйбат, акылсызга мал кыйбат.

Бал – балчык, мал – кылчык.

Дин кардәш булса да, мал кардәш түгел.

Әвәлге байлык – бала, икенче байлык – белем, өченче байлык – мал.

Җан кардәш булса да, мал кардәш түгел.

(Бай туган ярлы туганына ярдәм итмәгәндә.

Төрдәше: Мал карендәш түгел, җан карендәш.)

Җан рәхәте – тән белән, тән рәхәте – мал белән.

Ике дөнья тоткасы – мал.

Ир күрке – мал, үзән күрке тал.

Мал ачуы – җан ачуы.

Мал башка бетәр, кына ташка бетәр.

Мал белән бала – дөнья зиннәте.

Мал – бәгырь ите.

(Төрдәше: Мал – бавыр ите.)

Мал булса, балаларга мал кала, булмаса, бурыч кала.

Мал – җанның юнгысы.

Мал кыйбат түгел, җан кыйбат.

Мал мәшәкать тудыра.

Мал мөлкәте тамактан керер,
Җан мөлкәте колактан керер.

(Колактан кергәне – белем, киңәш, акыл, тәҗрибә, ишетү, өйрәнү.)

Малның таягы булсын.

Мал төрекмәннең түрендә, арысланның авызында.

(Ерак һәм табасы кыен, дигәннән.)

Миндә булсын, миндә булмаса да, илдә булсын.

Өй салмыйча, мал булмый.

Яхшы ат малдан артык.

Бал тапмаган корт булмас, мал тапмаган егет булмас.

Бар итәргә – йөз ел, юк итәргә – ярты көн.

Баш булса – мал, аш булса, казан табылыр.

Бирмә малыңны кешегә хисапсыз,
кермә кеше өенә рөхсәтсез.

Гайрәтле ирдә мал торыр.

Дөньяның кадерен – йөргәндә, малның кадерен – бөлгәндә, җанның кадерен үлгәндә белерсең.

Җиңел табылган җилгә китә.

Чыганак: Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда/ Нәкый Исәнбәт. – 2нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010, 146-148 битләр.

Әбекәй чәе

Оренбург өлкәсенең Әсәкәй район Мәдәният йортында «Туган тел» дигән клуб эшләп килә. Ноябрь аенда әлеге клуб каршында «Әбекәй чәе» дигән татар кунак өе ачылды.

Әлеге кунак өен ачуның максаты – балаларны туган телебезгә, мәдәниятебезгә якынайту. Сер түгел, урыс мохите йогынтысында яшәүче бүгенге татар баласының ана телен белү дәрәҗәсе белән мактана алмыйбыз. Ана телебездән ерагаю елдан-ел ныграк сизелә бара. Бу вазгыятьнең сәбәбе, барыбызга да мәгълүм булганча, мәктәпләрдә татар теле дәресләренең укыту программасыннан чыгарылуы (хәзер инде, кызганычка, татар халкының мәркәзе булган Татарстан Республикасында да шушы ук хәл күзәтелә). Халык составын нигездә татарлар тәшкил иткән безнең Әсәкәй мәктәбендә татар теле 1–5 сыйныфларда факультатив рәвештә укытыла. Әлбәттә, бу юл белән генә телне саклап булмый. Шунлыктан, балаларны, мөмкин булганча, Мәдәният йортында татар телендә узган мәдәни чараларга җәлеп итәргә тырышабыз.

Район Мәдәният йорты методистлары Әлфирә Мөгыйнова һәм Алия Шәриповалар, «Әбекәй чәе» һәм башка чаралар узачак кунак өен оештырганда, биредә татарның чын борынгы мохитен булдыру өчен, бөтен фантазияләрен биреп, илһамланып эшләделәр: көндез утырып тору, ризык әзерләү өчен хезмәт иткән, төнлә ятак вазифасын башкарган сәке урнаштырдылар, идәнгә кулдан тукылган палас җәйделәр, бала тирбәтү өчен бишек астылар, җирле милли бизәкләр төшереп ту-

кылган сөлгеләр, тастымаллар элделәр, самавыр, комган өше көнкүреш кирәк-яраклары тезеп куйдылар.

«Әбекәй чәе»нә, төп кунаклар сыйфатында, Әсәкәй урта мәктәбе укучылары һәм Мәдәният йортының «Нур» балалар вокаль төркеме әгъзалары чакырылды. Әлеге балаларның күбесе татар телендәге мәдәни чараларда инде берничә ел дәвамында катнашып киләләр һәм татарча да шактый иркен аралашалар. Шуңа күрә, Әлфирә «әбекәй»нең зирәклекне сынау буенча биргән йөкләмәләре алар өчен әллә ни кыенлык тудырмады. Ә менә «кызыксынучанлык» сүзенә кергән хәрефләрдән мөмкин кадәр күбрәк сүзләр уйлап табу һәм аларны дөрес итеп язу шактый кыен мәсьәлә булып чыкты. Кайбер балаларның аваз артикуляциясе өстендә дә байтак эшләргә кирәклеге ачыкланды. Балалар ике командага бүленеп ярышты. Жюри рәисе, Әсәкәй район Мәдәният йорты директоры, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Зәйтүнә Геннадиевна Вәлишина һәр җавапка карата да бик таләпчән булды һәм, ахыр килеп, кызлар командасын җиңүче дип игълан итте.

Кызыклы уеннар, башваткычлар белән үрелеп барган «Әбекәй чәе»ннән балалар зур канәгатьлек белән таралдылар. Әлфирә «әби» һәм чараны оештыручы башка хезмәткәрләр кулы белән пешерелгән табын сыйлары да күңелләренә бик хуш килде. Иң кызыгы – чәйне иң күп эчкән бала урыс милләтеннән иде.

Әлегә бу чара айга бер тапкыр планлаштырылган. Алга таба без аны атнага бер тапкыр үткәрергә ниятләп торабыз.

Рания Галим кызы МӨХӘММӘТҖАНОВА,
Әсәкәй район Мәдәният йортының методик кабинет мөдире

Юаткычлар

Баланы тәпи йөрергә өйрәткәндә

***

Вак кына, туак кына,
Бәләкәй генә, куак кына.
Куак асты саз гына,
Бөдрә чәчле кыз гына,
Кил, уйнаек аз гына.

***

Тәп-тәп атлап китә бу,
Ышкафларга җитә бу,
Тәп-тәп йөреп зур үскәч,
Мәктәпләргә китә бу.

***

Текер-текер йөресен,
Тигәнәк моңа тимәсен,
Күп кешеләр моны сөйсен,
Күз дә моңа тимәсен.

***

Йәле, кил әле, кил әле,
Килә аласың микән әле?
Камыт аякларың белән
Баса аласың микән әле?

***

Минем кызым кечкенә,
Бик охшаган үземә.
Әкрен басып, вак-вак атлап
Кил, күз нурым, үземә.

***

«Тәй-тәй» ит, бала, «тәй-тәй» ит,
Атаң прәннек китерер;
«Тәй-тәй» итеп килмәсәң,
Үзе ашап бетерер.

Рәхмәтуллина Зилә

Мөхәммәтҗанова Динә.

Санамышлар

Берәм-берәм,
Икәм-икәм,
Ипелдәтәм,
Типелдәтәм,
Кил, кошым,
Ак бирәм,
Күк бирәм,
Салам сата Кушколак,
Анда түгел, монда чык,
Кайсы җиңел, сикер чык!

***

Әвәләмә, дәвәләмә,
Дәвә кошын кабалама,
Чәнти, чәмбәр,
Тазый, тузый,
Әнчек, мәнчек,
Монда торма, сикереп чык!

***

Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде.
Тау башы ачылды,
Ак ташлары чәчелде,
Сайрыйлар тургайлар,
Шылтырый сука-сабаннар,
Моңая сыерчык,
Җыр салды чыпчык,
Син тор, бу чык!

Низамова Камилә

Хәрәкәтле уеннар

Кәвешче

Уйнаучылар, кулга-кул тотынып, бер түгәрәк ясыйлар. Уртадагы бүкәнгә утырган «кәвешче» куллары белән читек теккән кебек кыйланып көйләп утыра:

Итек, читек, энә, без,
Матур итеп тегәбез.
Кирәкмиме, алмыймсыз,
Әллә киеп карыймсыз?

Түгәрәктәгеләр, җыр беткәч, бар да беравыздан: «Кая бир!» – дип, бер якка таба түгәрәк буенча йөгерә башлыйлар. «Тегүче» утырган урыныннан йөгерүчеләрдән берәрсенең аягына кулы белән тиеп калырга тырыша. Тия алса, аны урынына утыртып, үзе түгәрәккә керә. Тидерә алмаса, уен яңадан башланып, ул «кәвешче» була.

Ханзаров Ислам.

Так каравыл

Иң беренче, санамыш ярдәмендә так каравыл сайлап куялар. Аннан соң уйнаучылыр, икешәрләп кулга-кул тотышып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Так каравыл (казык) булганы алда берүзе тора. Ул арттагыларны күрми. Ул шулай алдына караган хәлдә:

– Очты, очты, кошлар очты! – дип артындагыларга хәбәр бирә. Шул уңайга иң арттагы ике кеше «Көш!» диләр дә, так каравылның ике ягыннан алга узып, качып китәләр һәм берберсенә тотышканчы йөгерәләр. Так каравыл алар тотышканчы куып җитеп, берсен эләктереп алырга тиеш. Тотса, хәзер ул шул тотылганы белән парлашып, теземнең алдына уйнаучы булып килеп баса. Тоттырмаганы (өченчесе) алга килеп, так каравыл булып баса. (Кайбер якта, киресенчә, тотылганын так каравыл итеп бастыралар.) Хәзер инде бу так каравыл да:

– Очты, очты, кошлар очты! – дип, артындагыларга хәбәр бирә.

Арттагы яңа пар «көш» дип алга йөгерә һәм кушылырга тырыша. Әгәр шундый парлар тоттырмаска сүз куешкан булсалар, әллә кайларга кадәр чабалар. Уен шулай дәвам итә.

Сәнгатуллина Камилә.

Алтынтау патшалыгы

Уен кыш көне уйнала.

Берничә ир бала кар өеп тау ясыйлар. Тау өелеп беткәч, балалар бер-берсен этә-төртә тауга менәргә тырышалар. Тау башына беренче менгән бала «патша» була. Ул башкаларны тауга мендермәскә тырыша, менгәннәрен төртеп төшерә бара. «Патша»ның үзен таудан төшерә алган кеше «патша» була, уен шулай дәвам итә.

Хәлилов Инсаф.

Сәхифәне бизәүдә Казан шәһәрендәге 15нче гимназиянең 2А сыйныф укучыларының рәсемнәре файдаланылды.

Чыганак: Татар халык уеннары.Төзүчесе Рәшит Ягъфәров. – Казан: «Раннур» нәшр., 2002. – 26, 27,54, 55, 172, 181, 182, 188 битләр.

Йомырка сытып, сөт яки сөт өсте, шикәр комы, кирәгенчә тоз, чәй содасы өстиләр дә шикәр эреп беткәнче әйбәтләп болгаталар. Аннары он салып, каты итеп камыр басалар. Камырны 1,5–2 мм калынлыгында җәяләр һәм махсус тәгәрмәч яки пычак белән 3–3,5 см киңлегендә тасмаларга, тасмаларны 4–5 см лы кыек шакмакларга кисәләр һәм кайнап торган сары майда кыздырып алалар. Суытып, шикәр оны сибәләр дә табынга бирәләр.

Кош теле

1 кг бодай онына: 10 йомырка, 100 г сөт, тоз, кыздырырга 600 г сары май, камырга салырга 30 г шикәр комы, өстенә сибәргә 100 г шикәр оны, бераз чәй содасы.

Кош теленеке кебек үк камыр басып, 1–2 мм калынлыгында җәяләр, юка стакан белән кисәләр, һәр түгәрәкне 4–5 урыннан (кырыеннан) 1,5–2 см кисеп, 3–4 түгәрәкне берсе өстенә берсен куялар, ябыштыралар һәм кайнап торган сары майда кыздырып алалар. Суынгач, шикәр оны сибеп, чәй янына бирәләр.

Роза

1 кг бодай онына: 10 йомырка, 100 г сөт, тоз, кыздырырга 600 г май, 30 г шикәр комы, 100 г шикәр оны, бераз чәй содасы.

Савытка йомырка сытып, сөт, тоз, шикәр комы өстәп, әйбәтләп болгаталар да, он салып, йомшак кына камыр басалар. Камырга бераз чүпрә дә салсаң, чәк-чәк йомшаграк була.

Камырны 100 г чамасындагы кисәкләргә бүлеп, 1 см калынлыктагы бау сыман тәгәрәтәләр дә эрбет чикләвеге кадәр итеп кисәләр һәм, болгата-болгата, саргылт төскә кергәнче кызган майда пешерәләр.

Балга шикәр комы салып, аерым савытта кайнатып алалар. Аның әзерлеген белү өчен, балкашык белән алып, салкын суга тамызып карыйлар: бал шар булып катып китсә, әзер була.

Әзер төшне зур савытка бушаталар, өстенә бал сибеп, әйбәтләп болгаталар, аннары чәкчәкне поднос яки тәлинкәгә салалар, кулны салкын суга тыгып алып, теләгән форма бирәләр.

Чәк-чәк

1 кг бодай онына: 10 йомырка, 20–30 г шикәр комы, тоз, кыздырырга 500–550 г май, 900–1000 г бал, 150–200 г шикәр.

Татар халкы ризыкка карата үтә таләпчән һәм нәзакатьле. Моны дәлилләү өчен чәй ризыкларыбызның атамаларын гына санап китү дә җитә: чәк-чәк, кош теле, гөлбәнәк, гөбәдия, бавырсак... Заманалар үзгәрә барган саен өстәлләребезгә яңа, ят тәгамнәр өстәлеп торса да, халкыбыз борын-борыннан килгән үз ризыкларын гасыр аша гасырга тапшырып, табын түрендә тота, аларны әзерләү серләрен дә хилафлык китермичә, кадерләп саклый.

Ю.Әхмәтҗанов, Татар халык ашлары, Татарстан китап нәшрияты, 1979. -256,265, 267 битләр.)

2007нче елгы фольклор экспедициясе вакытында Яшел Үзән районының Бишнә авылында төшереп алынган фотолар.

Сатуда бәя ирекле

ИНДЕКСЫБЫЗ– 16987

Кадерле укучыларыбыз!

Менә тагын бер елыбызны йомгаклап куйдык. Көнчыгыш (татар) календаре буенча Кызыл Әтәч елы булган 2017 ел безне шактый чукып, сискәндереп, туган телебезгә булган битараф мөнәсәбәтебез турында уйландырып китеп барды. Инде 16 нчы февральдән Яңа ел – Сары Эт елына атладык. Эт кешеләргә дустанә мөнәсәбәте, тугрылыгы белән аерылып тора. Шул ук вакытта ул усаллыкны, яманлыкны, хыянәтне кичерә белми, тешләп алырга да күп сорамас. Елыбыз тыныч, матур үтсен дисәк, киң күңелле була белик. Һәм, әлбәттә, «Түгәрәк уен» белән бергә халык акылына таянып, үз асылыбызга хыянәт итмичә яшик!

Яңа еллар мөбарәк булсын!